КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№7 (134)
13 февраль
1998 ел

95 елның июленнән
башлап чыга

Атналык гәзит

Бүгенге санда:

2 __Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН.__ Укытучы, аптырагач-йөдәгәч, класс бүлмәләрен ремонтлау, яңа әсбаплар сатып алу өчен ата-аналардан акча җыярга мәҗбүр.

5 __Айдар ХӘЛИМ.__ "Без коры җирнең алтыдан бер өлешен биләп торабыз!" дип күкрәк кагу үзенең империалистик асылын ачты да салды.

17 __Марат ӘХМӘТОВ.__ Республикабызның, татар халкының йөзен, тормышын, яшәү рәвешен бөтен дөньяга лаек итеп тәкъдим итә алырдай шәхес булсын иде Татарстан мөфтие.

19 __Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.__ Авылда туып-үскән талантларыбызны шәһәр тормышы үзенең мең дә бер каршылыклы яклары белән сыный...



Аллаһыдан иман, нур алганбыз —
Хак мөселман булып яралганбыз...

Мөхәррир мөнбәре

Фәрештә валчыгы... Татарның даһи шагыйре балаларны әнә шулай атаган. Бүгенге кырыс заманыбыз турында уйланганда, шушы иләһи сүзләрне искә төшерәсең дә, ихтыярсыз имәнеп куясың: аһ, күпме безнең көтелмәгән тормышта балаларны ач тотулар, имгәткәнче кыйнаулар, ябып-бикләп тотулар, ирексездән үксез калдырулар, аларны фаһишәлек максатында файдаланулар, чит илләргә сатып җибәрүләр, аерым әгъза-шәрифләрен „запчасть" рәвешендә кулланулар, үтерүләр... Бөтенесен санап китсәң, чәчләрең үрә торырлык. Без киләчәк варисларына карата иблислек күрсәтеп, җинаятьче буларак, гаять зур гөнаһ кылабыз түгелме?! Әллә фәрештә канатына пычрак кулыбызны сөртүдән ил-көнгә бәрәкәт иңәр дип уйлыйбызмы?..

Зиннур МАНСУРОВ

Мин әйттем

Чирләшкәләр булмасын дип...

Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН,
"Мәгариф" журналының баш мөхәррире урынбасары



Мәктәп нинди генә сикәлтәле юллар, зур сынаулар узмады. Ул һәрвакыт яшәеш ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырыша.

90 нчы елларда җәмгыятьтә тирән үзгәрешләр барлыкка килгәч, мәгариф учреждениеләренә дә яңалыклар дулкыны "бәреп керде". Шунысы әһәмиятле: бу үзгәрешләр мәктәпнең үзеннән башланды. Укытучылар коллективы, югарыдан күрсәтмәләр көтеп тормыйча, яңа эш формаларын, укытуның яңа технологияләрен эзли башлады. Башкача булу мөмкин дә түгел. Укытучы халкы шундый тынгысыз, үҗәт җанлы инде ул. Мөмкинлек, шартлар булмаса да, таулар күчерергә әзер. Мөгаллимнәрнең күңеле дә саф, самими, тормышта очрый торган төрле тискәре күренешләргә алар чын күңелдән көенә, шуларны булдырмау юлларын эзли башлый.

Хәзерге чорда укыту-тәрбиягә үзгәрешләр кертүдә иң беренче каршылык булып мәгариф эшләренә тиешле күләмдә акча бүлеп бирмәү тора. Ә акча бигрәк тә мәктәпкә кирәк. Укытучы, аптырагач, йөдәгәч, класс бүлмәләрен ремонтлау, яңа әсбаплар сатып алу өчен ата-аналардан акча җыярга мәҗбүр. Бу – килешә торган эш түгел, билгеле. Нишлисең, башка чара юк. Мондый хәлне гәзит-журналлар, радио, телевидение бик нык тәнкыйтьләде. Бу очракта мөгаллимнәргә сүз әйтү урынсыз, минемчә. Аны җәмгыять, мәктәпнең хәерчелеге шуңа этәрә. Элеккеге зур завод, предприятиеләрне акционерлаштырып, аларның хуҗалары булып калган һәм, законсызлыктан файдаланып, үзләре теләгәнчә хезмәт хакы алучылар, бер шәһәрдә генә дә 4-5 фатир тотучы, чит илләрдә виллалар салдыручы, акчаларын Төркия, Швейцария, АКШ банкларында саклаучы абзыйлар, дәдәйләр типтереп яшәгәндә, мәгариф, мәдәниятне үстерүгә, сәламәтлекне саклауга акча бик аз кала шул.

Мөгаллим вакыт-вакыт аптырашта кала: җәмгыятебезнең киләчәге булган балаларны ничек итеп рухи һәм физик яктан сәламәт итеп үстерергә соң? Ул белә: аның юнәлешләре күп... Һәркайсы мөһим. Шуларның берсе, мәсәлән, милли тәрбия бирү. Моңарчы гел урысча гына укып урыслашып бетә язган балаларыбызга татар теле укыту, аларны татарча сөйләргә, укырга, язарга өйрәтү эше көннән-көн җанлана бара. Әлбәттә, укытучылар зур тырышлык куйган урыннарда ул шулай.

Моның әһәмиятен яшьләргә бүген аңлатып бетерүе дә кыен. Ә олыгайгач, соң булуы мөмкин.

Әле күптән түгел генә мин улыма мәктәптә математика укыткан һәм аларның класс җитәкчесе булган мөгаллимәне очраттым. Хәзер пенсиядә инде ул. Ләйлә ханым Троицкида туып-үскән. Шунда урыс милләтеннән булган кешегә кияүгә чыккан. Бу гаилә ике малай тәрбияләп үстергән. Соңыннан алар Казанга күчеп кайткан. Баштарак без Ләйлә ханымны Ольга Ивановна дип белә идек. Төсе, кыяфәте белән гел урыс кешесе кебек ул. Тик шулай да аның мөлаем карашында, йомшак сөйләшүендә татар милләте сыйфатлары чагылып киткән кебек була иде. Мәсьәләгә очраклылык ачыклык кертте. Көннәрдән бер көнне укытучылар конференциясенә багышлап төзелгән стендта Ольга Ивановна фотосурәте күзгә чалынды. Рәсем астындагы язуны җентекләп карасам, ни күрим: Ләйлә Ибраһимовна Геполова дип язылган иде анда. Ә инде шуннан соңгы очрашуда мин аңар Ләйлә Ибраһимовна дип эндәштем. Ул йомшак кына итеп күз сирпеп алды да: "Миңа үз исемем белән эндәшүче юк иде әле. Яшьлегемә, милләтемә кире кайткандай булдым", – диде ул. Шулай еллар уза торды. Минем улым да мәктәпне, югары уку йортын тәмамлады. Математикадан төпле белемле булуы белән аерылып торды ул. Ләйлә ханым очрашуларның берсендә болай диде: "Хәзер ялда. Еш кына үткән гомеремне искә төшерәм. Үземнең туган телемне белмәвемә бик үкенәм. Җәй көннәрендә татар карчыклары, үзләренең кершәндәй ак яулыкларын бәйләп, ишек алдына чыгып утыралар. Урыс карчыклары да, аерым бер төркемгә берләшеп, гәп сата. Ирексездән, үз-үземә сорау бирәм: мин – кем? Татармы, урысмы? Мин бер төркемгә дә кушыла, алар белән чын күңелдән аралаша, сөйләшә алмыйм. Алар да мине кабул итми кебек. Менә шушы уйларны уйлап, кайчак йокыларым кача..."

Әйе, мөгаллимә Ләйлә Ибраһимовнада татар каны ага, заманында телебезгә, гореф-гадәтләребезгә бик үк әһәмият бирмәве өчен аның йөрәге газаплана, җәберсенә. Бары тик укытучы йөрәге генә әнә шулай сызлана ала. Хәзер тормышта очрый торган күңелсез хәлләрнең һәрберсенә мөгаллимә күңеле белән тирәнтен борчыла, әрни. Шулай яратылган да инде ул укытучы. Башкача була да алмый. Ә бит татарлыгын җуеп милләтенә, аның гадәтләренә төкереп караучы маңкортлар күпме?

Ләйлә Ибраһимовнаның шундый хәлгә калуында безнең чынбарлыгыбызның, җәмгыятьнең зур гаебе бар. Бу турыда күп сөйләргә булыр иде. Мәгариф тормышында да мөгаллимне сыкрандыра торган хәлләр еш булып тора. Республика, район күләмендә үткәрелә торган конкурс, смотрларда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының класстан тыш үткәргән чараларына составында бер генә татар кешесе дә булмаган жюри әгъзалары бәя бирүне дә нәрсә дип әйтергә дә белми ул. Үзен мыскыллау дип тә, санга сукмаулары дип тә аңлый. Әмма күңелен төшерми. Эшли дә эшли. Балаларга белем һәм тәрбия бирә.

Тәрбия – укучы шәхеснең үсеш процессы белән максатчан идарә итү ул.

Биредә балалар сәламәтлеген саклауга игътибарны юнәлтү аеруча мөһим. Безнең ил кыен чорны кичерә: ул – чирле. Чирле җәмгыятьтә чирле балалар туа һәм үсә. Ә чирләшкәләр белән ерак барып булмый.

Бүгенге җәмгыятьтә балалар тормышын тулырак күз алдына китерү өчен саннарга мөрәҗәгать итик. Яңа туган балаларның 17 проценты акыл ягыннан зәгыйфь. Русиядә 15 млн. наркоман, 35 млн. эчкече бар. Революциягә кадәр Русия җан башына исерткеч эчемлекләр куллану буенча дөньяда 11 нче урында торган. Бүгенге көндә илдә һәр кеше елына уртача 25 литр исерткеч эчемлек куллана. Ә бу сан дөнья күләмендә 5 литр тәшкил итә. Шуны да ассызыклап үтик: җан башына 8 литр исерткеч эчемлек кулланганда милләт бетүгә йөз тота башлый.

Хәзер балалар һәм яшүсмерләрнең 15-19 проценты гына сәламәт: Яшь буынның 75 процентына психиатрия ярдәме һәм тиешле дәва кирәк.

Безнең Татарстанда да балалар сәламәтлеге шәптән түгел. Татарстан халык депутаты Сүрия Усманова әйтүенчә, республика мәктәпләрен тәмамлаучылар арасында сәламәт егет һәм кызлар 5,2 процент кына тәшкил итә. Укучыларның 50 процентка якыны азканлылыктан интегә, гәүдә авырлыгы – буйларына, ә буйлары яшьләренә туры килми. 22 мең кеше сабый чактан ук гарип. Билгеле, авыру балаларны дәвалау һәм тәрбияләү өчен хөкүмәтебез бернәрсә дә эшләми дип әйтеп булмый. Әлеге максат өчен елга 372 миллиард сум акча тотыла. Әмма бу бик аз.

Мәктәпләрдә белем һәм тәрбия бирү өчен дә шартлар җитәрлек түгел. Икенче, өченче сменада укучылар саны да арта тора. Республикада бер укучыга 3 квадрат метр уку мәйданы туры килә. Бу – нормадан 1,4 тапкырга түбән.

Шәһәр читендә урнашкан җәйге сәламәтләндерү лагерьларының саны да елдан-ел кими. 1990 елда алар 145 булса, үткән җәйдә нибары 100гә якыны гына балаларны кабул итте. Элеккерәк елларда үсмерләр өчен клубларда төрле түгәрәк, секцияләр эшләде. Бүген аларның барысы да ябылган, спорт корылмаларына балалар түгел, эшмәкәрләр хуҗа. Ә ябылган ишек алды клубларына коммерсантлар кереп оялаган.

Бары тик сәламәт балаларга гына тиешле белем һәм тәрбия бирергә мөмкин. Әгәр дә сабыйның тамагы – тук, өсте – бөтен, сәламәтлеге булмаса, аңа гыйлем туплау өчен шартлар тудырылмаса, мөгаллимнәр нинди тәрбия системасы гына уйлап тапсалар да, аның бернинди нәтиҗәсе булмаячак.

Моны искә алып, Аксубай районы Иске Илдерәк мәктәбе укытучылары физик культура чаралары белән сәламәт тормыш рәвеше принципларын формалаштыра.

Биредә укучыларны сәламәтләндерү эше махсус программа нигезендә алып барыла. Һәр укучының "Безнең сәламәтлек" дигән диагностик картасы бар. Класс җитәкчеләре бу картага кайсы баланың кайчан, нинди авыру белән авыруы, ничек дәвалануы, хәзерге вакытта сәламәтлеге торышы, медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында язалар.

Һәр класс сәгате "Син һәм синең сәламәтлегең" дигән темага 10 минутлык сөйләшүдән башлана. Анда укучыларның өйдә нинди физик күнегүләр белән шөгыльләнүе, спорт секцияләренә ничек йөрүе, ярышларда нинди уңышларга ирешүе турында сөйләшәләр, еш кына "Сәламәтлек дәресләре" дә уздырыла. Аларга физкультура укытучылары, медицина хезмәткәрләре чакырыла. Алар сәламәт булу өчен нәрсәләргә игътибар итәргә кирәклеген әйтәләр. Атнага 3 сәгать укытыла торган физкультура дәресләреннән тыш, барлык укучылар да, һәр көнне 3 дәрестән соң, физкультура күнегүләре ясарга чыга.

Барлык физкультура-масса эшенә физкультура советы җитәкчелек итә. Ә план, положение проектлары, бәйрәм сценарийлары класс җитәкчеләре киңәшмәсендә тикшерелә.

(Ахыры 4 нче биттә).

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән
5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

Хемингуэй иле ник кыбырсый?

Ерактагы Кояш яктырак була, диләр. Ә менә ерактан торып янаган кара көчләр тагын да хәвефлерәк вә хәтәррәк була икән. Америка һәм Бөекбритания, сүз берләшеп,хәрби көчләрен кая куярга белмәүдән аптырап-йөдиме, кемгә булса да бәйләнергә сәбәп эзлиләр. Шундыйлар табылып та тора тагын. Ул гарәп илләренең берсе – Гыйрак. Илнең үзеннән дә бигрәк аның җитәкчесе Саддам Хөсәен кайберәүләргә тынгылык бирми. Чөнки ул кыю, башбирмәс, үз иленең эчке эшләренә тыкшынучы даирәләрдән дә өркеп калмаучы Илбаш.

Ни өчендер бу очракта Җәүһәр Дудаев искә килеп төшә. Ул да үз Ватанының азатлыгын, бәйсезлеген яклап көрәште, шул юлда шәһит китте. Әмма ул башлаган изге эш, ут-ялкын эченнән чыгып, хәзер дә дәвам итә. Димәк, сугыш белән генә халыкның изге ниятен үтерү мөмкин түгел, ул яши, дәвам итә.

Җир шары алга, киләчәккә тәгәри. Гыйрак халкының да үзе сайлаган җитәкчесе белән алга атларга, үзе теләгәнчә яшәргә хокукы бар. Американың да, Бөекбританиянең дә бер генә илгә дә күрсәтмә бирергә, аның эчке эшләренә тыкшынырга хакы юк. Американың нинди төр генә коралы юк икән?! Ә ул бик ерактан килеп, Багдадны тикшермәкче, С.Хөсәен яшәгән йортта нәрсә барлыгына күз салмакчы була. (Дөрес, Гыйрак та, башка илләр кебек, БМО карарларын үтәргә тиештер). Америкага анда ни бары мөһим түгел, ә бары тик сәбәп кенә. Ә гарәп дөньясында күп нәрсә, аеруча яшәү рәвеше сер булып кала. Ярый, хуш, Хөсәеннең коралы да булсын ди, ләкин бу һич тә Америкага янау дигән сүз түгелдер ич. Һәр илнең үз иминлеген саклау өчен корал җитештерергә хокукы бардыр. Гыйрак солдатлары Американың Ак йорты каршында түгел, ә АКШ самолетлары һәм хәрби корабльләре Багдадка ут, сугыш ачарга торалар лабаса. Кызганыч, бу очракта ерактагы Америка Кояш та, яктылык чыганагы да түгел.

Американың бөек әдибе, Нобель бүләге иясе Эрнст Хемингуэй заманында "Прощай, оружие!" дигән роман язган һәм анда сугышның нинди нәтиҗәләргә китерүе турында кисәткән иде. Бу очракта да АКШ җитәкчеләренә мәшһүр язучының кисәтүенә колак салу комачау итмәс иде...

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

Бөгелмә кызы – Олимпия чемпионы

Японияиең Нагано каласында башланган XVIII кышкы Олимпия уеннарында Русия командасына иң беренче алтын медальне Бөгелмә шәһәрендә туып-үскән һәм шунда чаңгы спорты белән шөгыльләнә башлаган Ольга Данилова алып бирде. Ольга – ике мәртәбә дөнья чемпионы. Аның ике баласы бар. Хәзер ул гаиләсе белән Владимир өлкәсендә яши.

Меццо-сопрано соклануы

Узган ел Германиядә, Франция һәм Һолландиядә Казан дәүләт консерваториясенең татар халык уен кораллары оркестры гастрольләре булган иде.

Шул уңайдан Һолландиядә вакытта Татарстан артистлары белән йөргән Британия җырчысы Рейчел Анн Морганнан Татарстан Хөкүмәте адресына хат килеп төште. Меццо-сопрано тавышлы җырчы оркестрның башкару осталыгына, виртуозлыгына һәм талантына баш июен белдерә. Морган ханымның Ринат Халитов турындагы фикере аеруча дулкынландыра: мондый дирижер турында һәр җырчы хыяллана гына ала, дип яза ул. Рейчел Анн Морган Һолландиядә башланган хезмәттәшлекнең дәвам итәчәгенә ышаныч белдерә.

Котлыйбыз, "Нократ"!



Мамадыш районында чыга торган "Нократ" гәзитенә 80 ел тулды. Төрледән-төрле хакимиятләр чорын кичереп, халыкның катлаулы язмышы белән яшәгән әлеге олпат басманы "Мәдәни җомга" укучылары, "Нократ" фатихасы буенча зур әдәбиятка килгән якташ язучылар, мәдәниятнең төрле өлкәсендә ат уйнатучы күренекле сәнгатькәрләр, галимнәр исеменнән олуг юбилее уңаеннан кайнар тәбрикләбез, район елъязмасының якты сәхифәләрен арттыру хакына яңадан-яңа уңышлар телибез.

Фестивальләр, бәйгеләр...

Сәнгать уку йортлары арасында Казан дәүләт консерваториясе Русия күләмендә "Елның сәнгать укытучысы" дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды. Бу очраклылык та, күктән яуган бәхет тә түгел,бәлки укытучы, методист һәм музыкантларның күп еллык тырыш һәм максатчан хезмәт нәтиҗәсе, республикадагы музыка мәктәпләре, махсус мәктәпләр һәм музыкаль училищеларда белем алган яшь талантларның, аларга белем биргән укытучыларның да уңышы. Чөнки консерваториягә төп базаны нәкъ менә алар әзерли.

* * *

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Казан дәүләт консерваториясе елның-елында Татарстан музыка мәктәпләре арасында төрле-төрле конкурслар, фестивальләр уздыра. Яшь талантлар кечкенәдән үк игътибар үзәгендә тәрбияләнә, аларны сайлап алу, юнәлеш бирү, кирәк чагында ярдәм итүдә музыка училищеларының да, консерваториянең роле зур. Һәм теге яки бу өлкәдә "Казан мәктәбе" дөньякүләм аренага чыга икән, гаҗәп тоелмас, чөнки моңа ныклы база бар.

* * *

Узган ел республика күләмендә яшь пианистлар конкурсы композитор Ринат Еникеев юбилеена багышлап уздырылган иде. 10-14 февральдә уздырылган виолончель фестивале бөтен Казанны шаулатты. Анда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән һ.б. шәһәрләрдәге музыка мәктәпләреннән алтмышка якын укучы катнашты. Сайлап алу турлары узганнан соң Татарстанның Зур концерт залында галаконцерт булды, лауреатларга бүләкләр бирелде. Фестивальгә Русиянең Гнесиннар исемендәге музыка академиясе галимнәре доцент Е.Жулева, Русиянең халык артисты, профессор В.Тонха кебек кунаклар да килде.

* * *

23-27 февральдә икенче фестиваль – тынлы музыка республика фестивале узачак. Аның статусы башкачарак – әлеге фестивальдә махсус музыка мәктәпләре, музыка училищеларында укучылар көч сынашачак. Башкаручылар Татарстаннан гына түгел, Идел буе республикаларыннан һәм Русиянең төрле шәһәрләреннән дә киләчәк.

Хөрмәтле укучылар! Татарстан Элемтә министрлыгы 1 февральдән 31 мартка кадәр 1998 елның икенче ярты еллыгы өчен гамәлдәге бәядә "Мәдәни җомга"га льготалы язылу үткәрә. Димәк, почта бүлекләренә барып, тагын 27 сум акча түләсәгез, гәзитебез сезгә ел ахырына кадәр килеп торачак. Бу хакта туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга да әйтсәгез икән.

Әйткән сүз — аткан ук

Борис ЕЛЬЦИН, РФ Президенты (Белоруссия Илбашы турында):
"... Ә ул әле, үсеп, исәя төшәчәк. Без аны тәрбияләячәкбез".

Павел ШЕРЕМЕТ, ирегеннән мәхрүм ителгән тележурналист, ОРТның Белоруссиядәге корпункты җитәкчесе:
"Лукашенко тәрбиягә бирелми..."
("КП").

Музей аурупача сипләнде

15 февраль – каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне.

Бу олпат затның Казандагы музей-фатиры бүген ни хәлләрдә? Мәгълүмдер, былтырның августында аны вакытлыча ябып куйдылар. Бу – капиталь ремонт, яңа биналарга реконструкция үткәрү белән бәйле иде.

Элегрәк монда эшләүче хезмәткәрләргә чыннан да кысанрак иде. Бирегә килгән тамашачылар өчен дә уңайсызлыклар шактый булды.

Казанның "ЮТЕК" фирмасы бирегә Аурупа стандартларына туры китереп ремонт үткәрде, һәм тиздән музей үзенең кунакларын тагын кабул итә башлар. Хәзер биредә һәртөрле әдәби-музыкаль кичә оештыру өчен зал да бар, пианино, видеоаппаратура да куелган.

Тиздән, февраль ахырында, музей хезмәткәрләре, Балык Бистәсе һәм Тәтеш районнарына барып, халык белән очрашырга, шагыйрь турындагы яңа мәгълүматларны бәян итәргә ниятләп тора.

Шупашкар рәссамы Казанда

"Казан" милли мәдәният үзәгенең "Ренессанс" галереясендә Шупашкар рәссамы Азат Сафинның шәхси күргәзмәсе ачылды. Оста бирегә үзенең 40ка якын хезмәтен куйган. Азат Сафин – нечкә поэтик тоемлау сәләтенә ия рәссам. Рәсем ясау өстенә ул шигырь язу белән дә мавыга.

Башланган эш – беткән эш

Иртәгә Казанның Бауман урамында данлы якташыбыз Ф.Шаляпинга куелачак һәйкәл урынына таш салу тантанасы үткәрелә. Бүген исә мәшһүр җырчының тууына 125 ел тула.

Һәйкәл Богоявление чиркәве янәшәсендә булачак. Республика көнендә, 30 августта, әлеге һәйкәлне ачу тантанасы булыр, дип көтелә.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Президент М.Шәймиев Кремльдә Монголиянең Русия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Ц.Цолмон әфәндене кабул итте.

Зур концерт залында Кол Шәриф мәчете төзелеше файдасына хәйрия концерты булып узды, концертны Президент М.Шәймиев, вице-премьер И.Хәйруллин да тамаша кылды.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Федор Шаляпин фестивале дәвам итте.

Татарстан Министрлар Кабинеты "Яңа үрнәктәге акчаларны әйләнешкә кертү чорында чаралар үткәрү турында" карар чыгарды.

Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев Татарстанда Кеше хокуклары елын үткәрү буенча оештыру комитетының беренче утырышын үткәрде.

Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин республиканың алкоголь җитештерү тармагына кагылган мәсьәләләр буенча киңәшмә уздырды.

Русиянең сәламәтлек саклау министры Т.Дмитриева Казанда булып китте.

Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмә залында балалар иҗатына багышланган "Төсле планета" дип исемләнгән күргәзмә эшли башлады.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Харисов "Әл-Зәкәт" хәйрия җәмгыяте вәкилләре белән очрашты.

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Казан дәүләт консерваториясе, шәһәр хакимиятенең мәдәният идарәсе, Композиторлар берлеге Казанда беренче тапкыр виолончель музыкасы фестивале үткәрде.

Татарстан Берләштерелгән дәүләт музеенда бөек галим һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 180 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды.

7 февральдә гармунчыларның Фәйзулла Туишев исемендәге YI республика бәйгесе башланды.

Сәхифәдә редакция журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Н.КУРАМШИН, Ә.ШӘФИГУЛЛИН** фотосы.

Үз илем — алтын бишек

Еш кына без, илнең гөле илгә аңкымас, дияргә яратабыз. Нишлисең, кешенең таланты туган-үскән җирдә үк ачыла башласа да, ул читкә китеп таныла, бәясен ала.

Елганың көче чишмәдә

Соңгы елларда җөмһүриятебез районнарында милли тәрбиягә игътибар шактый көчәйде. Туган якны өйрәнү укудан тыш эшләрнең дә бер юнәлешенә әверелде. Бу уңайдан әлегә күпләрнең кукмаралылардан үрнәк алырлыклары бар, дип әйтәсе килә. Биредә һәрбер мәктәпнең кечкенә генә булса да үз музее оештырылган. Аларда үз төбәкләрендә туып-үскән, зур иҗат мәйданында танылган әдип-шагыйрь, галимнәрнең иҗатын яктыртучы экспозицияләр куелган. Соңгы елларда Кукмара төбәгеннән әдәбиятка шактый гына яңа исемнәр килде. Рәшит Бәшәр, Рәниф Шәрипов, Заһид Мәхмүди, Газинур Морат... Өлкәнрәк буыннан галим һәм тәнкыйтьче Фоат Галимуллин, сугыш кырларын аркылыга-буйлыга узган язучы Мәгъсүм Насыйбуллин... Күрәсез, иҗатның һәр өлкәсенә Кукмара үз өлешен кертә.

Гыйнвар ахырында Кукмара районында якташ язучылар катнашында әдәбият атналыгы уздырылды. Язучылар 20ләп мәктәптә булды, мәдәният йортларында очрашулар үткәрде.

Бу якта гаҗәеп тырыш, хезмәт сөючән халык яши. Авыл клубларында очрашулар вакытында без аларның югары сәнгать дәрәҗәсендәге чыгышларына да еш тап булдык һәм берникадәр аптырап та калдык. Авыл саен күпме талант! Әмма... танылган артистлар арасында аларның исеме алай ук еш очрамый шикелле. Бу, әлбәттә, традицияләр белән бәйле. Акыл көче, хезмәт куеп, мул, нык тормышта яшәргә күнеккән монда халык, җырны, шигырьне, гомумән, иҗатны яраткан шөгыль итеп кенә карый кебек, киләчәге өчен табиб, укытучы һөнәрен сайларга тырыша. Бүгенге көндә район буенча югары уку йортларында гына да 300дән артык студент мөгаллимлеккә укый. Чыгарылыш сыйныфларының яртысы укытучылыкка киткән мәктәпләр бар. Мөгаллим кешенең талант иясе булуы да начар түгел, билгеле.

Әйе, Кукмара ягы – әдәпле, динле як. Бу районнан мөселманнарның чираттагы корылтаена да 57 кеше бара икән. Димәк, туган ягымда бүгенге көндә 57 мәчет эшли.

Ничәмә еллар тере шагыйрь һәм язучыларны күрү бәхетеннән мәхрүм булып торган халык бу очрашулардан, шөт, канәгать калгандыр. Төрлечә – көлеп тә, елап та тыңладылар алар безне. Чөнки һәрберебезнең иң кадерле истәлекләре туган ягыбыз, авылыбыз, аларның кешеләре белән бәйле иде ич.

Очрашу вакытлары бик кыска билгеләнгәнлектән, сөйләшер сүзләр бетмәгән килеш киттек. Җылы кабул итүләрдән тамакка төер утырган хәлдә туган ягыбыз белән хушлаштык.

Район мәдәният бүлеге мөдире Азат Сабитов, "Ислах" мәгълүмат агентлыгы җитәкчесе Радик Әминов, район мәгариф бүлеге хезмәткәре Әлмира Хәбибуллина белән якын дуслар булып аерылыштык.

Кукмара чишмәләре әдәбият елгасын әле киләчәктә дә саф, үзгә, татлы сулар белән тулыландырыр дигән ышанычны тагын бер кат ныгыткан иҗат көннәре булды бу.

Рифә РАХМАН.



● *Язучы Мәгъсүм Насыйбуллин.*
● *Тәнкыйтьче Фоат Галимуллин һәм шагыйрә Рифә Рахман.*

Радик ӘМИНОВ фотолары.

Газинур МОРАТ

Авылдашлар кайта...

Үз бәхетен үзе таба халык,
Ярдәм көтми күктән, Алладан...
Ел да, әнә, Сабантуйлар җитсә,
Авылдашлар кайта каладан.
Авылдашлар кайта Сабантуйга,
Бохарадан кайта, Донбасстан.
Авылдашлар кайта...
Иңсәләрен
Биштәр түгел, гүя моң баскан.
Ә биштәрдә – кала күчтәнәче –
Әфлисуны, лимон, кавыны...
Бөтен авыл бүген кавын ашый –
Кавын тансыклаган авылым.
Авылның да үз хөрмәте, сые –
Каклаган каз, әйрән, катыгы...
Кунакларга әйрән, катык булсын –
Күрәксенмәс шуннан артыгын.
Тәмләп кенә әйрән эчә алар,
Тәме шул ук юкса – таныш тәм.
Бары бераз ачылана төшкән,
Ачылана төшкән сагыштан.
Авылым да үйчанланып калган –
Ул күнеккән инде котәргә...
Ишегалларында, тыкрыкларда
Ешрак өрә бүген этләр дә.
Ятсынырмы өрә...
"Кунак" сүзе
Таныш түгел бугай аларга.
Ә калада этләр өрми.
Этләр
Борынчыклы була калада.
Ә калада этләр күндәм була,
Күнгән була әмер теленә.
Ә калада сукбай этләр генә
Шыңшып йөри подъезд төбендә.
Ә шуларга кемдер таш ыргыта,
Малай-шалай уза типкәләп.
И Табигать, син дә үксез мәллә –
Ник этләрең йөри типкедә?!
Ни атлары, кушаматлары юк,
Кемгә хаҗәт этләр кайгысы?
Ә авылда этләр атлы була,
Кушаматлы була һәркайсы.
Әнә Акбай...
Кунак икәнеңне
Яшерермен димә аңардан
Шундук сөрән салыр:
– Каладашлар,
Подъездашлар кайта каладан.
Әнә Сарбай...
Дымсу карашыңны
Яшерермен димә аңардан.
Шундук сөрән салыр:
– Шахтадашлар,
Язмышташлар кайта каладан.
...Сызлык, тальян,
"Шахта" көйләренә –
Чиләбедән, Төмән, Донбасстан
Авылдашлар кайта...
Иңсәләрен
Биштәр түгел, гүя моң баскан.

Чирләшкәләр булмасын дип...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Һәр уку елы башында классларда анкета сорауларына җавап яздырыла. Анкета мәгълүматлары балаларның кайсы фәнне тырышып үзләштерүен, физкультура дәресләренә мөнәсәбәтен, нинди спорт секцияләрендә шөгыльләнүен белергә ярдәм итә. Мәктәптә физкультура дәресләрен, класстан тыш спорт чараларын тиешле дәрәҗәдә үткәрү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәр укучы бер спорт секциясенә йөри. Спорт бәйрәмнәре үткәрү традициягә кергән. Көз һәм яз көннәрендә "Йөгерешчеләр көне" уздырыла. Анда барлык укытучылар, укучылар, ата-аналар катнаша. Һәр елны җәйге һәм кышкы спорт сезоннарын ачу тантанасы, спорт бәйрәмнәре, мәктәпнең һәм авылның иң көчле спортчылары, физкультура укытучылары белән очрашулар, спортринглар һ.б. үткәрелә.

Мәктәптә "Үз-үзеңә ярдәм ит" дигән клуб та нәтиҗәле эшли. Укучылар клуб дәресләрендә анатомия, биологиядән алган белемнәрне файдаланырга өйрәнәләр.

Мәктәптә 1 нче сыйныфтан ук сәламәтлекнең кеше өчен иң кыйммәтле, иң әһәмиятле нәрсә икәнлеге төшендерелә. Шуңа күрә укыутучы да, ата-аналар да моңа нык игътибар итәләр. Моның нәтиҗәләре дә бар. Соңгы мәртәбә үткәрелгән медицина тикшеренүләре күрсәткәнчә, балалар салкын тию авырулары белән авырмыйлар, ябык һәм кирәгеннән артык симез балалар, шулай ук тәмәке тартучылар, исерткеч эчемлекләр кулланучылар юк.

Укучыларның сәламәтлеген ныгыту мәсьәләсе мөгаллимнәрнең игътибар үзәгендә булуы тагын бер мисалдан бик ачык күренә.

Аксубай якларында суда йод җитешми икән. Бу исә калкансыман биз авыруы китереп чыгара. Шуңа күрә укытучылар, балаларда бу чирне булдырмау өчен, составында йод булган антиструмин даруын үз акчаларына сатып алалар һәм аны шәфкать туташлары бушлай өләшәләр. Билгеле, бу эш табиб җитәкчелегендә эшләнә.

Сөйләгәннәрдән күренгәнчә, Аксубай районының Иске Илдерәк мәктәбе тәрбия системасында укучыларның сәламәтлеген ныгыту төп юнәлеш булып тора.

Кеше дөньяга өч алшарт белән туа. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: хәрәкәткә, вертикальлеккә, пространствога омтылу. Җәмгыять еш кына бу омтылышны сүндерә. Укучылар аз хәрәкәтләнә, тирә-юньдә пычрак һава, без куллана торган ризык экологик яктан чиста түгел, мәктәпләр кысан.

Бала 3-4 яшьтә көненә – 9-10 мең, 5-6 яшьтә – 13 мең, 7дә – 15-30 мең адым атларга тиеш. Шуңа күрә һәр дәрестә физкультминутлар үткәрелсен. Аз хәрәкәтләнүчеләрнең тормышы кыска булуын мисаллар белән дәлилләргә була. Мәсәлән, йорт куяны (кролик) – 3-4 ел, ә кыр куяны – 15 ел яши. Чөнки аның гомере чабып уза. Моны истә тотып, Түбән Камадагы 22 нче лицей укытучылары тәнәфесләрне озынрак итәләр, ул вакытта балаларны саф һавага алып чыгалар. Һәр көнне, өченче дәрестән соң, экология дәресе үткәрелә. Күз, кул, аяк, бармаклар өчен махсус күнегүләр, һәр дәрестә 15 минуттан һәм 30 минуттан соң физкультминуткалар уздырыла.

Мәктәптә югары белемле физиологлар һәм психологлар эшли. Табиблар белемен күтәрү институтының балалар авырулары кафедрасы белән килешү дә төзелгән. Табиблар әледән-әле укучылар сәламәтлеген тикшереп тора. Тикшерү мәгълүматлары медицина картасына теркәлә һәм алга таба сәламәтләндерү чаралары күрелә.

Әйе, укучылар сәламәтлеген саклау һәм ныгыту – тәрбия системасының мөһим юнәлешләреннән берсе.

Хәзерге чорда безнең илдә бара торган яшәү өчен көрәш, шәхси эшмәкәрлекне хуплау, җәмгыятьтә үз-үзеңне генә ихтирам итү хисенең көчәя, коллективларның таркаулана баруы, яшьләр арасына базар мөнәсәбәтләренең кыргый законнары үтеп керүе, безгә бөтенләй ят булган мөнәсәбәтләр формалашу яшь кешенең якты омтылышларын сүндерә, үзенә тиешле тормыш юнәлеше сайларга комачаулый. Аңа еш кына гаилә дә ярдәм итә алмый. Ул да базар "чире" белән авырый. Бу шартларда яшь буынга мәктәпнең гуманлы тәрбия системасы гына ярдәм итә ала. Бары тик мәктәп, укытучы гына яшь буынны фаҗигадән коткарып калырга мөмкин.

Тормыш урта мәктәп алдына тәрбия эшен яңача оештыру бурычын куя. Мәсәлән, хәзерге вакытта яшьләр (гомумән, җәмгыять) акча туплауга зур әһәмият бирә. Элегрәк тә әлеге мәсьәлә игътибардан читтә түгел иде, ләкин базар мөнәсәбәтләре бу хисләрне тагын да көчәйтеп җибәрде. Педагогика фәне мондый хәлгә нинди караштa торырга тиеш соң? Мәгълүм ки, "акча артыннан куу"ны, акча туплау өчен төрле җинаятьләр эшләргә әзер торуны тәнкыйтьләп кенә тормышка үзгәреш кертеп булмый. Хәзер чоры башка. Шунысын да танырга кирәк: яшүсмерләрнең кооперативта эшләп яки шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнеп, яисә шәхси автомашиналарның пыяласын юып акча тупларга тырышуы – гадәти күренеш. Ләкин яшүсмерләргә бу мәсьәләдә уңай тәэсир итүдән баш тарту хата булыр иде. Шулай итеп, акча туплау белән табигый мавыгуны ыклы әхлакый нормаларга туры килүенә, көч куеп эшләп алган акчаны җинаятьчел яки башка төрле юл белән табылганнан аера белү күнекмәсе тәрбияләүгә нык игътибар итәргә кирәк. Бу – хәзерге чорда барлыкка килгән педагогик мәсьәлә. Эшләп алган акчаны ничек тоту, кирәкле әйбер сатып алу, хуҗаларча эш итү күнекмәсе тәрбияләү дә гади генә бурыч түгел. Аларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе әле тупланмаган. Шунысы ачык: базар һәм мәктәп бер-берсеннән "йөз чөерергә" тиеш түгел, бәлки, алар шәхесне заман таләбенә җавап бирерлек итеп тәрбияләүдә кулга-кул тотынып эшләргә тиеш.

Матбугатта хәбәр ителгәнчә, 14-15 февральдә Әлмәт каласында Татар Халкы Милли Мәҗлесенең өченче чакырылыш өченче сессиясе, шулай ук "Тирә-як мохит һәм шәхес бөтенлеге" дигән темага фәнни-гамәли конференция булачак. Шушы уңай белән хәбәрчебез Заһид ШӘФИГЫЙ Милли Мәҗлес рәисе язучы Айдар ХӘЛИМГӘ берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.



Айдар ХӘЛИМ:

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

үрнәк дөнья булырга тиеш

– Айдар әфәнде, моңа кадәр Милли Мәҗлеснең сессияләре Казан каласында үтә торган иде. Чираттагы сессиянең Әлмәт каласында үткәрелүе бер вакытлы яңалыкмы, әллә үсеш тенденциясеме?

– Әйе, үсеш тенденциясе дип сез минем өчен җавап да бирдегез шикелле, Татар Халкының Милли Мәҗлесе, исеменнән күренүенчә, халык органы һәм халык белән эшләү формаларын тагын да тирәнәйтү, төрләндерү ниятендә киләчәктә үзенең сессияләрен Татарстанның аерым шәһәр һәм район үзәкләрендә үткәрә башлаячак. Моңардан хакимият тә отачак, чөнки без утырыш темалары итеп нәкъ шул төбәкләр өчен хас булган проблемаларны сайлап алачакбыз һәм аларны чишү юлында хакимият белән бергә чаралар эзләячәкбез. Әлбәттә, мондый форумнарны үткәрү җиңелдән түгел. Беренче чиратта, урындагы җитәкчелектән финанс ярдәме булмаган хәлдә, теләктәшлек булса да кирәк. Сессиянең Әлмәттә билгеләнүенең үзенең бер сәбәбе дә бар. Соңгы елларда "Татнефть" акционерлык җәмгыяте, гомумән Әлмәт җәмәгатьчелеге, тирә-як мохит һәм күңел мохите арасындагы дисгармонияне кыскарту, конкрет чаралар аша аларны бербөтен итеп якынайту буенча гаять зур эш башкарды. Милли Мәҗлес бу тәҗрибәне еллар буе күзәтеп барды һәм аерым чараларда үзе дә катнашкалады. Шуңа күрә, без гамәли конференциянең көн тәртибенә беренчеләрдән итеп "Татар дөньясын табигый һәм әхлакый тазарту юлында Әлмәт һәм Түбән Кама җәмәгатьчелекләренең уңай тәҗрибәсе" дигән мәсьәләне керттек. Докладлар белән Әлмәттән язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Разим Вәлиуллин, Түбән Камадан татар иҗтимагый үзәгенең җитәкчесе Хәлил Әюпов чыгыш ясаячак.

Гамәли конференциядә Фәүзия Бәйрәмова тарафыннан укылачак "Милләт, дин һәм хакимият" дигән доклад та ифрат зур кызыксыну тудырыр дип уйлыйм. Кыскасы, тема күптән билгеле: чишмәләрне тазарту, елгаларкүлләрне тәртипкә китерү, чокыр-чакырлар, юл буйларына урманнар утырту, тирә-як мохиттәге бозылган исемнәрне тарихи дөреслеккә кире кайтару, дини яңарыш аша адәм баласында җан азатлыгы конституциясен тудыру, аңарда яшәргә дәрт уяту. Ягъни татар дөньясы – үрнәк дөнья булырга тиеш. **"Үрнәк татар йортыннан үрнәк татар урамы буйлап үрнәк татар телендә – үрнәк татар дәүләтчелегенә"**. Безнең бу мәҗлеснең мәгънәсен менә шулай аңлатырга мөмкин булыр иде. Әйтегез, кемгә, нинди көчләргә куркыныч яный мондый гүзәл үрнәк? Беркемгә дә. Бәс, шулай булгач, эшләргә генә кирәк. Әйтегез әле, соңгы елларда Әлмәт төбәгендә ничә чишмә тазартылды, елгаларкүлләр тәртипкә китерелде, ничә милли мәктәп, балалар бакчалары, мәчетләр, гыйбадәтханәләр төзелде? Байтак! Ничә яңа һәм иске урамнарга безнең милли исемнәребез бирелде? Дистәләрчә! Нигә без моны күрмәскә тиеш? Бу бит кешене борчыган, аның күңеленә тынгысызлык биреп торган ясалма проблемаларны вакытында хәл итеп, җан тынычлыгы урнаштыру дигән сүз! Шуңа күрә безнең сессия кабул итәчәк резолюциянең беренче маддәсендә ачыктан-ачык әйтелә: **"Татнефть" акционерлык җәмгыяте коллективының, Әлмәт һәм Түбән Кама район һәм шәһәр хакимиятләренең, Әлмәт һәм Түбән Кама татар иҗтимагый үзәкләренең бергәләп халыкның үрнәк тормышыннан халыкның үрнәк дәүләтчелегенә ирешү юлындагы уңай тәҗрибәсен хупларга, бу тәҗрибәнең Татарстан җөмһүриятенең барлык дәүләт, хөкүмәт структуралары, оешма, предприятиеләре, авыл хуҗалыгы кооперативлары, күмәк хуҗалыклары, фермерлары, иҗтимагый хәрәкәтләр тарафыннан тирәнтен өйрәнелеп, барлык татар һәм халыкара дөньяга таратылуын тәэмин итәргә".** Мин күбрәк сөйләп ташладым бугай?

– Юк, юк, Айдар әфәнде, киресенчә. Сез мин бирәсе берничә сорауга алдан ук җавап биреп куйдыгыз. Сез сөйләгән нәрсәләр мәсьәләнең гамәли ягы. Ә аның фәлсәфи тәэмин ителеше ничек?

– Рәхмәт. Бу сорау кызык һәм хәтта кызганыч. Кайчакта кеше чишмә суын эчкәннән соң гына үзенең нинди чишмәгә юлыкканын аңлый. Мин дә аның никадәр тирән, никадәр вакытлы һәм дөрес, фәлсәфи яктан күпкырлы булуына бу эшкә тотынганнан соң гына төшендем. Алтын эзләүчеләр телендә "алтын тамырга тап булу" дигән төшенчә бар. Татар милләтендә "чишмә тазарту" эшенә керешү алтын тамырга төшү белән бер икән ул. Без әле гомер буе табигатьне талап яшәгән "табигый монополияләр"нең чынлап мохитне аякка бастыру эшенә тотынуын аңлый да башламаганбыз. Шулай итеп, мәсьәләнең фәлсәфи ягына килик.

Тирә-як мохит һәм шәхес бөтенлеге кешелек дөньясының иң кискен проблемасына әйләнде. Табигый байлыкларны "рациональ" файдалану табигатьне компсыз талауга, аны тәмам хәлсезләндерүгә кайтып калды. Ул Җир шарындагы яшәү балансына куркыныч яный башлады. Кем әйтмешли, "причем" монда татар да, причем монда "милләтчелек?" XX гасыр уртасында бу әхлаксыз күренешнең кешенең генетик нигезенә зыян китерәчәк глобаль нәтиҗәләрен алдан күреп алган көчле, бай, гакыллы һәм бар дөньяны үз кулында тоту өчен барысын да эшләргә тырышкан Көнбатыш демократиясе икътисад һәм сәнәгатьне зарарсызландыру юлында ашыгыч чаралар күрергә, табышының өчтән берен даими рәвештә тирә-як мохитне саклауга юнәлтергә мәҗбүр булды. Безнең күз алдында тормышка ашырылган чаралар кешелек тарихында беренче тапкыр Җир-Ананың мохит санитариясе фәнен һәм гамәлен булдырды.

Әмма бездә, Русиядә бу фән дә, бу гамәл дә була алмый калды. Бездә генә түгел. Империалистик коллыктан сәяси яктан котылса да, икътисади яктан котыла алмаган, икътисадның югары җитештерү формаларына ирешә алмаган "икенче" һәм "өченче" илләрдә, шул исәптән империалистик кысалардан әле дә булса котыла алмаган, киресенчә, шовинистик мунча исенә торган саен исерә барган Русиядә табигать әле булса кешене бар итүче феномен, кешенең гормональ чыганагы итеп түгел, әле дә булса оятсыз-чамасыз талау базисы буларак файдаланыла. Көнбатыш демократиясенең күз-колак булуы, аеклыгы җитмәү аркасында Русия территориясе бөтен Җир шарын пычрату, агулау кыйтгасына әйләнде. "Без коры җирнең алтыдан бер өлешен биләп торабыз!" дип күкрәк кагу үзенең империалистик асылын ачты да салды. Шулай итеп, бүген Русиядән килгән һава агымы, Русиядән аккан сулар агымы, Русиядән килгән сәяси агымнар, Русиядән килгән кайбер матди байлыклар нәкъ Русиядән агылган агулы, урланган акчалар кебек, барлык кешелек яшәешенә куркыныч яный торган үлем стимуляторына әйләнә башлады. Дөньяда котырып тамыр җәйгән "урыс мафиясе" нәкъ менә шуның белән бәйләнгән.

Әмма Русиядәге мохит әхлаксызлыгын Көнбатыштагы мохит әхлаксызлыгы белән чагыштырып булмый. Халыкның күпчелеге бөлгенлеккә төшкән, эшләгән акчасын да ала алмаган, алган хәлдә дә аны аракылата алган денсез шартларда Русия халыкларына 80 ел буе сеңдерелгән имансызлык, хуҗасызлык, хушкүңеллелек, бәйрәмчәлелек, мәгърифәтсезлек, телсезлек, дәүләтсезлек, кешене, аның рухын кимсеткән бөекдержавачыл шовинизм бездә җимерү гамәленең котчыккыч идеологиясен тудырды. Әүвәлдә кеше табигатьнең үзен җимерде, хәзер инде җимерелгән табигать җай гына һәм ышанычлы рәвештә кешенең үзен җимерүен дәвам итә. Бу бөҗра Русия аурасыннан таралган авыру буларак, барлык дөнья аурасына чир буларак тарала бара...

Әлегә үз дәүләтчелеген булдыра алмаган Татарстанның нефть сәнәгате – "Татнефть" акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге шушы авыр шартларда тирә-як мохитне – чишмә-болакларны, елга-күлләрне, урманнарны, гомумән кара туфраклы җиребезне үзләренең беренче сыйфатында аякка бастыру, халыкка кире кайтарып бирү юлында тирән һәм нигезле программа булдырып, нәтиҗәле эш башлады. Һәм соңгы 10 елда, күренекле белгечләр раславынча, бөтен дөнья масштабында өйрәнү мәктәбе булырлык хезмәт башкарды. "Татнефть" башлаган көрәш – тыныч көрәш, бөек көрәш, кеше өчен, кеше хакына башлангaн көрәш ул. Бу көрәшне бары тик бер милләт мәнфәгатьләренә генә илтеп ялгау өчен сәяси ахмак булырга кирәк. Кешедә шәхесне тәрбияләми торып, аякка бастырмый торып, кеше мохит бөтенлеге өчен көрәшмәячәк һәм киресенчә. "Татнефть" җәмгыяте бу бурычны комплекслы хәл итү бурычын куйды: шәхес һәм табигать – бербөтен; табигатьне саклау, яклау өчен телсезнең теле, денсезнең дене, җирсезнең җире, сусызның суы, димәк, илсезнең иле булырга тиеш. Безнең белән кем бәхәскә керә ала? Рәхим итегез! Әйдәгез, бергәләп эшлик! Татарстанның фәнни институтларының, Фәннәр академиясенең "Татнефть" тарафыннан тупланган бу дөньякүләм тәҗрибәне гомумиләштермәве мине шаклар катыра. Күтәреп алмавы аптырата. Алар күтәреп алмагач, инде менә без күтәреп алырга тәкъдим итәбез. Күтәреп алырга ярдәм итегез!

– Болар барысы да кызыклы. Әмма Милли Мәҗлес сессиясе һәм фәнни-гамәли конференциясенең программасы ошбу фәлсәфә белән генә чикләнерме?

– Сез безнең бу чараларның программасы турында сорыйсызмы?

– Шулай дип тә аңларга мөмкин.

– Бүгенгә Җир шарында моннан да зуррак фәлсәфә юк. Менә сезгә бер генә мисал. Моннан 10 елга якын элек без Чаллы ДАИ хезмәтенә: "Нишләп Чаллы – Казан трассасында Чаллы елгасы татарча да, урысча да "Река Челнинка", "Челнинка елгасы" дип язылып куелган?" – дип мөрәҗәгать иткән идек. Рәхмәт, Чаллының ДАИ хезмәте, безгә рәхмәт әйтеп, аны төзәтеп куйды. Хәзер күрсәткечләр болай язылган: "Чаллы елгасы. Река Челнинка". Аңлашыла, әйеме? Беркемне дә борчымый, дөрес, әйеме? Димәк, бу яшәүнең гармония балансын тудыра. Ә менә Чаллыдан Казанга барганда дистәләгән ялгыш атамалар әле һаман булса эленеп җанны әрнетеп тора. "Шумбутка елгасы. Река Шумбутка". "Омар елгасы. Река Омарка". Туктагыз әле, оланнар, бу нинди хәл? Соң бит Чаллы – Казан трактыннан көненә дистә меңләгән пассажир, шул исәптән меңләгән түрәләребез үтә. Алар нигә "шамбыртамый" бу Шумбуткаларны үткәндә? Нигә алар "омарламый"? Бик гади: алар борчылмый. Алар башкаларны да борчымый. Чөнки борчысаң, Шумбутканы балыклары белән шомбыртап торган "Шомбырт" елгасы дип, Омарканы Гомер елгасы дип язып элү өчен кемнедер кузгатырга, "фәлән тонна иген алдык" дип мактанган түрә бу атаманы алыштыру өчен бер-ике кисәк такта, ике йөз грамм буяу, аны эшлисе кешесен табарга тиеш була. Аннан соң, "вдруг" кемгәдер ошамаса?! "НИГӘ КАГЫЛДЫГЫЗ?!" дисә?! Алла сакласын. Менә бит без нинди үшән халык. Юк, Шумбутканы "Шомбырт"ка әйләндермәгез, дип Президент Шәймиевтән дә, Президент Ельциннан да күрсәтмә килмәгән! "Просто" кагылмыйбыз. Без – шундыйлар. Без, имеш, иген үстерәбез. Ә үстергән игеннең исемен ничек атау – бу инде сәясәт, "фидәрәтсия" бурычы. Без сәясәткә кагылмыйбыз, янәсе. Нәкъ Салтыков-Щедрин малайлары, билләһи газыйм!

Менә безнең шундый коллык психологиясеннән чыгасыбыз һәм милләтебезне чыгарасыбыз килә. "Причем" монда Русия һәм "Федерация составы"нда булу! Син әле үзеңнең кулыңнан килгән нәрсәне эшлә! Безнең сессиябезнең тоткан гамәле ул коллык сыйфатларыннан котылу хакына кыйлган гамәл...

– Инде соңгы сорау: сезнең сессия һәм конференция программагызниләрдән гыйбарәт?

– Безнең программа "Татнефть" һәм Әлмәт районы хакимиятендә яклау тапты. Конструктив эш хакына без аларга, алар безгә рәхмәтле булыр, дип уйлыйм. Программага килгәндә, ул файдалы: төшке аш вакытында Русиянең төрле почмакларыннан, Татарстанның төрле районнарыннан килгән депутатларыбыз һәм кунакларыбыз Әлмәт мәдәният учакларында, мәктәпләрендә, гимназияләрендә, балалар бакчаларында, мәчетләрдә булып, эш стиле һәм яңалыклар белән танышачаклар. Кичен Әлмәтнең сәнгать осталары һәм Милли Мәҗлеснең иҗтимагый эшлеклеләре, язучышагыйрьләр катнашында зур концерт булуы көтелә. Әлмәт ерак җир түгел. Казан зыялыларын көтәбез.

● Волгоград. 169 нчы укчы дивизия ветераннары һәлак булган батырларны искә ала. Алгы рәттә сулдан беренче М.Колсанов.

Бистә артында урман шаулый

Бистә артында гына урман шаулый. Буй җиткезгән төз наратлар Идел ягыннан туктаусыз искән җилдә чайкалалар. Вакыты белән яңгыр сибәли. Теңкәгә тигән көзге салкын яңгыр. Карт солдатның хәтерендә: теге чакта да яңа походка чыкканда биткә котсыз яңгыр бәрә, юештән шинель шешенә иде.

Михаил Владимирович тәрәзәдән урман ягына карап уйланып калды. Ул чагында авыр сугыш юлы үткән 169 нчы укчы дивизия Идел ярындагы Карабали төбәгендә ялга куелган иде. Кызылармеецлар оборона, маневр сугышларында нык йончыганнар, азга гына булса да сулу алырга, сирәгәйгән сафларны тулыландырырга телиләр иде. Сугыштагы мондый тәнәфес кече командирлар әзерләү өчен дә файдаланылды. Көннәр күбрәк тактик дәресләр белән үтә иде.

Дивизиянең 556 нчы укчы полкы составындагы 1 нче пулемет ротасы да байтак сугышчыларын югалткан, алдагы аяусыз бәрелешләр өчен аңа да ныгып алырга кирәк иде.

Бу рота Михаил Колсанов өчен бик кадерле. Ул Татарстанда төзелде. 1940 елның феврале иде. Яшь педагог авыл мәктәбендә укыта. Аны кече лейтенантлар курсына чакырдылар. Хәрби курс Аурупада күтәрелгән сугыш җилләрен искәреп куркусыз пулеметчылар хәзерли. Вакыт тар, укырга урта һәм югары белемле егетләрне генә алалар. Дәресләр кыскартылган программа буенча гына үткәрелә. Һәм ул 1941 елның мартында тәгәлләнде дә инде. Яшь Михаилны пулеметчылар ротасы составында резервтагы Киев аерым хәрби округына җибәрделәр.

1941 елның июне иде. Фашистлар Германиясенең безнең илгә һөҗүм итү куркынычы арта. Чик буе аерым округларының командирларына дивизияләрне алдан билгеләнгән план буенча чик буена тартып ныклы оборона оештырырга боерык бирелә. 169 нчы укчы дивизия дә Румыния чигенә якын китерелә. Михаил Владимировичтан сугышның беренче көне турында сорап куям.

– Безнең өчен ул Винницадан яшерен поход белән башланды, – ди ул. – Рота командиры пулеметчыларны күтәрде дә патроннар, сугышчан противогаз алырга боерды. Хәрби маневр башланасы икән дә, хәрби уен вакытында Прут елгасы буенда оборона тотарга туры киләчәк. Төнлә марш белән барабыз, көндез урманда туктыйбыз. Җәяүләп 50 чакрым уздык, Прут ярына җитеп ялга туктаган идек, урман аланында митингка чакырдылар. Сугышның башланасын белдек. Прут елгасы буенда инде атышлар бара иде. Румын гаскәрләре белән бәрелешләр купкан. Безнең пулеметчылар дошманның беренче самолетын бәреп төшерделәр...

Шунда тукталып уйланасы килә. Хәзерге сәясәтчеләр СССРның сугышка әзерлексез керүе, уяулыгын югалтуы, гаскәрләрнең булдыксызлыгы турында сөйләргә яраталар, бөтен бер державага гаеп ташлап маташалар. Ләкин сугышның башын да, ахырын да күргән карт солдат, дипломатларча тәгәллек белән үк булмаса да, сугышның якынаюын, аның аяусыз буласын белүләре, аңа әзерләнүләре турында дәлилләп аңлата. Хәтере алдамый. Ул партия үзәк комитетының 1940 елгы март пленумы карары белән үк Кызыл Армияне үзгәртеп кору һәм коралландыру программасының тормышка ашырыла башлавы, яңа укчы, танк, авиация дивизияләре оештыру, баш командованиенең резерв артиллериясен булдыру, кадрлар хәзерләү чараларын искә ала. Урта һәм югары белемле белгечләрдән оештырылган хәрби курс та шул чараларның берсе. Аннары резервтагы хәрби частьләрнең дә чик буйларына маневр ясавы, карт солдат сөйләгәнчә, гаскәрләрне төнлә билгеле план буенча күчерү үк хәрби уяулыкның булуын раслый. Гаскәрләрнең яхшы коралланган һәм Һитлер армиясенә беренче сугышта ук зур каршылык күрсәтүе дә игътибарсыз кала алмый. 169 нчы укчы дивизия дә сугышчан бурычларны уңышлы үти. Пулеметчылар ротасы башта ике тәртәле арбага, аннары машина өрҗәсенә парлап урнаштырылган пулеметлар белән дошманның авиация һөҗүменә каршы тора, укчыларга кыенлык булганда ярдәмгә килеп дошман танкларына да ата. Ә сугыш югалтусыз булмый. Хәтта бер мәл чигенү ачысын да татыйлар. 1 нче пулемет ротасы 169 нчы укчы дивизия составында Прут, Днестр, Днепр, Дон һәм башка елгалар бассейнында, Николаев, Харьков кебек эре шәһәрләр, стратегик яктан гаять әһәмиятле йөзләгән торак пунктларында көчле оборона сугышлары алып бара, дошманның бик күп хәрби техникасын юк итә.

Кыска ялдан соң дивизия ныгыган состав белән Иделне кичә. Сталинград оборонасында катнаша һәм таныла. Җиңүгә юл да Идел ярындагы шушы героик кала диварларыннан башлана. Михаил Колсанов та үзенең пулеметчылары – солдат, командир һәм политработниклар белән Сталинградны соңгы сулышка кадәр сакларга, дошманны Иделгә җибәрмәскә ант итә. Дивизияне иң җаваплы участокка куялар. Команда пунктында генерал Ф.Толбухин һәм А.Василевский булалар, тарихка кергән тиңдәшсез һөҗүм алдыннан генерал Г.Жуков командирлар белән гаскәрләрнең әзерлеге турында сөйләшә. Бу Сталинград оборонасына баскан һәр гаскәри өчен зур вакыйга була. Сталинград фронтына корал һәм өстәмә көчләр килә. Бу вакытта Татарстанның Идел аръягы районнары аша салынган, бер ел дигәндә өлгертелгән тимер юлның әһәмияте зур була. Шушы яңа һәм иң якын юлдан Сталинградка хәрби эшелоннар китә. Идел ярындагы җиңү шулай хәзерләнә. Сугышчылар дошманны тар-мар итеп зур чыныгу алалар.

Михаил Владимирович Бөек Җиңүгә илткән Сталинград сугышларыннан солдат батырлыгы турында күп истәлекләр саклаган. Ә мин Берлинда барган сугышның соңгы көне турында сорыйм. Ул, ашыкма әле дигән кебек, текәлеп карый. Чөнки Берлин операцияләренә кадәр 2 ел ярым фронт юлы үтәсе бар. Өлкән сержант Колсанов данлы дивизия составындагы пулеметчылар ротасы белән иң авыр сугышларда катнаша. Орел-Курски дугасы, Белоруссия, бигрәк тә Рогачев плацдармы өчен барган авыр сугышларны кем онытыр! Алар гаять катлаулы булды һәм күп корбаннар сорады. Днепр буендагы Рогачев шәһәре өчен көрәш аеруча катлаулы иде. Атака артыннан атакага күтәрелделәр. Пулеметчылар да шәһәр урамнарында дошман белән күзгә-күз очраштылар һәм җиңделәр. Шунысы истәлекле: Рогачев шәһәрен азат итүчеләр хөрмәтенә Мәскәүдә салют бирделәр. 169 нчы дивизия Рогачев исемен алды, укчы һәм пулеметчылары орден-медальләр белән бүләкләнде.

Дивизиянең юлы җиңүле, бүләкләре байтак. Аның солдатлары гел ут эчендә кайный. Укчы дивизия Белоруссиядә Волковыска шәһәрен азат итүдәге батырлыгы өчен Кызыл Байрак орденына лаек була. Шунысы кызыклы һәм куандыргыч, 1944 елның июлендә Мәскәү урамнары буйлап Белоруссиядә әсир ителгән 57600 нимес солдаты һәм офицерларын үткәрәләр. Алар арасында 169 нчы дивизия укчыларына һәм пулеметчыларына теш-тырнаклары белән каршы торган һәм җиңелгән әсирләр дә күп була. Алар сугыш кырында кулларын күтәреп соңгы сүзләрен әйтәләр: "Һитлер капут".

Ә совет солдатлары Көнбатышта җиңүле һөҗүмнәрен дәвам иттерәләр. Варшава өчен барган сугышларда данлы дивизиянең Байрагына батырлык символы булып II дәрәҗә Суворов ордены беркетелә. Дивизия өченче – II дәрәҗә Кутузов орденын Көнчыгыш Пруссия өчен барган канлы бәрелешләрдә ала. Ул Кенигсбергтан көньяк-көнбатышта дошман гаскәрләрен тар-мар итүдә гаять зур хәрби осталык күрсәтә. Дивизия махсус хәрби йомыш үтәгәч, яңадан I Белоруссия фронтына кайта. Бу 1945 елның 30 марты була. Данлы дивизия, аның укчы һәм пулеметчылары Берлин операциясенә тартыла.

Михаил Колсанов сугыш хроникасын бәян итүдән туктап калды. Аның өчен гаять кыен әңгәмә иде бу. Сугыш юлы гел җиңүдән генә тормый, аның чакрымнарында фронтовик дусларыңны югалту хәсрәте дә чәчелгән – шунысын кичерүе кыен. Ә сугышның соңгы көне истәлегенә килгәндә, Михаил Владимирович болай ди:

– Минем өчен ул 30 апрель иде. Партия-комсомол эшен үтим. Дивизия гәзитенең мөхәррире бәйрәм санын әзерләүдә катнашырга чакырды. Урамнарда, рейхстаг тирәсендә каты сугышлар бара. Солдатларның күңел күтәренке, ни әйтсәң дә, дошманны үз өнендә кыйныйлар! "Ура" тавышлары да күк яңгырый. Ә бу вакытта инде безнең дивизия, безнең Татарстанда оешкан данлы рота Одер юнәлешендә хәрәкәт итә, ул сугышны Америка гаскәрләре белән шул елгада дустанә очрашып тәмамлады. Дивизия туган илгә 1945 елның августында әйләнеп кайтты...

Вакытлыча өзелгән хезмәтне тыныч күңел белән дәвам итәргә мөмкин иде. Михаил Владимирович күкрәгенә сугышчан орден һәм медальләр тагып кайтты, яңадан да Кайбыч районының Ульянково урта мәктәбендә эшли башлады. Фронтовик педагогның беренче әңгәмәләре укучылар һәм авыл кешеләре күңелендә хәзер дә истәлек булып саклана. Аның кадерле реликвияләре белән дә танышалар. Хәрби командованиедән дистәләгән рәхмәт: Сталинград героик оборонасында катнашкан өчен таныклык һәм медаль, Рогачев, Бобруйски шәһәрләрен азат иткәндә, Нарев елгасының көнбатыш ярында нимес оборонасын өзгәндә, Көнчыгыш Пруссия шәһәрләрен алганда, Кенигсбергтан көньяк-көнбатышта нимес гаскәрләре төркемен тар-мар иткәндә оста һәм батыр хәрәкәт иткәне өчен Сталин рәхмәтләре. Ә Берлин өчен Рәхмәт грамотасын аеруча кадерләп тота ветеран. Ул сугыш юлының соңгы чакрымы өчен батыр солдатны хөрмәтләп бирелгән.

Михаил Колсановның педагогик эшчәнлеге дә хөрмәтләнә. Ул укытучы хезмәтен 1938 елда башлый, район мәгариф бүлеге мөдире дә була. Соңгы, пенсиягә кадәрге 25 елында Кайбыч районының Федоровски урта мәктәбендә директор хезмәтен башкара. Бер үк вакытта районда, авылда зур тәрбияви эш алып бара. Аны "Почет билгесе" ордены белән бүләклиләр, "Татарстан мәктәпләренең атказанган укытучысы" исеменә лаек була. Ә иң кадерле бүләк – йөзләгән укучылар һәм ата-аналар рәхмәте. Михаил Владимирович мәктәпнең оста педагоглары белән укучыларга ныклы белем бирә. Үз гаиләсендә дә җәмәгате, танылган педагог, "Почет билгесе" ордены иясе Зинаида Сергеевна белән өч бала үстерәләр. Берсе полковник дәрәҗәсенә күтәрелә, икенчесе әйбәт геофизик булып үсә, өченче улы Сережа мәгълүмат органнарында актив эшли. Педагогның гаиләсе дә башкалар өчен үрнәк булып тора.

Еллар үткән, ләкин заяга түгел. Әмма ул бистә артындагы урман шаулаганда тәрәзәдән карап еш уйлана. Шаулап торган Украина, Белоруссия, Польша, Балтыйк буе урманнарында бик күп сугышчан дуслары ятып калды бит. Көзге боек җилдә чайкалучы наратлар гүя шул хакта искә төшерәләр: "Онытма, солдат, сугышчан дусларыңны. Онытма!" – диләр. Ә карт солдатның онытырга хакы юк.

Мәрди РАФИКОВ,
үз хәбәрчебез.

● М.Колсанов гаиләсе белән.

Кызарып пешкән җиләкләр Изелә учларында...

Нәҗибә САФИНА

Әй туган тел

Әй туган тел, бәйләнгәнсең
Җанымдагы һәрбер хискә.
Фани дөнья йөзләрендә
Мин эшләгән һәрбер эшкә.

Әй туган тел, бәйләнгәнсең
Уйларымның һәр очына.
Хәтта бәйсез дип уйланган
Зәңгәр күкнең һәр кошына.

Әй туган тел, бәйләнгәнсең,
Тамырларга бәйләнгәнсең;
Син аларны яшәтүче
Яфракларга әйләнгәнсең.

Бәйләнгәнсең искән җилгә,
Тәпи баскан туган җиргә.
Әйләнгәнсең Иделемнән
Җанга аккан олы җырга.

Әй туган тел, бәйләнгәнсең
Урамга да, Уралга да;
Себерләрне Себер иткән
Ап-ак карлы буранга да.

Бәетләргә бәйләнгәнсең,
Әкиятләргә әйләнгәнсең.
Мәңгелеккә бару юлын,
Туган телем, шәйләгәнсең.

Әй туган тел, әй генәм лә,
Җанны җанга, җирне җиргә,
Җырны җырга, серне сергә
Бәйли торган бәй генәм лә!..

Дөнья үзгәрми

Беренче укытучым
Хафәсә Габдулла кызы
Йосыповага

Каралардан кара ике толым,
Ай-кояштай иде йөзләрең.
Шикәр генә, бал гына да түгел,
Зәмзәм суы әйткән сүзләрең.

Зифа сыннарыңа сузылып төшкән
Толымнарың иде сер тулы.
Кыйгач кара кашлы моң дингезе —
Ул күзләрең иде җыр тулы.

Чия иреннәрең иркә иде,
Ах, китәргә җирдән иртә иде.
Уттан — суга, судан утка салып,
Бу язмышлар сине йөртә иде.

Хафизәлә түгел, Хафәсә апа,
Зөләйхалардан син чибәр идең.
Йосыф үзе күрсә, таң калыр да
Мәхәббәттән газап чигәр иде.

Син күкләргә күтәрелдең инде,
Андый җаннар җиргә инәмени?!
Юк, башкача һич тә була алмый —
Гүзәллекне үлем җиңәмени!

Тик мин генә мәңә син кушканга
Авызымны "А-а-а" дип ачкан хәлдә.
Кычкырамын: "А-чы! А-чы дөнья!"
Ай-яй дөнья, үзгәрми бит әл дә...

Ни буласын бел

Өзелә кайчак юллар,
Нихәл итәсең.
Урау юллар белән һаман
Алга китәсен.
Өзелә кайчак бәгырьләр,
Нихәл итәсең.
Үз җаныңны үзең ямап,
Гомер итәсен.
Өзелә кайчак уйлар да,
Нихәл итәсең.
Уйсыз гына һаман юлың
Дәвам итәсең.
Сөйләп торган сүз өзелә
Кайчак телендә.
Әмма сүзең дәвам итә
Йөрәк түрендә.
Уйлар, юллар, бәгырьләр дә
Өзелә, өзелә.
Туган тел өзелмәсен дип,
Һаман түзелә.
Җан белән шушы дөньяны
Бәйләп тота тел.
Туган телең өзелә калса,
Ни буласын бел!..

Зинданнарга салма утны

Җаныма ут салучы син, -
Читлеккә яптың утны.
Инде сүндермәкче булып,
Тырышма да син юкны.

Ут ул зинданны кичерми,
Күчәчәк үз җаныңа.
Әле ваемсыз йөрисең,
Киләчәксең аңыңа.

Читлектә дә ут бит ул,
Сөймәгәннәр юк бит ул.
Зинданнарга салма утны,
Ут кадәрле ут бит ул!

Миңа — синсез, сиңа — минсез
Фани дөнья юк бит ул...

Киңәш сораучы гашыйк хәле

Мәхәббәттән ул исергән,
Башын югалткан иде.
"Бер киңәш бир, нихәл итим,
Шашып яратам!" — диде.
Күзләренә карап тордым —
Мөлдерәр яшьләр иде.
Шундый сөюнең барлыгын
Мин аңлар яшьтә идем.
"Чынлап яратсаммы, — дидем, —
Югалтмас идем аны!"
Шулчак... аның тарафына
Чыкты да очты җаны.
Иләс-миләс сөйләнде дә
Очты да китте күккә.
Җәяү йөргән икән, юләр,
Җиткәнче соңгы чиккә...

* * *

Кызарып пешкән җиләкне
Учыңа җыясыңдыр.
Җиләк түгел, учларыңда
Кузлар дип тоясыңдыр.

Җиләкләрне җыясыңдыр,
Чирәмгә коясыңдыр.
Тагы ашый алмады, дип,
Җаныңны кыясыңдыр.

Җиләкләр ачы түгелдер,
Ачыдыр хатирәләр.
Үч иткәндәй, җилләр синең
Уйларны китерәләр.

Инде шушы җиләкләрне
Ашыйсы иде бергә, —
Сөюдән китү мизгеле
Җитә икән гомергә...

Кызарып пешкән җиләкләр
Изелә учларында.
Җиләкләр кызарып пешә
Мәхәббәт утларында.

Төшләр эзләп кайтам

Төш иде бу: мине башка
Берәү кочмакчы булды;
Мине кочып, ләззәт сутын
И татымакчы булды.
Әллә инде шул мизгелдә
Мин дә дәртләнеп киттем, —
Аһ оят, тик дулкынланып,
Аның кочуын көттем.
Дәрт учагы яктырттымы —
Анык күрдем йөземне.
Укталдым әйтмәкче булып
Карышулы сүземне.
Шайтан көзгесендә күрдем —
Дөрләп кабынган йөзем.
Кая сүзләр — инде аны
Мин башлап кочтым үзем.
Әмма гөнаһ кылынмады —
Күңел капкасы бикле.
Син кайттың да ачып кердең
Ишеккә салган бикне.
Төш иде бу. Тик барыбер
Син коткардың афәттән...
Көткәнсендер, күзләреңне
Алмый алсу шәфәкъгән.
Җаныңнан да якынрак
Килә алмыйм бит инде.
Бу төш кенә, өннәремә
Кайтып керәлмим инде.
Анда син юк! Нигә өннәр —
Кайтасым килми өнгә.
Төшләр генә эзләп кайтам
Мин синсез буп-буш өйгә...

Хәбәр җибәрмә

Бер көн миңа хәбәр килде,
Ул синнән ваз кичкән дип;
Аның җаны, синнән чыгып,
Башкаларга күчкән дип.

Җаныма дәшеп карадым —
Җаным буш дала кебек.
Тавыш бирмәде бит хәтта
Адашкан җанвар-киек.

Хәбәр китергән җилләрне
Куып йөрим далада.
Җанны ачар бер кеше юк
Шундый олы калада...

Әгәр син миннән ваз кичсәң,
Зинһар, җибәрмә хәбәр!
Җаныңны тоеп яшәрмен
Соңгы көнемә кадәр.

Шигырь — нечкәлек билгесе белән языла

ХАЛЫК ХӘТЕРЕН ЗОЛЫМ

Кулыма каләм алгач ук, 1963 елдан бирле, мин Гаяз Исхакый белән гел-гел очрашып тордым.

Гаяз Исхакыйның исемен дә телгә алырга куркыныч чакта, инде Галимҗан Ибраһимов иҗаты турында дипломнар, диссертацияләр яклый башланганда Салих Баттал әйткән иде:

– Татар әдәбиятының иң бөек, иң олуг әдибе Гаяз Исхакый булыр! – дигән иде.

Әмирхан ага Еники дә ул елларда, берәрсе ишетеп тормыймы, дигәндәй як-ягына каранып алганнан соң:

– Татарның иң олы язучысы Гаяз абзый Исхакый! – дия торган иде.

Шушы ике олы әдипнең Гаяз Исхакыйга биргән бәясе безнең, яшь язучыларның күңеленә кереп урнашты. Ләкин үз күзләребез белән укып, үз кулларыбыз белән тотып карарга китап түгел, мәкаләсе дә юк иде. Чышын-пышыннан ары без Исхакый турында мәгълүмат ала алмадык.

Солженицынны эзәрлекләгән кебек эзәрлекләнгән чагында да Салих Баттал Исхакыйны халык аңында тергезергә азапланып карады. Ул үзенең архивыннан бер фотосурәт табып ала да, "Казан утлары"ның тәнкыйть бүлеге мөдире Фәрваз Миңнуллинга китерә:

– Карале, Фәрваз, менә монысы Галимҗан Ибраһимов инде боларның, ләкин менә монысын, хет үтер, танымыйм, кем икән ул? Бәлки, бастырып чыгарырсыз да, бу кешене танып алучы табылыр, Галимҗан янында утырып, кәртечкәгә төшкән икән, ул бәләкәй кеше түгелдер, – ди.

Фәрваз сурәтне алып кала да, билгесез шәхесне ачыклау өчен, рәсемне берничә олы агаларыбызга күрсәтеп карый. Ләкин берәү дә аның кем икәнен әйтә алмый. Сурәт Нәкый Исәнбәткә барып җитә.

– Бәй, – ди Исәнбәт. – Бу бит Гаяз Исхакый.

Шулай итеп, Фәрваз сурәтне хуҗасына кайтарып бирә.

– Баттал белгән ул аның Исхакый икәнлеген, – ди Фәрваз. – Хәйләкәр карт, абайламыйча бастырырлар да, шул рәсем тирәсендә гауга кубар, Исхакый рәсеме, Исхакый исеме халыкка таралыр, дип уйлаган ул.

Шул рәсем басыла калса, башлар очмаса да, байтак кына кешеләр урынынан оча иде, аның караве, халык Исхакыйның кем икәнен белеп кала иде.

Фәрваз да, Салих абый да мәрхүмнәр инде. Ул сурәт кайда икән, Галимҗан Ибраһимов яки Гаяз Исхакый музеенда ул рәсем үз урынын алсын иде.

Шул мохиттә, җае чыккан саен, КГБ яраннары, партия бурзайлары Гаяз Исхакыйга өрә, аның исемен каралтканнан-каралта тордылар. Эт өрә торыр, кәрван йөри торыр, дигәндәй, нинди генә тыюларга карамастан, Исхакый әкренләп безнең күңелләргә керә барды.

Бары тик 1974 елда гына мин Исхакыйның һәм мәгънәви, һәм әдәби яктан таптым. Азнакай төбәгендәге Чалпы авылында мин Әнвәр Әхмәдиевләр йортына төштем. Олы яшьтәге хуҗабикә миңа:

– Син, улым, үзебезчә укый беләсеңме? – диде.

Мин гарәпчә укый алганымны әйттем. Тәрәзәләргә караштырып алганнан соң, хуҗабикә минем алга шактый калын төенчек китереп куйды. Ашъяулыкны чишеп, мин беренче китапны кулыма алдым. "Мөхәммәд Гаяз Исхакый" дигән сүз авызымнан очып чыкмасынмы. Бу аның "Зиндан" исемле китабы иде. Икенче китап "Алдым-бирдем" пьесасы булып чыкты. Калтыранган кулларым белән мин тагын тарихка орындым: минем кулда Гаяз Исхакыйның "Мөгаллимә" драмасы, "Кәләпүшче кыз" әсәре, "Өч хатын белән тормыш" пьесасы иде...

Әнвәрнең атасы Фатих Әхмәдиев йортына бу китапларны Сарман ягының Кәшербаш авылы кешесе Миңлекамал Гарипова тапшырган булган. 1902-1908 елларда басылган әлеге китаплар яхшы сакланган, яңаклары һәм текстларның каләм белән билгеләп куелуыннан күренеп тора: китапларны күп кеше укыган, бу пьесаларны күп тапкырлар сәхнәдә уйнаганнар. Кайбер китапларда китап хуҗаларының исемнәре дә язылган: Нурулла, Нурлыгаян.

Шулай итеп, миндә Гаяз Исхакыйның берьюлы биш әсәре пәйда булды. Хуҗабикә ул китапларны миңа бирде. Җиргә күмгәнче, ятларга калганчы, укый белә торган кешегә булсын, дигәндер инде. Казанга кайтуга ук мин "Зиндан"ны хәзерге хәрефләргә күчердем, машинкадан чыгарып куйдым. Җае чыгу башлауга ук мин әсәрне "Казан утлары"на илтеп бирдем. Ләкин аны бастыручы булмады. Ул шул килеш журнал архивында ята булыр.

Пьесаларның берсен хәзерге хәрефләргә күчереп, машинкада бастырып, берничә дустыма бирдем.

1989 елда Финляндиягә баргач, Мәәззәс ханым, алырмы-юкмы, дигәндәй сынаулы карап, миңа төрекчә язылган китап сонды, бу – 1955 елда Гаяз Исхакый вафатының бер еллыгы мәнәсәбәте илә Истанбулда чыгарылган "Милли мөҗәһит вә милли әдип Гаяз Исхакый" дип аталган хатирәләр китабы иде. Исхакыйның төрле елларда төшкән рәсемнәре, аның мөһаҗирлектәге дуслары, ватандашлары язган хатирәләр, Исхакыйның иҗаты һәм ватанының азатлыгы өчен көрәшү, тарихы турында мәгълүмат урнаштырылган иде. Алдагы биш китабы һәм менә шушы хатирәләр җыентыгы Исхакыйның кем икәнен ачып бирә иде кебек. Минем алда Гаяз Исхакый дигән могҗизалы дөнья ачылганнан-ачыла барды. Кешеләрдән ишетелгән имеш-мимеш белән генә түгел, мин Гаяз Исхакыйны тотып карап дигәндәй белә башладым.

Һельсинки уртасындагы мәчеттә бөтен голәмага хәбәр салдылар, 24 июнь иде: Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт ханым бүген Анкарада вафат булды, диделәр. Мәчеттәге 300ләп кеше җеназа намазы укыды.

Төркиягә баргач, мин тагын Гаяз Исхакый белән очраштым. Акышлар гаиләсе миңа Исхакыйның Төркиядә чыккан "Өйгә таба" исемле романы белән "Мөхәммәд Гаяз Исхакый, хәяте вә фәгалияте" дигән китап бүләк итте. Шулай итеп, мин каләмдәшләремнән байтакка алда Исхакый дөньясы белән таныша алдым. Һәм үзем күрә кечкенә генә ачышлар да ясаштыргаладым. Мәсәлән, соңгы аталган китаптан мин Тукайның "Мөхәррирга" дигән шигыренең Гаяз Исхакыйга атап язылганлыгын белдем. Гаяз Исхакый алты ел сөргендә булганнан соң иреккә чыга, ләкин Казанга кайта алмый, аңа рөхсәт юк, беркайчан да Исхакыйны күрмәгән, ләкин аның иҗатына гашыйк Тукай аңа багышлап мәдхия яза. Шигырь бүген язылган диярсең.

И мөхәррир! Кайсына биргән
яшен күз кибрия!
(Яшен кебек бөек күз күреше – Р.Б.)
И мосавир! Кемгә биргән
пакь вә чын сүз кибрия!
(Чын бөек сүз сөреше – Р.Б.)
Кайт әле монда ватанга, кайт әле,
саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир
тапмасынчы кер, рия!
Алты елда үзгәреп китте
логать һәм истилях,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә
сәүдәдер зыя.
Җанлырак тормыш та бетте,
шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче
елдагы күп әүлия.
Алты ел торды чупансыз
(көтүчесез – Р.Б.),
аерылышты яшь көтү:
Карт бүре кук, бары корган
айрым-айрым бер оя.
"Ул Гомәрдән курка шайтаннар"
дигән төсле рәсүл,
Бер карашның иң шома
ялганчысын сүздән тыя...

Бу шигырь басылып ике-өч атна узуга, Тукай вафат була. Ике бөек – Исхакый белән Тукай фани дөньяда очраша алмый кала.

Мәхмүт ага Ураллы сөйли. Ул Икенче бөтендөнья сугышында Алманиядә әсир калган. Үзе Урал якларыннан икән. Алманиядән Төркиягә күчеп килгән. Төркиядәге татар җәмәгатьчелегенең иң эшлекле кешеләреннән берсе Мәхмүт агадыр. Ул Төркиягә күчеп килгән көнне танышу кичәсендә Гаяз Исхакый да була. Утырыш башланганда Исхакый әйтә:

– Җәмәгать, әфлисун ашый-ашый сөйләшсәк, һәйбәтрәк булыр, – ди.

Әфлисун алып кайтыр өчен яшь җегет Мәхмүт Ураллыны җибәрәләр. Мәхмүт, Төркиягә яңа гына килгән кеше, күп нәрсәне белеп бетерми, урамга чыга да беренче очраган сатучыдан күп итеп әфлисун алып кайта. Алып кайта да юып өстәлгә куя. Һәркем әфлисун алып ашый башлый. Әфлисун капкаларының чырае сытыла, кемдер:

– Бә-әй, җәмәгать, бу әфлисун өшегән ич, – ди.

ыннан да, бөтен әфлисуннар да

Чөшегән булып чыга. Әче әфлисунны чүплеккә ташлап, чәй эчә башлыйлар. Шулчак Гаяз Исхакый Мәхмүтнең аркасына кулын куеп:

– Аптырама, Мәхмүт энем! Шулай югалта-югалта табарсың! – ди.

Бервакыт Исхакыйның өенә искәрмәстән кунаклар килеп керә. Өйдә ашарга ипи, җыярга җимеш, эчәргә чәй булмый. Кунаклардан берәү, әлеге дә баягы Мәхмүт Ураллы:

– Хәзер, Гаяз абый, үзем кибеткә йөгерәм, – ди.

– Утыр! – ди Гаяз Исхакый. – Үзем йөгерәм.

Шулай дип, хуҗа балконга чыгып керә дә кунаклар янына утырып гәп кора, сөйләшә башлый. Бар да гаҗәпләнә: нишләп Гаяз әфәнде кибеткә китмәде? Аларның гаҗәпләнүенә җавап итеп, Исхакый:

– Әфсен-төфсен, ризык килеп төшсен! – дип сөйләнә-сөйләнә янә балконга чыга һәм дә бер кәрҗин ашамлыклар күтәреп керә. Баксаң, Исхакый бау бәйләп астагы кибеткә кәрҗин төшергән икән. Кибетче аның бу гадәтен белеп, бөтенесен тәяп куйган да Исхакый шуны тартып алган икән.

Мәхмүт ага Ураллы Исхакый белән бик еш очраша торган була. Соңгы елларда әдип бик бетерешә. Берчак гадәте буенча Гаяз абзый Мәхмүткә:

– Һәйди, энекәш, бер гүләйт итеп кайтыйк әле, – ди.

Алар Гаяз Исхакыйның яраткан ресторанына китәләр. Исхакый Мәхмүт өчен бик тәмле ит ризыклары китертә, үзенә сөтле аш сорап ала. Әлек ит ризыкларын бик тәмләп ашый торган Исхакыйның сөтле аш китертүенә гаҗәпләнеп, Мәхмүт сорап куя:

– Хуҗам, бу ни эшең? – ди.

– Ашказаным рөхсәт итми, арыды бугай, – ди Исхакый.

Шуннан соң озак та тормыйча, Гаяз Исхакый ашказаны авыруыннан вафат була.

Сәйдә ханым Акыш сөйли:

– Без Кытайдан монда күчеп килдек. Без Төркия ватандашы. Илле елдан артык монда, төрек арасында яшибез. Әмма телебезне сакладык. Хәер, сез төрекләшүдән курыкмагыз. Сез урыслашудан куркыгыз... Корбан, фытыр бәйрәмнәрендә без төрле илләрдәге туганнарыбызга, танышларыбызга котлаулар юллый идек. Ул котлаулар ел саен гел бер төрле сүзләр белән языла иде: корбан бәйрәме мөбарәк булсын. Киләсе бәйрәмне хөр ватаныбыз Идел-Урал җөмһүриятендә каршы алырга язсын!.. Менә, Батулла әфәнде, шулай гел-гел олы өметләр белән яшәде читтәге татарлар... Безне шулай уйларга, шулай өметләнергә Аяз абый Исхакый өйрәтте.

Сүзгә Нәҗия ханым Акыш кушыла:

– Әти-әни һәрвакыт аңлата иде безгә бала вакытта ук, анда безнең ватаныбыз бар, дия иде... Безнең туфрагыбыз анда. Кытайда чакта ук Тукай шигырьләрен өйрәндек, динебезне сакладык, татарчабызны онытмадык, ата-бабаларыбыз, урыннары җәннәттә булсын. Гаяз абый кебек бөекләребезнең исемнәрен, әсәрләрен өйрәнеп үзебезне саклый алдык, Аллага шөкер. Хөр ватан, хөр милләт зиһенен Исхакый остазыбыз тәрбия кылды.

Шуннан соң Акышлар гаиләсе миңа тагын бер китап бүләк итте. "Русиядә Беренче мөселман корылтае" исемле китап ул. Бу корылтайда Гаяз Исхакый сигез тапкыр чыгыш ясый, җыелышны алып бара. Аның чыгышлары ялкынлы, ихлас һәм алар һәрвакыт алкышка күмелә торган була. Бу беркетмәләрдә Исхакыйның милләтпәрвәрлеге ап-ачык күренә.

Гаяз Исхакый милләт өчен көрәштә гаять кырыс һәм катгый булса да, холкы белән бик шаян җор кеше була. Атасы турында Сәгадәт ханым менә бу вакыйганы язып калдырган.

Атаклы галим Галимҗан Барудиның хатыны үзен сәедләр, пәйгамбәрләр нәселеннән, дип сөйли торган була. Ягъни аның нәселе борынгы ата-бабасы, имештер,



"Бай углы" китабының титул бите. Өстә – Г.Исхакыйның үз кулы белән язылган автографы.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Хөсәеннән килә икән. Бер мәҗлестә бер шаяны Галимҗан Барудидан сорый:

– Хәзрәт, ничек соң ул сәедләр нәселеннән булырга мөмкин? – ди.

Баруди кыен хәлдә кала, ул җавапка әзерләнгәнче, Гаяз Исхакый әйтеп куя:

– Дөрес, хәзрәти Мөхәммәд салаллаһу галәйһиссәлам үзе дә мишәрләрдән чыккан бит!

Галимҗан Баруди барысыннан да артыграк көлә:

– Тапкыр сүз Гаяз бәйнең мәсләге инде ул, – ди.

Төркиядә мин Гаяз Исхакый каберен эзләп киттем. Без Чаллы җегетләре белән идек. Әдирнә капы шәһидлеге зиратына барып кердек, ләкин кабер санын белмибез. Эзли киттек, сигезебез сигез яктан барабыз. Юк, һич кенә дә табып булмый.

Шулчак бер төрек агасы безне туктатып, нәрсә эзләгәнебезне сорады. Җавабыбызны ишеткәч, төрек кардәш:

Монголиягә китеп үлә. Әйттеләр, Корбангали урыс яклы татар гаскәрендә меңбашы (майор) булып хезмәт иткән икән, совет гаскәрләрендәме шунда. Ул Япониягә советлардан качып килгәнме, белмим. Исхакый, әлбәттә, советларга каршы кеше иде. Аларның бәхәсе шул бугай. Исхакый Япуниядә чакта безнең өйдә кунакта булды. Аның туган көнен безнең өйдә уздырдылар. Матур кеше иде ул, шәфкатьле булганга матур күрендеме, белмим...

Халкыбызның атаклы артисты Фәйзи ага Йосыпов хатирәсе:

– Минем горур исемем Фәйзи Йосыпов түгел, мин Йосыф мулла углы Фәйзерахман булырмын. Мин Чистай ягының Гаяз Исхакый туган Яуширмә авылы малае. Аллаһының сөеклесе – Фәйзерахман исемен миңа Гаяз Исхакыйның әтисе Гыйлаҗетдин хәзрәт куйган. Гаяз Исхакый энисе Камәрия абыстай ягыннан безгә туган тиешле кеше. Исхакыйның энисе минем әбием

Сара Әхмәрова ул вакытта Казанның иң гүзәл кызы саналган. Гаяз Исхакый генерал утарында атна чамасы кунак була. Казанга кайткач, ул генералларны халык язмышына карата битарафлыкта гаепләп язып чыга. Генерал гаиләсендә шушы мәсьәләдә байтак кына сүз, канәгатьсезлек булганын сөйләде Заһидә ханым. Бу мәкаләнең кайсы гәзиттә басылганын Заһидә апа атый алмады. Бер атна эчендә Заһидә туташ белән атаклы язучы Исхакый утар бакчасында, урманда бергә йөриләр, һәм алар гел бәхәсләшә торган булалар. Заһидә апа Аурупа, урыс мәдәниятен мактый, Исхакый исә татар милләтчесе, мондый ике капма-каршы кеше тыныч кына сөйләшә аламыни? Ләкин Исхакыйның әүлиялеге Заһидә апаның исендә калган. Генерал өендә спектакль уйнаганда Заһидә апаның уйнавына Исхакый бик тә югары бәя бирә һәм аңа актриса булып китәргә киңәш итә. Исхакый милләт мәсьәләсендә дә Заһидә туташ күңелендә алда шытачак орлык салып калдыра. Заһидә апа татар театры артисты булып китә.

күрүчеләр бар, алар да Усманов сүзен кабатлый иде. Аллага шөкер, Исхакыйның исеме дә, җисеме дә тегеләр үлгәнче үк дөньяга чыкты. Исхакый үз бөеклегенең күтәртмәсенә менеп басты. Инде аны хәзер әнчекләр, бурзайлар гына куркыта алмас.

Сармандамы ул, Азнакайдамы, Финляндия, Төркиядәме, Кытай яки Америкадамы, Япуниядәме – Җир шары буйлап Исхакый рухы йөри, Ленин рухы түгел, Исхакый рухы йөри. Аның рухы милләтпәрвәрлек, татар халкы өчен фида булырга тору, ватан азатлыгын шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую. Исхакый бу максатына тугры калды. Менә Гаяз Исхакыйның үлеменә өч көн калгач Финляндия имамына язган соңгы хаты.

"Хөрмәтле Хәбибрахман хәзрәт, мин 26 майдан бирле Анкарадамын. Бераз хастаханәдә яттым. Хәзер кызымда торам. Аллага мең шөкерләр булсын, кызым белән киявем мине бик яхшы карыйлар. Алардан бик

ДУЛКЫННАРЫ ДА ЮА АЛМЫЙ

– Ә-ә, беләм мин аның каберен, ул безнең Ататөрек шикелле кеше, шулаймы? – дип безне туп-туры Гаяз Исхакый кабере янына алып килде. Иң башта мәрхүмнең рухына дога кылдык. Чаллы дусларыма мин Исхакый турында белгәннәремне сөйләдем. Җегетләрнең күзләрендә яшь иде. Чаллы җегетләре бу мизгелләрне кинога да төшереп алган иде. Аларда саклана булыр.

Кабер ташына: "Идел-Урал төрекләренең коткарылыш хәрәкәте рәһбәре. Тәңре рәхмәте илә М.Аяз-Исхакый-Иделле. Казан 1878 – Анкара 1954" дип язылган.

Вакытында чит илгә китмәгән булсаң, Гаяз абзый, синең кабереңә килеп баш ия алмаган булыр идек.

Америкада яшәүче кардәшләребез дә Исхакыйның рухын, исемен, әсәрләрен кадерләп саклый. Аннан да мин Исхакыйның ике әсәрен алып кайттым – "Солдат" исемле романын һәм "Бай углы" әсәрен. Соңгысының тышлыгында Исхакыйның үз кулы белән: "Фуат Әмин бәк җәнабларына мөхәррирдән бүләк, 1904 ел, апрель..." – дип язылган.

82 яшьлек Гөлчирә ханым Дашки хатирәсе (Сан-Франциско, 1997 ел):

– Шулай матур гына Япониядә яшәп ята идек, берзаманны Аяз Исхакый килде. Ничектер Корбангали (Япуниядә яңа ачылган мәчет имамы) аны яхшы каршы алмады, бүленделәр. Ул (Корбангали) халыкны яхшы гына алып бара иде. Аннан соң Аяз Исхакый килгәчтен, ничектер аңа каршы килеп, аны (Исхакыйны) үтертә яздылар. Шуннан халкыбызның берсе Корбан яклы булды, икенчесе Аяз Исхакый яклы булып китте. Шуннан соң Аяз абзый озак тормады. Ул тиздән качып китте. Аны үтерергә япун кешеләрен җибәргәннәр, дип сүләделәр. Җомга намазыннан чыгып барганда аны буа башлаганнар, халык коткарып калган, япунский гродскийлар, ягъни бандитлар инде. Исхакыйны качырдылар. Мин кеше сүләве буенча гына сүлим, яшь идем, шәкерт кенә идем әле ул вакытта. Шуннан соң Исхакый Кытайга китте. Шуннан соң ничектер Корбангалинең үзен дә япуннар кулга алды. Урыс ышпиуны дип аны Кытайга сөрделәр, ул аннан

белән бертуган. Исхакыйның энесе Хәсән абзый минем беренче хәлфәм иде. Мин аңарда укый башладым. Икесе бертуган булсалар да, Хәсән абый белән Гаяз абзый бер дә охшаш түгел иде. Гаяз абзый сары кеше иде ул, аксыл кеше. Хәсән абзый анасына охшаган, каракучкыл иде. Бер көнне Хәсән абый бәйрәмчә киенеп, дәрескә бер сары абзыйны ияртеп керде.

– Менә, балалар, бу кеше минем абыем Гаяз Исхакый була инде. Ул да сезне укыта башлар.

Гаяз абзый баштан сыйпап кына дәрес аңлата торган иде. Билге урынына ул безгә кечкенә генә конфетлар бирә иде. Сабагын яхшы белгән кешегә бер конфет. Шул конфетны алыр өчен иң ялкауларыбыз да тырыша-тырыша укый идек. Гаяз абзый безне озак укытмады. Каядыр китеп барды. Шулай итеп, бүген мин, Гаяз Исхакыйда укыган кеше, дип мактана алам. Конфет миңа күбрәк эләгә иде, мин шигырьләрне күп ятлый идем, шигырьләрне матур итеп укыганым өчен ул минем башымнан сыйпый иде... Хәсән абзый Гаяз Исхакый кызы Сәгадәт белән мине Чистайга алып китте. Ул мине детдомга урнаштырды, мин ятим калган бала идем. Сәгадәтне алып чит илгә озатыр өчен ул Ташкентка китте. Аннан әйләнеп тә кайтты. Мин каникуллар вакытында авылга, Хәсән абыйларга кайтам, шунда торам, алар мине кеше итте, укытты, рәхмәт. Гомерем буе мин Исхакыйлар гаиләсенә бурычлы, рәхмәтле булдым. Хәсән абыйны алып китеп аттылар. Юкка чыкты ул.

Заһидә Тинчурина истәлекләреннән.

Заһидә ханым 1913 елның җәендә
Әгерҗе төбәгенең Шаршада утарын-
да генерал Шәех-Гали йортында Га-
яз Исхакый белән очраша. Күрәсең,
Гаяз Исхакыйның сергеннән соң ха-
лыкны өйрәнер өчен сәяхәт иткән
вакыты булгандыр. Заһидә апа
Исхакыйның мәһабәт кыяфәтле,
бик мәгърур торышлы, күзәтүчән
кеше икәнлеген сөйли. Заһидә апа-
ны күрүгә үк Гаяз Исхакый:

– Сез, туташ, Сара Әхмәрованың сеңлеседер, – ди.

– Дөрес, мин Шаһбазгәрәй кызы, – ди Заһидә. – Ләкин без апам белән бер дә охшаш түгел, сез ничек шулай таный алдыгыз?

– Күз карашларыгыз охшаш, – ди Гаяз Исхакый.

Заһидә апа 1922 елда Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәтне Ташкентта укыта. Сәгадәтне шуннан Төркиягә алып китәләр. Байтак еллар узгач, Заһидә апа исеменә Төркиядән хат килеп төшә. Сәгадәт Исхакыйдан. Заһидә апа җавап язмый. Шомлы вакытлар җиткән була. Икенче хатына да җавап бирми. Хәсән Исхакый:

– Заһидә ханым, Сәгадәт синең язмышың белән бик кызыксына, яз инде шуңа бер-ике сүз, – ди.

Заһидә апа барыбер җавап язмый. Хәсән Исхакыйны алып китәләр. Бераздан соң Кәрим Тинчурин да үз исеменә Төркиядән хат ала. Кәримнең кәефе нык китә. Бу хат Гаяз Исхакыйдан була. Исхакый Кәримгә: ташла шул коммунистлар оясын, син бит бик талантлы кеше, ятма анда талантыңны әрәм итеп, сифилитик Ленинның...(сүз атыюлы белән язылган була) шул нәрсәсен ялап, ди.

– Нишлим икән? – ди Кәрим.

– Черек күлгә илтеп бир, – ди Заһидә ханым.

– Юк, мин моны редакциягә илтәм, – дип, Тинчурин хатны алып чыгып китә. Кайтканда хаты булмый. Ләкин юлда аңа Хөсәен Уразик очрый. Күрәсең, Кәрим шул хатны Уразикка укыткан, чөнки Уразикның сеңелләре, Тинчурин капиталистлардан ярамаган журналлар алып, укып ята, дип дөнья буйлар. Шуннан соң инде Тинчуринга театрда да гел бәйләнә башлыйлар. Ахырда, юк-бар сылтау табып, аны театрдан куалар.

Гаяз Исхакый турында рәсми төстә беренче сүзне язучы Марсель Гали әйтте, шул ук җыенда Әмирхан ага Еники Гаяз Исхакыйның мирасын халыкка кайтару турында җитди сүз кузгатты.

Гаяз Исхакыйны менә шулай ха-
лык куркыта торган бүкәй, карач-
кы итеп тоталар иде ул заманнарда.
Табиләр, фасиләр, батыйлар, усма-
новлар гына аның рухын басып сы-
та алмады.

– Татар халкының иң олы, берен-
че номерлы дошманы – Гаяз Исха-
кый! – дип тәкрарлый иде партия
өлкә комитеты беренче секретаре Ус-
манов. – Мин исән чакта Ис-
хакыйның исеме дә чыкмас!

Алар гына түгел, татар язучылары арасында да Исхакыйны дошман

канәгатьмен. Минем хәлем бер дә яхшы түгел...Берәр могҗиза булмаса, бу айда яки атна эчендә соңгы сулышымны алачакмын. Мин мөселман ата-анадан тудым вә мөселман буларак тәрбия күрдем. Кануни караштан мин төрекмен. Һичбер төрек халыкларына дошманлык кылмыйча, төрек-татар халкының баласы буларак, халкымның сәгадәте вә бәхете өчен бөтен гомерем буена көрәштем. Бу эшләрне башкарганда һичбер төрек халкына зарар китермәдем... Үз арамыздагы татарлык, башкортлык, мишәрлек вә нугайлык юлларына кермәдем. Кулымнан килгәнчә тар кабиләчелектән качтым. Минем фикеремчә, Татарстан белән Башкортстанны бер-берләреннән аерыр өчен, икесен дә бергә туплый торган Идел-Урал милли идарәсен юк итәр өчен иҗат ителгән совет шайтанлыгыннан башка һич нәрсә юк. Минем ышануыма күрә, Совет кул астында ыңгырашучы кырык миллион төрекнең алга таба конфедерация шәкелендә берләшүе, ул да булмаса, Уртак культура берлеген югалтканчы, ягъни уртак культурага ия буларак, Аурупа берлегенә тигез хокуклар белән керүе, Аурупа гаиләсендә шәрәфле урын алуы иң дөрес юл булачактыр. Тәңре сезләргә бәрәкәтле тормышта яшәп, ватаныбыз Идел-Уралның азат булуын күрергә насыйп итсен дип, догада калам. Аермаенча бөтен мәхәллә әгъзаларына соңгы сәламнәремне юллыймын. Хөрмәтләр белән...Аяз Исхакый. Өстәмә сүз: бу хатны Алиулла Акыш исемле милләтче җегетебез язды, чөнки үземнең хат язарлык көчем юк. Язылганнарны минем фикерем буларак кабул итегез. Али Акыш минем иң ышанычлы ярдәмчем. Сәламләр белән...Аяз Исхакый".

Гаяз Исхакый 1917 елның 1 маенда Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда чыгышын болай тәмамлый:

– Көчле вә куәтле булыгыз, вак-
төяк эшләрне онытыгыз, һәртөрле
кечкенә мәнфәгатьләрегезне, үтеп
китә торган мәнфәгатьләрегезне ал-
дыбыздагы эшебезнең бөеклеге ха-
кына фида итегез. Мин сезне бөек
милләт исеменнән көчлелеккә вә
бөеклеккә чакырам!

Рабит БАТУЛЛА,
Гаяз Исхакый исемендәге
бүләк иясе.

XYI-XYII йөздә Болак пароходлар, баржалар йөрерлек елга була. Казан ханлыгы яулангannнан соң, Болакның сул ягында 1554-1556 елларда Татар бистәсе оеша башлый. Ул елларда Казанда барлыгы 7-8 бистә була. XYIII йөз урталарында бу төбәктә иң күпчелек халык – татарлар була. Патша хөкүмәте, үзенең кирәге өчен, ясак түләүче татар крәстиәннәренең кайберләрен хәрби хезмәткә, кайберләрен төзелеш эшләренә чакыра.

1718 елда Петр I кушуы буенча Казан адмиралтействосы төзелә башлый, анда иң күп эшчеләр татарлар була. Мәсәлән, 1750 елда 10770 ясак түләүче татарның барысы да адмиралтейство эшләренә куылган. Ясак түли алмаганнарын Казан тирәсендә төзелә башлаган адмиралтейство участогына куып китерәләр. Алар Казан тирәсендәге калын имән урманын кисеп, киселгән бүрәнәләрне адмиралтействога ташыганнар. Чөнки ул чорда Идел-Каспий флотилиясе төзелә башлый. Пристань Казансу елгасының Иделгә кушылган тамагында булган, һәм "устье"ны татарчалаштырып "усия" дип йөрткәннәр.

Ясаклы татарларның бер өлеше – Яңа Бистәдә, икенче өлеше адмиралтейство тирәсенә йорт салып хуҗалык итә башлый. Хәзерге Киров районындагы "Адмиралтейская Слобода" шул мәҗбүри куып китерелгән татарлар җирләшкән төбәк.

Соңыннан алар Усиядә авыр йөк ташучы булып эшләгәннәр.

Яңа Бистәгә сәфәр тарихы

Татарларның тормышы авыр булган. Аларның бер өлеше һөнәрчелек белән көн күргән. Ирләр кием-салым, бүрек, читек-кәвеш, корама бүрек теккәннәр. Һөнәрләре булмаган ир-атлар байларга йорт сакчысы, урам себерүче, ат караучы, кучер булып ялланганнар. Хатын-кызлар тегү теккәннәр, түбәтәй, кәләпүш, такыя, каттаҗи эшләгәннәр, чиккәннәр.

Ул чорда Яңа Бистә халкы яшелчә, җиләк-җимеш үстермәгән, яшелчә үстерүне марҗалар эше дип караган. Үзләре бер бау суган, бер баш кәбестә яки бер дистә кыярны да Балык базарына барып сатып ала торган булганнар.

Ярлыларның сыеры – кәҗә булган. Кәҗәне һәрбер гаилә күпләп асраган. Ләкин кәҗә тиресен эшкәртү – күн ясау турында уйлап та карамаганнар. Бу эш соңрак киң колач ала. Ә хәллерәк татарлар сыер асрый башлаган.

Әбиләр: "Яңа Бистә – Алла каргаган урын, шуңа анда кешеләрне сөргәннәр", – дип зарлана торган булган. Чөнки Яңа Бистәнең ике ягы да сазлык, өченче ягында шәһәрнең чүплеге булган. Шунлыктан Яңа Бистәнең һавасы авыр, начар исле булган. Җәй җитсә чебен-черки баскан, малярия авыруы таралган. Авыр тормыш туберкулез, рахит авыруларын да китереп чыгарган. Хатын-кызлар арасында камыт аяклы кешеләр шактый күп булган.

"...Кәкре аяклы, кыйгач кашлы
Яңа Бистә кызлары..." -

дигән шаян җыр шуннан калган булса кирәк.

Яңа Бистәдә чисталык, арулык та җитеп бетмәгән. Ярлы татар гаиләсенең бөтен өй җиһазы – сәке, ул аш урыны да, ял итү, йокы урыны да булган. Шәһәр Думасы Яңа Бистә татарларының тормышын яхшырту, авырулар белән көрәшүне кирәк дип тә санамаган. Анда бер медпункт та булмавы шуны раслый.

Октябрь революциясе алдыннан Яңа Бистә хәле түбәндәгечә сурәтләнә: биредә 3000 кеше яшәгән. Өч мәхәлләдә 3 мәчет, 4-5 мәктәп-мәдрәсә, 3-4 ашамлык кибете һәм көянтәсен бер тиенгә сата торган (халык телендә "фонтан" дип йөрткәннәр) бер суүткәргеч кран була. Татар халкын куркытып торучы насыйр бутышнигы (городовой), бер камчылы ишаны, бер сукыр җырчы-шагыйре һәм бала дөньяга килгәндә ярдәм итә торган кендек әбисе "әҗәтче" Гафифә әби һәм башкалар булган.

Яңа Бистә кешеләре үзләре яшелчә үстермәгәнлектән, ашаган ризыклары да күбрәк он-камыр ризыклары булган. Токмач, өйрә, ботка, тары, карабодай ярмасыннан, бәрәңгедән кыстыбый, коймак, тәбикмәк, бәрәңге, бәрәңге боламыгы, талкан кебек ризыклар белән туенганнар.

Үзләре бик кунакчыл, кешелекле булганнар, йомыш белән кергән кешене дә чәй эчермичә чыгармаганнар, күтәренке күңелле, дәртле, уенчак кешене ачык йөз белән каршылый торган булганнар.

1552 елдан алып, XYIII йөзнең урталарына чаклы Казанда янгыннар бик еш кабатланып торган: 1579, 1672, 1684, 1742, 1749, 1842, 1847 елларда көчле янгыннар чыккан. Бу янгыннарның 1749 елдагысы аерата дәһшәтле булган. "Кызыл әтәч" Пеләтән урамыннан башлап Татар зиратына, Яңа Бистә ягына барып чыккан. Хәтта Болак күпере дә янган.

1749 елгы янгында гөбернә канцеляриясе, дәүләтнең кыйммәтле архивының бер өлеше янып зыян күрә. Берничә кеше дә янып үлә. Менә шушы янгын Яңа Бистәнең барлыкка килүенә сәбәпче булган.

Янган татарларга үз урыннарына яңа йорт салырга рөхсәт ителмәгән. Рөхсәт бирүдә губернаторның уң кулы булган, татарларны көчләп чукындыруда даны чыккан, халык арасында "Аксак Каратун" кушаматлы әрхәрәй Лука Канашевич сәясәте өстенлек алган. Аксак Каратун татарларга Идел белән сазлык арасындагы ярымутрауга күчәргә боерык бирдерә. 300ләп татар ярлы-ябагасы күчәргә мәҗбүр була. Шуннан Пеләтән ягындагы татарларга "Иске Татар бистәсе", ярымутрауга күчкәннәргә "Яңа Бистә" дип исем кушканнар. Иске Бистәдән күчеп киткән татарларның йорт-җир урынын байларга, купецларга сатканнар, монах-монашкалар өчен йортлар һәм чиркәү салырга биргәннәр (мәсәлән, хәзерге Г.Камал театры тирәсен).

Яңа Бистә татарлары яз-көз айларында батачума йөргәннәр. Ә шәһәргә язгы ташу вакытларында көймә белән чыкканнар.

1773-1775 елларда булган Пугачев явына авыр тормышта изелгән, патша чиновниклары тарафыннан өзлексез мыскылланган Яңа Бистә татарлары бик теләп катнаша. Тарихи язмалардан күренгәнчә, Пугачев явына Яңа Бистәдән генә түгел, Иске Бистәдән дә, Татарстан территориясенең бик күп төбәкләреннән төрле милләт вәкилләре катнашып китәләр.

1774 елның 12 июнендә Пугачев Казанны алган. Яңа Бистә халкы Пугачевны сый-хөрмәт белән каршылый. Пугачев солдатлары – урысы, татары, башкорты – бергәләп кунак булып йөриләр.

Бу яуга катнашучыларның күбесе авыр тормышта яшәүче крәстиәннәр, кара эшчеләр булган. Яңа Бистәдән 1771 елда рекрутлыкка алынмаган Исмәгыйл Туктамышев Казан адмиралтействосы аша флотка җибәрелгән. Ул үзенең иптәшләре Раим Якуповның, Рәхимкул Әбүкәримовның Пугачев явына катнашып киткәнен ишетә дә, флоттан качып китеп, Пугачев явына кушыла. Бераздан Исмәгыйл Туктамышев Пугачевта писер булып эшли башлый.

Фетнәне бастыручы хөкүмәт армиясе ягында да татарлар була. Шундыйлардан Иске Бистәдән – 18 кеше, Яңа Бистәдән 9 кешене Пугачев солдатлары үтерәләр.

Пугачев явына чукынган өчен ясак түләүдән азат ителгән керәшеннәр дә катнаша, чөнки аларның да тормышы бик җиңелдән булмый.

Пугачев явында актив катнашкан һәм командир дәрәҗәсенә күтәрелгән татарлар да бар. Мәсәлән, Канкаев, Кананай, Моратов, Арсланов һ.б.

Пугачев явына катнашучыларның саны 50 меңгә җиткән. Восстание рәхимсез бастырыла. Кулга алынып җәзаланып үтерелүчеләрнең саны 11552гә җиткән. Шулардан Казан гөбернәсеннән 4526 кеше һәлак булган.

Иске һәм Яңа Бистә халкы авыр тормышта изелеп яшәп, укымыйча калган. Әгәр бала хәреф танып, сүзләрне укый белсә, ягъни ибтидаи мәктәптә "Иман шарты"н, "Һәфтияк шәриф"не укый башласа, аны грамоталы санаганнар. Ләкин ата-аналар моның тормыш таләпләренә туры килеп бетмәвен аңлап, үзләре кебек балалары да надан калмасын дип, Яңа Бистәгә укымышлы мулла-хәлфә эзли башлыйлар.

XYIII йөзнең башларында Яңа Бистәнең бер мәчетенә имам һәм хәлфә итеп, Көек авылыннан Әмирхан мулланы чакырып китерәләр. Ул бик тырыш, укымышлы мулла булып чыга, балаларга тирән белем бирә. 1815 елларда Яңа Бистәдә ике катлы зур мәктәп салдырып балалар укыта. Ул мәктәпнең беренче катында ибтидаи (башлангыч), 2 нче катында рөшди (урта белем бирүче) класслары оештырып, балаларны үзе укыта.

Бу мәктәп бинасы хәзер дә саклана: Зайцев урамы, 2 нче йорт. Мәктәпне шул вакытта ук "Мәдрәсәи Әмирхания" дип йөртә башлаганнар, һәм ул буыннан-буынга шулай "Мәдрәсәи Әмирхания" булып сакланып килгән. Әмирхан мулладан соң аның улы Хөсәен мулла, аннан соң оныгы Зариф мулла (Фатих Әмирханның әтисе) укыткан.

1873 елда хәзерге Меховщиклар урамындагы Кондратьев йортында урыс-татар классы (училище) ачыла. Аны татар мәгърифәтчесе Ибраһим Терегулов оештырып җибәрә. Аны КТУМда укытучы итеп билгеләгәч, Терегулов урынына кызы Әминә Терегулова эшли башлый. Революциядән соң училище 13 нче мәктәпкә кушыла.

XX йөз башында, Зариф мулла, уллары Ибраһим белән Фатихны шул училищены тәмамлаткач, шул чорның алдынгы мәдрәсәсе "Мөхәммәдия"гә укырга бирә. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе 1882 елда Галимҗан Баруди (Галиев) тарафыннан төзелгән. "Мөхәммәдия" күп кенә күренекле галим-белгечләр әзерләп чыгарган. Мәсәлән, биредә Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Касыйм Туйбактин, Кәбир һәм Фазыйл Туйкиннар, Бакый Урманче, Вафа Бәхтияров, Камил Якубов һ.б. укыган.

Татарларны Яңа Бистә ягына көчләп куган вакытта да тормышлары яхшы, укымышлы татарларны Иске Бистәдә – Пеләтән ягында калырга, йорт салырга рөхсәт иткәннәр.

1910-1915 елларда татар бистәләре ягында 20гә якын төрле типтагы уку йортлары, мәктәп-мәдрәсәләр булуы билгеле.

Аларның 17се – саф татар мәктәп-мәдрәсәләре булган. Тик аларның тарихы әлегә тулысынча өйрәнелмәгән. Хәтта КТУМ, "Мөхәммәдия", "Иж-Буби" мәдрәсәсе кебек мәктәпләрнең тарихы да нигезле рәвештә тулы өйрәнелмәгән.

Хәзер Болакның сул ягында Казан дәүләт педагогия университетында, күпсанлы гомуми уку мәктәпләрендә, төрле типтагы училище, техникумнарда, татар гимназияләрендә, лицейларда белгечләр әзерләнә. Спорт сарае, стадион, тимер юл вокзалы, елга порты корылмалары барлыкка килде. Дини-әхлакый тәрбия алу да алга китте. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе яңадан эшли башлады. Шушы телгә алынган төбәкләребездә генә алты мәчеттә гыйбадәт кылулары шуны раслый.

Вәли ХАҖИЕВ,
ветеран укытучы.

Мөхәммәт МИРЗА

БЮРО АЛДЫННАН

(Хикәя)

Иртәнге өч белән дүрт арасында ике "УАЗ" машинасы, фараларын балкытып Кирмәнле авылына килеп керде һәм сыер фермалары каршына ук килеп туктады. Үзләрен каршылаучы күренмәгәч, ике шофер берьюлы машиналарының сигналларын бөтен көчкә акырта башладылар. Ул да булмады, икенче булып туктаган машинаның түбәсеннән зәңгәр-кызыл нурлар чәчеп, коточкыч тавышлар чыгарып, сирена улап җибәрде. Төн уртасында сыер бозаулатып, арып кергән каравылчы Гафурҗан карт мичкә терәлеп утырган җиреннән изрәп йоклап киткән иде. Гадәти булмаган ят тавышка һәм балкышка сискәнеп уянып, корт чаккандай сикереп торды да тәрәзәгә капланды:

– Анасына төкерим, әллә фермага ут капканмы тагын? – дип, мич авызына кибәргә куйган олтанлы киез каталарын да kияргә онытып, каравыл өенең ишекләрен бәреп, тышка йөгереп чыкты. Милиция машинасын янгын машинасы белән бутапмы, тамагын ярып:

– Пожар! – дип сөрән салды.

– Нинди пожар булсын, ахмак, әллә айнып җитмәдеңме, исерек баш?

Милиция начальнигы Әхмәевнең ачулы карашы сирена тавышыннан да, хәтта чын пожардан да куркынычрак тоелды каравылчы картка. Тегесе исә кызганнан-кыза барды:

– Йоклыйлар рәхәтләнеп! Райкомның беренче секретаре белән милиция начальнигы кырык чакрымнан килеп бастылар, алар йоклап ята, понимаешь, кайда председателегез, кайда зоотехник, ферма мөдире кайда? Бәхетегез, элекке заман түгел!..

Элекке заманнарны подполковник Әхмәевтән яхшырак белсә дә, Гафурҗан кайтарып бер сүз әйтмәде. Ул арада, кар-бураннарын туздырып, чанасына баскан хәлдә, атын көчкә-көчкә тыеп, ферма мөдире Әхнәф килеп туктады. Тире бияләйләрен тиз генә чанага салып атты да, чанадан сикереп үк төшеп, райкомның беренче секретаре Нуруллинның каршына килеп басты. Тегесе авызын ачып сүз әйткәнче, кулларыннан алып, селки-селки исәнләшә башлады.

– Председатель кайда? – дип атты соравын беренче секретарь, кулларын Әхнәфтән тартып алган уңайга.

– Өендәдер ул, йә икенче бригадада. Кичтән безнең фермада булды.

– Булды-булды! Шушында кунып калса да таманга туры килер. Нишләдегез сез, ә? Ник сөтегез узган елгыдан ике йөз граммга ким? Ел башыннан кем шул кадәр сөт киметә?

– Ни бит... ашату дигәне такырырак бит, иптәш Нуруллин.

– Үзенеке ничавамы соң, ашау-эчү дигәннәре?

Хәлнең уен-муен түгеллеген аңлый башлаган каравылчы, әллә үзенең кар өстендә оекбаштан басып торудан аягы туңа башлап, әллә кирәкне-кирәкмәгәнне күрмәвең хәерлерәк дипме, йөгерә-атлый каравыл өенә кереп китте.

– Бар, хәзер үк председательне, партком секретарен, авыл Советы секретарен чакырып кил! Юк, үзең белән алып кил, – диде Нуруллин милиция начальнигының сүзләреннән соң коты алынып басып торган Әхнәфкә.

– Сохариларын алырга онытмасыннар, – дип өстәде подполковник Әхмәев. Милиция начальнигы "Беренче"нең "Коминтерн" колхозы председателен бик өнәп бетермәвен, аңа юкка-барга бәйләнүен белгәнгә күрә, бүген үзенең "Беренче"гә җаны-тәне белән тугрылыгын күрсәтү мөмкинлеген тулысынча файдаланырга булды.

– Менә, монда куйганнар бер пешмәгәнне, – дип дәвам итте "беренче", – ни эчми, ни йөрми, ни эше бармый. Кыскасы, бүгеннән дә соңармыйча акылга утыртасы булыр. Син, иптәш подполковник, алдан сөйләшкәнчә хәрәкәт ит! Мин "Трудовик"ны барып уятып кайтам. Иртәнге тугызда киңәйтелгән бюро утырышы, бу егетең, утырышка кадәр тәти егет булсын.

Нуруллин черт иттереп төкереп куйды да, "УАЗ"игына кереп утырды. Февраль иртәсенең, дөресрәге төненең чыгар-чыкмас буранын икегә аерып, "УАЗ"ик "Трудовик"



колхозына юл алды. "Трудовик" рәисе, яшьлегенә барып, "Коминтерн" рәисенә ияреп, кирәкмәгән сүзләр ычкындыра башлады, дигән хәбәр алган иде ул, ялдан кыйтырkайтмас ук. Барыр, күрер, күзенә туры карап бер генә сүз әйтер. Әйтеп аңламаса, бюрога куяр. Алай да аңламаса, подполковник Әхмәевкә тапшырыр... Сүз сөйләргә бар да остарды. План үтәү, җир белән, кешеләр белән эшли белүче генә азаеп бара...

– Габдулла Нуруллович, хәерле иртә!

– Хәерле була шул чакта, кайчан "Трудовик" чын "Трудовик" була! Урып-җыюны кар яуганга кадәр суздың, инде кыш уртасында ашарыңа калмаган.

– Терлекләр күп бит, Габдулла Нуруллович.

– Күп булсын! "Коммунизмга"ның, "Алга"ның баш саннары кәгазьдәгедән ике тапкыр артык. Шуңа да алар бер сыерга биш мең килограмм сөт савалар. "Коминтерн" белән сез өч меңгә дә җиткерә алмыйсыз. Җитмәсә, узган елгыдан тагын да түбәнрәк тәгәрәмәкче буласыз. Мин егерме көнгә ялга киткән идем, районны тәмам сүтеп бетергәнсез.

– Хәлне җайга салдык, Габдулла Нуруллович, "Коммунизмга"ның, ит сату исәбенә, илле сыерын алып кайттык. Сөт кимеми, арта башлады. Ит планын үтәү авыр булыр, сөт планын, Габдулла Нуруллович, һичшиксез үтәячәкбез. Сөт буенча сезнең күрсәтмәләрегез бик урынлы булып чыкты.

– Мин ялда чакта "Коминтерн" белән бик хәтәр дуслашып алгансыз дип ишеттем. Чамала! Абыеңның колагы зур, күзләре күп...

– Дөрес информация түгел, Габдулла Нуруллович. Сәлимнең хатыны белән минем хатын техникумда бергә укыганнар. Узган атнада хатынының туган көненә дәшкәч, барган идек, шуннан ары очрашкан да, сөйләшкән дә юк. Бүтән чакырсалар да бармаячакбыз...

– Бу хакта аерым сөйләшербез. Бүген, иркен сулап, курыкмыйча бар бюрога. Күршеләрең табада сикергәндә ял итеп утырырсың, аңладыңмы?

– Аңладым, Габдулла Нуруллович, ашыкмасагыз, чәйләп чыгыйк, Габдулла Нуруллович?

– Башка вакытта. Мин иртәдән чәйгә керергә яратмыйм, без киттек.

– Киңәшләрегез өчен рәхмәт, Габдулла Нуруллович!

Тиз генә җыеп алып килергә кушсалар да, Әхнәф тиз генә җыя алмады түрәләрне. Биек урыс капкасын эчке яктан бикләгән авыл Советы рәисе капкасына чыбыркы сабы белән сугуны да, аяк белән тибеп шакылдатуны да ишетмәмешкә салышты. Кышлау бозау хәтле эте, чылбырын өзәм-өзәм дип бәргәләнеп, өрә-өрә хәтта тамагы карлыгып, чинап, елый башлады.

Әхнәф бер уңайдан партком секретаре өе капкасын шакыды. Анысы, алдагы көндә зур бюро буласын белеп, кичтән үк район үзәгенә китеп, шунда куна калган булып чыкты.

"Председательләрнең өй тәрәзәләреннән яктылык күренә, уятып торасы юк икән", – дип уйлап алды Әхнәф. Атын яндырып дигәндәй килеп туктауга, капкаларын ачып Сәлим үзе килеп чыкты.

– Анда килгәннәр! – диде Әхнәф, аты урынына үзе чабып килгәндәй тыны бетеп.

– Ишеттем. Гафур абзый шалтыратты. Икешәр машина белән төн уртасында нишләп йөрүләрен генә аңламадым.

– "Беренче"дән бигрәк, погонлысы ямьсезләнә. Харап, ул гына кеше. Сәлим, бер сүз әйтми чанага менеп басты да, авылның теге очында, төрле-төрле утларын әйләндереп, авылның бөтен этләрен котыртып өрдергән машина ягына китеп бардылар.

– Ай-һай, озак йоклыйсыз, егетләр, озак йоклыйсыз. Без беренче секретарь белән бөтен районны әйләнеп чыктык. Ә сез һаман да йокыгыздан уяна алмыйсыз.

– Без иртәдән кичкә кадәр эштә. Хәтта балаларны күрә алган юк. Эшкә киткәндә йоклап калалар, кайтуга – йоклап киткән булалар. Бүген исә, ун минут та йокламадым. Ничек кенә тырышсам да йоклап китә алмадым. Тыңлыйм сезне, Мирзариф Сәүбәнович.

– Сөтең юк, понимаешь, узган елгыдан ике йөз грамм ким савасыз. Район күрсәткечен бер-ике баскычка күтәрәсе бар, понимаешь, конференция елы!

– Сөтне узган елгыдан нәкъ бер килограмм күбрәк савабыз. Үзегез бик яхшы беләсез, мин зыянга эшли торган тармакны тагы да киңәйтергә җыенмыйм. Баш санын арттырып, качышлы уен уйнарга һич кенә дә теләгем юк.

– Тукта, тукта, слушай. Ник әле син миңа лекция укый башладың?! Миңа синең лекцияң кирәк түгел, – дип ысылдауга якын пышылдауга күчте милиция начальнигы, – утыр машинага, киттек.

– Кая?

– Районга?

– Мин үземнең машина белән бара алам.

– Үзеңнең машина үзе барыр, син минем машина белән барасың, "Беренче" шулай кушты!

– "Беренче" сезгә кушкан, миңа кушмады. Миңа кушса да, үз машинам белән барыр идем.

– Йә, йә?!

– Нәрсә йә, йә?

– Сәбәбе?

– Миңа хезмәтемне башкару өчен машина бирелгән, мин ул машина белән барам, сез мине милиция машинасына салып алып китмәкче буласыз.

– Алып китеп нишлим мин синең белән? Дөресен генә әйткәндә, пычагымамы сөтең, үзең... Беләсеңме, күпме җинаять ачылмый ята?

– Беләм. Никадәрле җинаять ачыл-

(Ахыры 12 нче биттә).

Тамаша залларына чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

А.Мөбәраков исемендәге Сибай башкорт дәүләт драма театры гастрольләре

13 февраль – *"Өйләнү" (Н.Гоголь)*

14 февраль – *"Тылсымлы курай" (З.Биишева)*

15 февраль – *Театрлаштырылган тамаша-концерт*

17 февраль – *"Гөргөри кияүләре" (Т.Миңнуллин)*

18 февраль – *"Йөрәк маем" (Т.Миңнуллин)*

19 февраль – *"Хуҗа Насретдин" (Н.Исәнбәт)*

20 февраль – *"Сөяркә" (Т.Миңнуллин).*

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

15 февраль (көндез) – *"Алтын алма" (Ш.Фәрхетдин)*

15 февраль (кич) – *"Игълан буенча өйләнү" (В.Константинов, Б.Рацер, Б.Нәҗми һәм Ә.Гобәйдуллина тәрҗемәсе)*

18 февраль – *"Син бит минем бер генәм" (И.Мәхмутова)*

19 февраль – *"Гайфи бабай, өйлән давай!!!" (Г.Зәйнашева)*

20 февраль – *"Бәхетле килен" (Х.Ибраһим).*

Зур концерт залы

14 февраль – *Татарстан Дәүләт симфоник оркестры концерты. Программада В.Моцарт, Р.Шуман, С.Барбер, О.Респиги әсәрләре. Солистка – Мариам Джива Женье (Австрия). Дирижер – Т.Камалов*

15 февраль – *Ф.Шаляпинга багышланган музыкаль кичә. Ф.Шаляпин репертуарындагы арияләр, романслар, җырлар, урыс һәм чит ил классикасы әсәрләре башкарыла. Катнашалар: Р.Маликов, Р.Аббасов, Л.Маслова, Г.Ибушев, И.Сафин, С.Кадыйрова, Н.Сәгыйрова.*

Цирк

13-20 февраль – *Мәскәү циркы йолдызлары тамашасы.*

Курчак театры

13 февраль – *"Аистенок и пугало" (Б.Лопеска)*

14 февраль – *"Невеста падишаха" (М.Гыйләҗев, Л.Батыр-Болгари)*

15 февраль – *"Кот в сапогах" (Ш.Перро)*

20 февраль – *"Барабашка" (Л.Кожевников).*

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

5 февральдән *Ф.Шаляпин исемендәге опера фестивале.*

Татар яшьләр театры

13 февраль – *"Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), Казандагы 106 нчы мәктәп.*

13 февраль – *"Керпе малае дуслар эзли" (Р.Корбан), 72 нче мәктәп.*

17 февраль – *"Үги кыз" (А.Әхмәт), 20 нче мәктәп.*

18 февраль – *"Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 2 нче балалар бакчасы.*

19 февраль – *"Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 155 нче мәктәп.*

20 февраль – *"Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская) 86 нчы балалар бакчасы.*

БЮРО АЛДЫННАН

(Хикәя)

(Ахыры. Башы 11 нче биттә).

маган, әле тагын күпме ясалыр, сезне миңа таксист итеп җибәргәннәр. Яхшыга түгел бу, яхшыга түгел.

Подполковник Әхмәев "Коминтерн" председателенең район җитәкчеләренә тел кайтарып әйтә алуын эченнән генә хуплый да иде кебек. Бигрәк тә, "Беренче"нең күрсәтмәләрен "обсуждать" итүенә хәтта эченнән генә сөенә дә иде бугай әле. Ни әйтсәң дә, "Беренче"нең беренчелегеннән ул көнләшә иде шул. "Беренче" барысын да куркытып тота. Аның бер карашыннан шыр җибәрәләр. Үзеннән курыкмаганнарны "Беренче" барыбер куркыта, сытып таптап үтә, әмма барыбер куркыта. Үзен генә түгел – гаиләсенең, туган-тумачасының иманын укыта. Иң каты чикләвекләрне "Беренче" милиция начальнигының йодрыгы белән вата иде. Менә кайчан килә ул тигезлек. "Беренче" үзе тезләндерә алмаганнарны тезләндереп бирә Әхмәев. Мондый вакытларда "Беренче"гә тиң кодрәт иясе итеп тоя ул үзен.

– Телеңә күп салынма, әйдә, утыр! Үземнең планеркага кайтып җитәсем бар.

– Милициядә планерка үткәрергә мин кирәкмимдер, – үз үҗәтлегенә бирелгән Сәлим үз сүзеннән чигенмәячәген аңлатырга теләде, – сез милициядә үткәрегез, мин икенче бригадада үткәрим.

– Энем, сүз көрәштереп маташма, мин бит синең каравылчың да, ферма мөдирең дә түгел. Утыр дигәч утыр, калганын юлда сөйләшербез.

– Мирзариф абый, мин дә сезгә милиция сержанты, йә участковый түгел. Бюрога кадәр дүрт сәгать вакыт бар. "Беренче" ялдан кайтты, димәк, тагы башланачак көн дә җыелулар, без кайчан эш оештырыйк соң?

– Син мине тыңларга теләмәдең, егет, үзеңә үпкәлә.

– Куркытмагыз, зинһар өчен!

– Элекке вакытларда...

– Элеккене бик сагынсагыз да, элекке – элекке инде. Элекке белән кеше куркытып йөрү бер дә килешми.

Инде кулын селтәп утырып китеп барырга уйлаган милиция начальнигы, кинәт борылып, кычкырып җибәрде:

– Ыштан төбендәге нәрсәңә сөйлә килде-китте сүзләреңне, маңка! Мин синнән ничә яшькә зуррак? Минем сүзләремне аяк астына салып, карышып маташасың!

– Хикмәт яшьтәмени, Мирзариф Сәүбәнович. Милиция начальнигы башыгыз белән конвой булып килгәнсез. Үзегезгә килмәскә иде, конвойны өйгә җибәрергә иде!

– Мин сиңа конвойны соңрак җибәрермен! Хәзер үк кереп утыр машинага, яки мин сине бәйләп салам!

Хуҗасының ярты сүзеннән нишләргә кирәген аңлап алган старшина Әхмәдуллин, машинасын әйләнеп чыкты да, артыннан килеп, Сәлимнең уң як кабыргасы астына бар көченә китереп сукты. Тегесе "Аһ!" дип бөгелеп төште дә сүзсез-тынсыз калды. Ул арада Әхмәдуллин, "УАЗ"игының иң арткы ишеген ачып, Сәлимне өстерәп алып килеп, шунда – исерекләрне, хулиганнарны йөртә торган җиргә бикләп куйды.

– Ү-үтерде персидәтелне! Үтердең бит. Ник анда бикләдең, кабинага утырт! – диде әле генә булган хәлләрнең ничарадан бичара шаһите Әхнәф, калтыранган иреннәрен көч-хәл белән буйсындырып.

Кизәнеп сукканда Әхмәдуллинның йолдызлы бүреге төшеп карга тәгәрәгән иде. Әхнәфнең аяк очындагы шул бүрекне иелеп алды да, тураеп баскан уңайга тимер йодрыгы белән аның ияк астына тондырды. Әхнәф аякларын ике метрлы Әхмәдуллиннан да биегрәк күтәреп, дүрт-биш адым очып барып, башы белән кар эченә кереп чумды...

Зәңгәр-кызыл утларын әйләндерә-әйләндерә, милиция машинасы ферма юлыннан күтәрелеп олы юлга чыкты да тизлеген арттыра-арттыра, район үзәгенә юнәлде.

Кар астыннан чыккан Әхнәф – карда утырып, каравылчы Гафурҗан карт – каравыл өе ишеге төбендә басып, исләренә килә алмыйча калдылар. Аяк астыннан гына сыпырып торган җил шактый көчәеп буранлый башлады.

Әмма, бер атна алдан әйтеп куелган, ничәмә-ничә җаннарны өшетеп, шүрләтеп торган киңәйтелгән бюро утырышы ул көнне булмыйча калды. Наратлы райкомының беренче секретаре Габдулла Нуруллович Нуруллин эш бүлмәсен ачып керүе булды, өлкә комитеттан турыдан-туры элемтә телефоны "Интернационал"ны уйнап алды. Оештыру бүлеге мөдире Шәмгунов:

– Хәерле иртә, Нуруллыч, нинди төшләр күрдең? – дип, күңелсез булмаган хәбәр җиткерәчәген сиздереп куйды.

– Төшләр күреп йоклар чакмыни, Илгиз Салихович, үзем ялда чакта "Икенче" тезгенне бушаткан. Кичә эшкә чыктым. Бераз чабындырып алыйм дип, бүген киңәйтелгән бюро җыям.

– Бюроңны җыеп торма, самолетка утыр да, бирегә килеп җит! Аэропортта каршыларга машина җибәрерләр!

– ...әйтергә яраса?

– Бар да бик яхшы булыр, Габдулла Нуруллович, Сезне башкалага алабыз. Шуннан артык берни сорашма! Ике сәгатьтән минем бүлмәдә бул!

Шул китүдән, беренче секретарь Нуруллин башкалада эшли башлады. Аны эчке эшләр министры урынбасары итеп билгеләделәр. Рәсми билгеләнү Мәскәүдә булса да, төп билгеләүче үзебезнең "Беренче" иде.

Наратлы районына яңа "Беренче"не сайлау пленумына да кайтып тормады полковник Нуруллин. Аның караве "сайлау"ларны үткәрергә килгән Шәмгунов аның исеменә бик күп җылы сүзләр әйтте, яңа сайланган "Беренче"гә дилбегәне Нуруллин шикелле нык тотарга, кирәк булса, чыбыркылап алырга да киңәш итте. Бик үк урынлы булмаса да, үзенчә юморга күчеп:

– Чын ир хатынының тузанын каккалап торырга тиеш, – диде. Залдагылар дәррәү көлешеп алдылар.

Алдагы рәттә бер читтәрәк утырган милиция начальнигы Мирзариф Әхмәев кенә көлә алмады. Дистәләгән карашларның салкын нәфрәтен аркасы белән тойган хәлдә, аның башында бер уй кайнады: элеккеге "Беренче" хәзер аның башкаладагы олы терәге, ә менә монда килгәне "Коминтерн" колхозы рәисе Сәлимҗан Фәттаховның бик үк ерак булмаган туганы икән лә... Элекке "Беренче" Наратлы районы трамплиныннан сикереп югары очканда шактый гына чуп-чар шушында коелып калачагын, алай гына түгел, аның – милиция начальнигы Әхмәевнең башына коелачагын аңлап, кара көеп утырды ул.

Әхмәевнең бөтен борчулы шикләнүләре рас килде. Яңа "Беренче" килеп бер атна эшләүгә үк, аны Эчке эшләр министрлыгына чакырып алдылар һәм, "сәламәтлеге какшау" сәбәпле, лаеклы ялга озаттылар...

Хәтер кайтавазы

Бер сурәтнең тарихы

Һәр елны 15 февраль көнне без каһарман шагыйребез Муса Җәлилнең туган көнен зурлап билгеләп үтәбез. Күп еллар дәвамында без бу көнне Татарстанның Берләштерелгән дәүләт музеенда җыела килдек, Моабит дәфтәрләренең төп нөсхәсе куелган залда тантаналы җыелышта катнашып, шагыйрьне искә алдык, Мәскәү шәһәреннән махсус килгән Әминә ханым Җәлил белән очраштык. Аннары Җәлил бәйрәме мәктәпләргә, югары уку йортларына, җөмһүриятебезнең төрле төбәк сәхнәләренә, күңелләрдән күңелләргә күчеп йөрде.

Казандагы М.Җәлил музее бу күркәм гадәтне һаман да дәвам иттерә. М.Җәлилгә багышланган очрашулар туган якның төрле почмакларында әледән-әле булып тора.

Миңа да үз гомеремдә Җәлилгә багышланган бик күп кичә, концерт, очрашуларда катнашырга, чыгышлар ясарга насыйп булды. Аларны искә алсаң, Мәскәү, Ленинград (Санкт-Петербург) һәм илебезнең бик күп башка шәһәрләре, аларның сәхнәләре күз алдыннан үтеп киткәндәй була. Халкыбыз Җәлил шигырьләрен, аның әсәрләренә язылган көйләрне ничек яратып, чын-чынлап дулкынланып тыңлый иде бит! Һәр башкаручы өчен дә – драма артистымы ул, опера җырчысымы, нәфис сүз остасымы – иҗатында Җәлил исеменә кагылу әйтеп бетергесез дәрт, илаһи илһам бирә иде.

Мин бүген архивымда кадерләп саклаған бер фотосурәт турында сөйләп китәргә телим.

...50 нче елларның урталары. Җәлил китаплары төрле нәшриятләрдә басыла, шагыйрьләр Җәлилгә багышлап шигырь-поэмалар, композиторларыбыз аның шигырьләренә матур-матур әсәрләр яза башлаган чор. Татар драматургларыннан беренче булып Нәкый ага Исәнбәт "Муса Җәлил" исемле трагедиясен язды. 1957 елда бу әсәр Г.Камал театры сәхнәсендә куелды. Әсәрне ул вакытта әле яшь режиссер Празат Исәнбәт куйды. "Муса Җәлил" спектакле җөмһүриятебезнең мәдәни тормышында олы вакыйга буларак кабул ителде. Спектакльдә рольләрне театрыбызның мәшһүр артистлары: Ф.Халитов (Муса), Г.Булатова (Әминә) башкарды. Калган рольләрдә Х.Әбҗәлилов, Х.Уразиков, Камал III, Г.Нигъмәтуллина, Х.Сәлимҗанов, Ш.Әсфәндиярова, Д.Ильясов, Ф.Колбарисов, Г.Шамуков, М.Миңлебаева, Р.Җиһаншина, Г.Зиатдинов һ.б. артистлар уйнады. Миңа да бу спектакльдә Җәлилнең көрәштәше шагыйрь А.Алиш ролен уйнарга насыйп булды.

Спектакльне рәссам М.Сутюшев бизәде, музыкасын композитор Х.Вәлиуллин язды.

"Муса Җәлил" спектакле театрлар һәм музыка коллективларының Октябрьнең 40 еллыгына багышланган Бөтенсоюз фестивалендә катнашып, мактаулы урынга лаек булды.

1957 елның 6 ноябрендә театр артистлары һәм җитәкчеләре өчен аеруча шатлыклы вакыйга булды: спектакльне карар өчен Мәскәүдән Әминә һәм Чулпан Җәлилләр килде. Шул кичне тамашачылар арасында Нәкый ага Исәнбәт, Җәлилнең дусты һәм иҗатын өйрәтүче Гази ага Кашшаф, күп кенә башка язучылар һәм композиторларның булуы артистларга тагы да дәрт, илһам өстәде.

Спектакльдән соң Әминә ханым белән Чулпан сәхнә артына кереп, артистларга рәхмәт әйттеләр. Менә шул мизгелне фотограф сурәттә мәңгеләштерде.

41 ел вакыт үткәннән соң, шушы рәсемгә карап, бөек Муса образын мәңгеләштерүче шәхесләребезгә тагын бер кат рәхмәт сүзләре әйтәсе килә.

● Спектакльдән соң (уңнан сулга): Х.Кумысников, Г.Шамуков, А.Арсланов, Н.Исәнбәт, Г.Кашшаф, Ф.Халитов, Г.Булатова, Ш.Әсфәндиярова, Ш.Сарымсаков, Әминә ханым, Чулпан, Д.Ильясов, Б.Шакирова, А.Галиева, П.Исәнбәт, Г.Нигъмәтуллина, Р.Әхмәрова.

Айрат АРСЛАНОВ.

Батулла баганасы

Артистлар кыскара

Мәһабәт буйлы, куәтле Зөйни Солтан, Мохтар Мутин, Камал Өченчеләрдән соң театрга кыска буйлы актерлар килә башлый. Алда исемнәре аталган артистлар белән уйнарга күнеккән Галимә ханым Ибраһимовага шул кыска буйлы "кәтәнәләр" белән уйнарга туры килә. Мирхәйдәр Фәйзинең "Ак калфак" әсәре буенча куелган спектакльдә ул – Хәмдияне, Бакый ролен Дәлъюс Ильяс башкарган икән. Дәлъюс Галимә ападан бераз кыскарак та иде бугай әле. Шунда Галимә ханым ачынып:

– Шушындый тәбәнәк артистлар белән уйный-уйный бөкрәеп беттем инде! – дип әйтеп куйган, имеш.

Рәнҗеш

Сугышта катнашкан артист Дәлъюс Ильяс кибеткә кереп, сугыш ветераннары чиратына басып, сирәк сатыла торган затлы ризык алмакчы була. Шулчак хатын-кызлар шаулаша башлыйлар.

– Карагыз әле, бу ир сугышта катнашмаган башы белән чиратсыз керә, – дип кычкыралар.

– Каян килгән фронтовик! Яшь-яшь башы белән кая керә бит, оятсыз!

Дәлъюс дәшмичә тик тора. Хатыннар аның саен катырак кычкыра, хәтта бәрсе Дәлъюс янына килеп:

– Күрсәт кәгазеңне, күрсәт орден-медальләреңне! – дип җилтерәтә башлый.

Шулчак Дәлъюс бишмәтен чишеп ачып җибәрә дә:

– Менә-менә, Кызыл Йолдыз орденым бар! – ди.

Гөнаһ шомлыгына, Дәлъюс орден тагылган пинжәгә урынына башкасын киеп чыккан булган икән. Аның орденсыз икәнен күреп, хатыннар Дәлъюсны ботарлардай булалар.

– Каян килгән сугышчы! Ха-ха-ха!

– Тай чираттан, әрөмтамак!

– Туниядис!

Татарстанның халык артисты, орденлы сугышчы Дәлъюс Ильяс буш кул белән, күңеленә рәнҗү төяп өенә кайтып китә. Орденлы белән таныклыгын алып, янә кибеткә бара, ләкин анда ризык та, чират та булмый инде.

Сиксәнгә җиткәч

Риза Ишморат театр тәнкыйтьчеләреннән зарланып утыра икән:

– Менә, минем иҗатым турында Кумыс Халитников дөрес язмаган! – ди.

– Риза абый, – ди Илдар Юзи. – Кумыс Халитников түгел, Халит Кумысников!

– Ие, ие, дөрес! Минем турында Кумыс Халитников гел дә булмаганны язган! – дип кабатлый Ишморат.

– Юк, Риза абый, – ди Илдар. – Сез дөрес әйтмәдегез! Кумыс Халитников түгел, Халит Кумысников.

– Соң, атаң башы, мин дә бит Халит Кумысников димим, Кумыс Халитников, дим. Менә шул Кумыс Халитников...

– Риза абый, Кумыс түгел, Халитников түгел, Халит Кумысников!

– Нигә башны бутыйсың, син, кем, Илдар, мин дә әйтәм бит, Кумыс Халитников...

– Юк, Халит Кумысников...

– Әйдә, синеңчә булсын, менә шул театр тәнкыйтьчесе, Кумыс Халитников, минем турыда дөрес язмаган...

Фаил Әмәк кылыклары

Мөслим районының Әмәк авылында туып-үскән ул. Үзе әйтүенчә, заманында "гап-гади" укытучы булган, аннан соң гына мәктәп директоры итеп билгеләнгән. Ни генә булмасын, Факил үзенең остазлары арасында үзе укыткан балаларны төп остазлары дип саный. Ә инде язучылар арасыннан Фоат

Садриев, Фаил Шәфигуллин кебек юмор осталарын, "Чаян" журналын, дуслареын-каләмдәшләрен телгә ала.

"Соңгы көз", "Тузганак чәчәге" кебек китапларында балаларча җылылык-самимилек булуы, аларның шаянлык һәм җорлык белән сугарылуы да, мөгаен, шуннандыр.

Без аның белән урамда таныштык.

– Исемең ничек? – дидем мин.

– Вәсимә, – диде кыз, ак тешләрен күрсәтеп. – Ә синеке?

– Ринат...

– Матур исем!

– Синең дә исемең бик матур, үзең кебек...

Колакларымның кызаруын сизәм.

– Сиңа ничә яшь?

Икебез дә көлеп җибәрдек – бер яшьтә икәнбез.

– Сине күргәнем бар, – ди кыз, мөлаемлыгын югалтмыйча.

– Минем дә... кайдадыр күргәнем бар. Кайда яшисең?

Вәсимә өен күрсәтте һәм әкрен генә атлап китте.

Акселерат

– Бераз озатып куярга мөмкинме? – дип сорадым, бар кыюлыгымны җыеп.

– Рәхмәт. Иренмәсәң, әйдә.

Дөньядагы төрле юк-барны сөйләшә-сөйләшә кызның капка төбенә килеп туктадык.

– Менә кайтып та җиттек, – диде Вәсимә, күзләрен аяк очына төбәп. – Хуш!..

– Ә бәлки бераз чөкердәшеп торырбыз?

Ул минем тәкъдимемне шатланып кабул итте. Капка төбендәге утыргычка утырдык... Капка баганасы күк тавыш-тынсыз тору мине тиз ялыктырды. Бераз җанлылык өстәп алырга кирәк... Җитез генә кызның ботын борып чеметеп алдым... Җавап тиз булды: "чалт" яңакка! Бу кадәресен үк көтмәгән идем – күздән утлар чәчелде! "Шап" итеп утыргычтан әйләнеп төшкәнне дә сизми калдым. Җитмәсә, түшем сыер ясап киткән "сандугач оясы"на туры килде. Мин торганда Вәсимә юк иде инде.

...Ярар, дидем, ыштанымны ике кулым белән әйбәтләп күтәреп куеп, майкамны салып аттым. Без дә биш яшьтә туктап калмабыз әле, үсәрбез... Ике теш арасыннан "черт" итеп төкердем дә, кулларымны кесәгә тыгып, үзебезгә кайтып киттем.

Безнең өй ерак түгел, түбән очта гына...

Пар(О)дөя

Махсус тудым

"Сугыш беткәннән соң нәкъ өч елдан,
Мин туганмын – шулай кирәк булган.
...Мин туганда асыл ир-егетләр
Туган илдә әле сирәк булган".

Роберт Миңнуллин.

Сугыш бетеп өч елдан соң бу дөньяга
Заказ белән махсус тудым.
Асыл ирләр сирәк, син бик кирәк,
Дип ялынгач, риза булдым.
"Яшь ленинчы"лар ул заманда
Ни сәбәптер сирәк булган.
Мин туганмын, инде кара -
Алар белән дөнья тулган!
Мин туганда – сер түгел бу -
Шеп шагыйрьләр сирәк иде.
Һәм шуларга иш булырлык
Тагын берәү кирәк иде.
Мин туганда кибетләрдә
Яхшы китап сирәк булган.
Җиң сызганып китап яздым -
Иң шеп китап синең кулда.
Бу китап – зур аквариум:
Сөн сулары, Аккош күле...
Сандугачтан, Сөннән башка
Шигырь язу мөмкин түгел.
...Сугыш бетеп өч елдан соң
Бик ялынгач, тудым, туган.
Дөрес булган!
Мине дөнья
Дүрт күз белән көтеп торган!!!
Шулай, туган...

Коммунизмнан кайткач

"Киләчәккә таба китеп барам.
Без барасы офык – Коммунизм".
"...Без сөйләгән сүзләр тузга язган,
Безнең йөрәк әйтерсең лә туздан..."

Мөдәррис Әгъләм.

Тузга язган! Мин барасы офык –
Коммунизм! – диде Мөдәррис.
...Бүген күрдем кабат аны:
"Чалбар тузды,
Ямаулык бир, – диде, – тегәрҗеп..."
– Башмагыңның табаннары төшкән...
– Юллар начар булды. Җил һәм тузан.
Ә, югыйсә, чакрым саен тузга
"Хәерле юл!" – дип язып куйган...
Казанымнан чыккан шәпкә
Таралды да төште машина...
"...изм" офыгына җәяү киттем,
Күрәселәр язган башыма.
Җеназаны хәтта укыдылар,
Сәяхәттә йөргән кешегә!..
Тузган мәтәштергән йөрәк-бавыр
Җәфалый гел, кереп төшемә.
Менә шулай, туган. Әле ярый
Сезнең белән күрешүләр язган.
Кайтсам – хәсрәт: тегә сары чәчби,
Әллә кемнән, каһәр, буйга узган.
Казанымның тынычлыгы киткән,
Урамында – гайбәт, әтрәк-әләм.
Һәм һәр йортта – мемориаль такта:
"Монда булды шагыйрь Әгъләм".

Эпиграммалар

Автоэпиграмма

Көр тавышың һәм мыегың
Булмаса, синең Әмәк,
Тигез җирдәге түмгәккә
Охшар идең, әкәмәт!

Айдар Хәлимгә

Аргамагың – өч аяклы,
Чапмак була, җилкенә,
Камчы уйный уңлы-сулы,
Кемгә – хәсрәт, кем – көлә.

Мансур Вәлигә

"Юк, килешмим!" – дип әйтергә
Кыюлык таба ул еш кына.
...Яшен чатный дип көткәндә
Тамак кырган тавыш чыга...

Зөлфәткә

Гаҗәпләнмәслек тә түгел,
Җегәр табам каян?!
Бәдрә чәчләр сирәкләнде -
Шигырь... Гаилә... "Чаян"...

Гамил Афзалга

Партизандыр Гамил Афзал -
Түрәләргә тынгы бирми.
Поскан җирдән атып ята,
Дошман ишәя, үлми.

"Мәдәни җомга" гәзите теге яки бу төбәккә бик теләп барып чыга. Мондый сәяхәт вакытында, бердән, ул үзенең дөньяда барлыгын белдерә, авыл җирендә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешен дә яктырта. Әгерҗе якларына беренче тапкыр юл тоту 1996 елның июль аена, Әгерҗе каласы үзенең 350 еллыгын билгеләп үткән көннәргә туры килгән иде. Икенчесендә – гәзит үткән елның сентябрендә укучыларына Әгерҗе районының ачык төрдәге "Агрохимсервис" акционерлык җәмгыяте турында сөйләде. Бу сәхифәдә исә гәзит укучылар "Йолдыз" акционерлык җәмгыяте, шул җәмгыять урнашкан авылларда яшәүчеләрнең эше һәм тормышы белән танышачаклар. Әлбәттә инде, башта аның рәисе Җәүдәт Хикмәт улы Кәримовка мөрәҗәгать иттек.

Җәмгыять рәисе Җәүдәт Кәримов (уңда) һәм "Җәүдәт мәчете"ндә имам-хатыйб вазифасын башкаручы Габдулла Галиев.

Әгерҗе җирендә

Зарланып кына яшәп булмый

– Җәүдәт әфәнде, соңгы елларда күмәк хуҗалыкларның исемнәре алмашынды. Аларның кайберләре күмәк хуҗалыклар ассоциациясе, акционерлык җәмгыяте, кайберләре кооперативлар берләшмәсе дип атала. Үзгәреш җилләре сезгә дә кагылмый калмагандыр, ул нидән гыйбарәт? Элекке белән хәзерге арасында берәр аерма бармы?

– Илдә барган мәгълүм үзгәрешләргә кадәр без Чапаев исемендәге колхоз идек. 1994 елда "Йолдыз" исемендәге акционерлык җәмгыяте төзедек. Аның уставын бик нык уйлап, ике ел дәвамында эшләдек. Элек колхозда эшләүчеләр саны 180 кеше исәпләнә иде. Хәзер җәмгыять үз эченә эшче көч саналган 150 кешене берләштерә. Бу сан ни өчен кимеде соң? Хикмәт шунда: колхоздан чыккач җәмгыятьнең тулы канлы әгъзасы булу өчен билгеле бер срок – өч айдан алты айга кадәр вакыт билгеләнде. Шул чор эчендә теге яки бу иптәш үзен лаеклы тотмый, җәмгыять Уставы таләпләрен инкарь итә икән, әгъза булудан туктый. Элек бит колхозга кабул итү, аннан чыгару мәсьәләсен колхозчыларның гомуми җыелышы гына хәл итә иде. Хәзер исә идарә, дөресрәге, идарә рәисе хәл итә. Аңа шундый хокук бирелгән.

– Сез бит инде эшчәнлегегезне адәм баласын тоттым да куып чыгардымга кормагансыздыр. Кеше үз теләге беләнме, хилаф эше өченме – җәмгыять әгъзасы булудан туктаганда нәрсәгә дә булса ия булып каладыр?

– Бик урынлы сорау бирәсез. Без колхозны таратып җәмгыять төзегәндә барлык җирләрне һәркемгә тигезләп бүлдек. Бүгенге көндә бездә һәр кешенең 4,5әр гектар җире бар. Җирне колхоз эшендә турыдан-туры катнашмаган, әйтик, укытучылар, медиклар һ.б. шундый һөнәр ияләре дә алды. Ә менә төп фондлар акчага күчереп исәпләнде һәм фәкать колхозчыларга гына бирелде. Минем, мәсәлән, яңа акча белән 168 мең сумлык өлешем бар. Җәмгыятьтә йөз мең акчаң булганда – син акционерлык җәмгыятенең бер тавышлы әгъзасы. Уставта шулай каралган. Димәк, минем байлык 17 тавышка ия булырга мөмкинлек бирә.

– Әйтегез әле, башта җәмгыятьтән чыгып, аннары үзләрен яңадан кабул итәргә сораучылар бармы?

– Без башта ук кирәкмәгән, үзләрен лаеклы тотмаган кешеләрдән арындык. Аннан соң ун кеше үзе теләп чыгып китте. Шуларның дүртесе янә кабул итүне сорады.

Беренче көннәрдә, беренче айларда Уставның бу пункты үтәлерме дип, мин берәз шикләнгән дә идем. Әмма юкка булган. Нәкъ менә шушы уставны бозучыларга карата җәза каралган пунктны үтәү акционерлык җәмгыяте әгъзалары арасында дисциплинаны ныгытырга, эленке-салынкы йөрүчеләргә юл куймаска мөмкинлек бирә дә инде.

– Сезнең сөйләүдән мин башта ук куйган сорауга – элек белән хәзерге арасында аерма бармы, дигәнгә җаваплар күренә. Ләкин минем шул аерманың чагылышын тагын да ныграк тоясым, тагын да ныграк сизәсем килә. Чөнки республика авылларында йөргән чакта колхозларның исеме генә алышынды, җисеме шул килеш калды, дигән фикерне бик еш ишетергә туры килә.

– Бу бик четерекле сорау. Моңа туп-тулы итеп җавап бирү өчен вакыт сынавын үтәргә кирәк. Ләкин шунысы ап-ачык: базар шартларына күчү теләсәңтеләмәсәң дә синең алдыңа яңа таләпләр куя. Элек аунап яткан әйберләрне, әйтик, запас частькә ярардай машина детальләрен җыештырып куясың, кирәге чыгу белән аларны эшкә җигәсең. Гомумән, һәр адымыңны нәрсәне дә булса экономияләүгә юнәлтәсең. Менә бер мисал: элек без Чаллыда эшләнгән "КамАЗ" автобусын файдалана идек. Хәзер "УАЗик"ка күчтек. Ни өченме? "КамАЗ"ның бер тәгәрмәче 5 млн.сум тора. Бер елга алты тәгәрмәч бетә. Димәк, тәгәрмәчләр өчен генә дә 30 миллион акчаңны чыгарып саласың. Ә башка чыгымнар? "УАЗик"ка күчкәч, байтак акча янга калачак. Хуҗалыкта файда бирердәй һәрнәрсәгә ябыша башлыйсың. Колхозда гомер булмаганны – ит, балык ыслау цехы ачтык. Ит үзебезнеке, балыкны кибеттән алабыз. Әлбәттә, ыслагач аларның бәясе арта. Әмма үзебезнең авылларда яшәүчеләр дә, килгән-киткән кешеләр дә ала ул ысланган продуктларны. Эшли башлагач, теге яки бу әйбернең файдалымы-түгелме икәнен тормыш үзе күрсәтә. Шул ук балыкны алыйк. Без аны, ит кебек үк кайнар ыслау ысулы белән эшләдек. Мондый вакытта температура 70 градустан төшми. Ә балыкка 30 градус кына кирәк. Ысланган балыгыбыз һәр очракта да сатылып бетми, калганы бозылып әрәм була иде. Хәзер аны салкынча ыслау өчен шартлар тудырабыз, иске котельныйны яраклаштырабыз. Салкынча ысланган балык озаграк саклана.

Ыслау өчен балыкны гел кибеттән генә алып булмый бит инде. Шуның өчен алдан ук балык буасы төзедек, анда карп һәм башка төрле балыклар үрчетелә. Хәер, ысланмаган очракта да балык артмый. Үзеңнеке булгач, ни кылансаң да килешә дигәндәй, аны җәмгыять әгъзаларына килосын өчәр, башкаларга алтышар меңнән саттык. Шулай эшләгәч, аларда, бу буа үзебезнеке бит, сакларга кирәк аны, дигән фикер туа.

Тагын бер мисал. Бездә Әгерҗе сөт-май комбинатының сепаратор пункты бар иде. Анда үзгәртеп кору башланганчы янәшә-тирә колхозлардан китерелгән сөтләр аертылды. Аннан соң ул ташландык хәлгә килде. Чөнки хуҗалыклар, тапшырган продуктлары өчен акчаны вакытында ала алмый башлагач, сөтләрен акчага кем алса – шуңа сата башлады. Хәзер без бу пунктны аякка бастырдык, аертылган сөт өстен район сөт-май комбинатына бирәбез, калганын терлекләр ашатуга файдаланабыз. Ләкин бу хәл дә канәгатьләндерми безне. Майны үзебездә язарга, аны йөзәр граммлы итеп төрергә кирәк. Шулай сатарга җиңел булачак, алынган акча җәмгыять кассасына керәчәк. Һәм шул ниятебезне тормышка ашыру өчен чаралар күрәбез.

Ә исем-җисем турында шуны әйтә алам. Болай фикер йөртүчеләрдә дә хаклык бар. Чөнки иген игәсең, бәрәңге үстерәсең, ит-сөт җитештерәсең, аларны дәүләткә тапшырасың. Ә акчасын айлар, еллар үткәч кенә бирәләр. Мәсәлән, ашлык саткан өчен безнең дәүләттән йөз миллион сум акча аласы бар. Ә бәяләр ничек диген!? Бер литр сөтең бер литр бензиннан арзанрак бит. Запас частьләр алу, техника паркын яңарту турында уйласаң, чәчләр үрә торырлык. Ә яшәргә кирәк, зарланып кына ятып булмый. Менә шуннан төрле юлларны эзләү башлана инде. Без хәзер терлекләрне Удмуртиянең Сарапул шәһәрендәге ит комбинатына тапшырабыз. Сәбәбе – комбинат көнендә үк тиешле акчаны бирә.

Әйтик, без җитештергән авыл хуҗалыгы продуктларын отышлы бәягә сату хокукын һәм үзебезгә генә кирәкле дип табылган культураларны игү мөмкинлеген бирсәләр, хәл бөтенләй башкача булыр иде. Ул вакытта исем үзгәрде, җисеме юк, диярге нигез калмас иде.

– Авыл җирендә буа бусаң да, ит-балык ысласаң да, хәтта трусик-майка тегү цехы ачсаң да үсемлекчелек һәм терлекчелек тармаклары төп тармаклар булып кала. Шуларга тукталып китсәгез иде.

– Әйе, безнең яшәүне бу ике тармаксыз күз алдына да китереп булмый. Үсемлекчелек буенча да, терлекчелектә дә авыз тутырып сөйләрлек сүзләребез бар. Бу тармакларда җитештерелгән продуктларның күләме ягыннан без районндагы 29 хуҗалык арасында беренче бишлеккә керәбез. Мәсәлән, бөртекле һәм кузаклы культураларның һәр гектарыннан 1996 елда 29, узган ел 34,8әр центнер уңыш алдык. Әлбәттә, кайбер районнар алган 50-60ар центнер түгел инде безнеке. Ләкин Әгерҗенең төньяктагы район икәнен, андагы белән 50-60 центнер алган районнардагы табигать шартларының нык аерылып торуын да искә алырга кирәк. Әмма безнең егетләр сер бирә торганнардан түгел. Узган ел, мәсәлән, Фердинанд Гыйззәтуллин "Дон-1500" комбайны белән 21 мең центнер ашлык суктырып, районда беренче урынны алды. Аңа бүләк итеп ат бирдек. Мөнәвир Гыйльметдинов белән Ирек Гайнуллиннар күрсәткече дә йөзгә кызыллык китерерлек түгел. Шунысын да әйтим, М.Гыйльметдинов гадәти вакытта – баш инженер, И.Гайнуллин – механик булып эшли. Урак өстендә икесе дә кыр корабын иярләп ала. Вакыт белән исәпләшмичә эшләүче "КамАЗ" шоферы Марат Галиев, "ГАЗ-53" шоферы Мөнәвир Шәңгәрәев, тракторчылар Фоат Вахитов, Фәнис Вәлиев, Фәнил Әхмәтов, Илдар Зәйнуллин, Марс Сәлимов кебек механизаторлар белән без хаклы рәвештә горурланабыз.

Терлекчелек дигән тармакны үз җилкәләрендә алып баручы, алар булмаса бу өлкәдә мондый уңышларга ирешер идек микән дип әйтерлек кешеләребез дә аз түгел. Сыер савучылар Фәридә Кәримуллина, Гүзәлия Вәлиева, Гүзәлия Хөснетдинова, бозау караучы Галя Сәлимгәрәева, Роза Хәмидуллина симертүдә эшләүче Радик Шәйдуллин, орденлы терлекче Мәйсәрә Шакировалар фидакарь хезмәт үрнәк-ләре күрсәтеп эшлиләр.

Соңгы елларда яңа төр кешеләр – фермерлар барлыкка килде. Хәзер алар унга җитте. Иң күп җир – йөз гектарга ияләсе – Эльмир Закиров. Калганнарныкы 9 белән 13 гектар арасында тирбәлә. Әлбәттә, бездә фермерларның берсе дә акционерлык җәмгыятеннән башка яши һәм эшли алмый. Чөнки алар өчен хөкүмәт тарафыннан шартлар тудырылмаган әле. Әмма монда бер зыян да юк. Без бит җир балалары, бер максат, бер теләк белән яшибез.

Кемдер төзи, кемдер сүтә – димәк, тормыш дәвам итә

Соңгы ике елда авыл Советлары җирле үзидарә дип аталса да, миңа "авыл" сүзе кергән атама күбрәк ошый. Шушы сүз үзең дөньяга килгән, шунда уйнап, укып үскән, клубында күңел ачкан, гаилә корган, бер сүз белән әйткәндә, сине кеше иткән җирлекне аңлатканга оеручы якындыр инде. Миңа бу сүз якын гына түгел, кадерле дә. Чөнки 1977 елдан бирле Кырынды авыл Советы рәисе булып эшлим.

Табигый ки, үзең идарә иткән советка-үзидарәгә кергән авылларның матур, төзек булуын күрсәң, күңел сөенә, эшкә дәрт арта. Дөрес, соңгы елларда бер көйгә салынган тормыш ритмы үзгәрде. Хезмәткә түләү вакытында башкарылмый, хәтта пенсия белән тоткарлыклар килеп чыга. Авырлыклар бар, әмма, кем әйтмешли, тормыш дәвам итә, кемдер төзи, кемдер сүтә. Минем бу очракта соңгы вакытта калкып чыккан яңа йортлар турында, аларның да таштан салынганнары турында әйтәсем килә.

60 нчы еллар уртасында колхоз авылның Гаяз Әхмәтов дигән мөхтәрәм кешесенә йорт салырлык күләмдә кирпеч биргән иде. Авыл халкы аны зур вакыйга буларак кабул итте. Ул елларда таштан хәтта колхоз идарәләре дә салынмый иде шул.

Аннан соң инде күп сулар акты, авылларда таш өйләр калкып чыкты. Аларның саны дистәдән артты. Әле соңгы вакытта гына "Йолдыз" акционерлык җәмгыяте Кырынды авылының машина-трактор паркыннан ерак түгел таш йорт салды. Ул үзенең хуҗасын көтә, лаеклы гаилә табыла икән – рәхим итсен. Шушы ук авылда Зирәк Нурмөхәммәтов таштан йорт салды. Зирәк фермерлар сафына баскан егет. Дөрес, аның җире 4,5 гектар, ягъни пайга бирелгән кадәр генә. Ләкин тырыш кеше өчен аз түгел ул.

Тукай авылында электрик Фердинант Гыйззәтуллин да таштан мәһабәт йорт салды. Бер сүз белән әйткәндә, кемдер төзи, кемдер сүтә, тормыш дәвам итә.

Светлана ШӘЕХОВА,
җирле үзидарә Советы рәисе.

● Җирле үзидарә Советы рәисе Светлана Шәехова (уңда) һәм почта бүлеге башлыгы Әлфирә Сабирҗанова.

Кабынган "Йолдыз"

Без, журналистлар, эш кешесен гадәттә эш урынында күрергә күнеккән. Терлекче сәнәк тотып печән-салам йә силос салып йөргәндә, механизаторны басуда орлык чәчкәндә, йә игеннәр урганда. Ә менә Фәридә һәм аның ире Вәгыйз Кәримуллиннар белән аларның өендә очрашырга туры килде. Көндезге ял вакыты иде. Икесе гомумән, тормыш-көнкүреш турында сөйләшәбез. Сораулар, җаваплар өзелеп тормый. 20 ел терлекче, бүгенге көндә 47 сыерны тәрбия кылучы, инде тарихка күчкән 1997 елда шулардан 98 тонна сөт савучы Фәридә Кәримуллинаның сөйләр сүзе аз түгел.

Ире Вәгыйзнең дә хезмәт юлы бай, аның хакында да авыз тутырып сөйләргә була. Заманында механизатор, аннан соң хисапчы, аннан соң төзүче, бүгенге көндә фермер һәм... хатыны Фәридәнең төп булышчысы. Без сөйләшеп торган арада ул фермага җыена башлады.

- Авыз ачтыргач Фәридә бара алмый да бара алмый инде. Хәер, без болай да кышын гел бергә. Җир эшкәртергә тотынгач кына аерылам мин аннан. Ул вакытта балалар булыша, – диде ул, җыенып беткәч.

Вәгыйзнең 9 гектар җире бар икән. Үткән ел шул мәйданда солы, арпа, бодай иккән. Һәр гектардан уртача 30ар центнер ашлык алган.

Кем әйтмешли, болар гына әлләни искитәрлек нәрсә түгел. Эш камыты кайсы гына татар гаиләсен читләтеп үткән дә, татарның кайсы гына терлекче яки механизаторы фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтми калган. Бу турыда без көн саен язып, көн саен сөйләп торабыз. Ә менә бүген, бөтен Русия халкы зарланган бер заманда, 7 бала үстереп карагыз әле сез. Әйе, әйе, Кәримуллиннар гаиләсе бер дистә кешене тәшкил итә. Һәм, иң мөһиме, бер бала да артык түгел, бер бала да кыек юлда йөрми. Әнә Илфар тракторда мөстәкыйль эшли башлаган, 9 нчы сыйныфта укучы Илмир уңга-сулга карамый әти-әнисенә булыша. Аш мәҗлесе үтәсе көнне дә ул әтисе белән бергә фермага җыенды. 6 нчы сыйныфта укучы Вәзинур да, 2 нче сыйныфта укучы Динил дә һич карусыз теләсә нинди эшне җиренә җиткереп үтиләр икән. Аларның дөньяда барлыгына сөенеп, Саимә апа болай диде: "Балалар күплектән без бернинди мохтаҗлык сизмибез, аларга ризыкны Алла үзе бирә".

Саубуллашканда өстәлгә тагын бер тапкыр күз ташладым. Ул нигъмәтләрдән сыгылып тора иде дисәм, һич арттыру булмас. Ризыкларыгыз тәмле, йорт-җирләрегез имин булсын, кардәшләр!

● Алдынгы савымчы Фәридә Кәримуллина.

Нәзер ашы

дә өйдә булырга тиеш, диделәр. Чыннан да шулай булып чыкты.

– Авыз ачтырырга әзерләнебез, – дип каршылады мине хуҗабикә. Якын тирәдәге карчыкларны чакырдык. Ничек дип әйтим инде, нәзер ашы бу безнең.

Сөйләшеп киткәч барысы да аңлашылды. Сүзгә каенана да кушылды. Саимә апа авырып алган икән. Исәнсау терелсәм, аш уздырырмын, дип нәзер әйткән. Ураза ае булгач, аш мәҗлесен авыз ачкан вакытка туры китергәннәр.

Үткәндәге вакыйгалар,

Тамырлар еракка тоташа

Урак өсте җиттеме, безнең баш инженер комбайнга утыра, дигән сүзләрне ишеткәч, миндә, ирексездән, аның белән очрашу, сөйләшү теләге туды. Мөнәвир Гыйльметдинов Әрем авылыннан икән. Шул сүзне әйтү белән әллә кайчангы танышымны очраткандай булдым. Таныш, бик таныш исем бу миңа. Шушы төбәктә туып-үскәнлектән, бала чагымнан ук якын бу авылның исеме. Икенчедән, үзәге Көчек авылы булган "Родина" колхозының тарихын язганда Әремгә шушы авылдан күчеп киткән кешеләр нигез салганын белдем. Октябрь борылышыннан соң, крәстиәннәрне күчереп утырткан вакытта. Исеме дә әнә күңелләргә якын үләннеке бит.

Тамырлар шулай еракка тоташа. Ә юкбар кеше күчеп йөри алмый, тәвәккәлләр генә таш яра. Димәк, Мөнәвирнең атасы Габделхак ага да, аның атасы да тәвәккәл кеше булганнар. Мөнәвир белән танышканда тәвәккәллекнең аңа да юлдаш икәнлегенә тагын бер кат инандым. Ул белеме буенча шофер булса да, 1986 елдан бирле күмәк хуҗалыкның баш инженеры булып эшли.

– Гадәттә институт тәмамлаучылар, ким дигәндә техникумнан соң эшлиләр бит бу эштә. Сезгә баш инженер хезмәтен үтәү авыр түгелме?– дидем мин аңа, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча.

– Чыгып-чыгып тордым мин бу эштән. Дипломлылар алыштырдылар. Тик янадан чакырып алдылар. Юк, мин аларны эшли алмадылар димим. Күп кешенең авылда каласы килми. Баш инженер булып эшләгән бер иптәш әнә бизнес белән шөгыльләнә башлады.

Мөнәвир гәүдәгә калын, сөйләшкәндә салмак. Аннан сүзне дә каерып аласың кебек. Була андый кешеләр. Сөйләшкәндә салмак, эшләгәндә ут уйнатучылар була. Ул нәкъ менә шундыйлардан икән. Аның хакында әйтүчеләр бу сыйфатын сүз аша җиткерсәләр, җитәкчеләр сан аша җиткерәләр. 14 мең центнер! Узган ел әнә шуның кадәр ашлык суктырып алган Мөнәвир.

Кылган гамәлләрендә тәвәккәллек сыйфатларын күргәч, Мөнәвирнең белемгә омтылмавы гайре табигый булып күренде миңа. Һәм теләсәм-теләмәсәм: "Мөнәвир туган, ничек инде син укымый калдың? Баш инженер вазифасын үтәгән баш техникум, йә институт программасын үзләштерерлек бит инде ул",– дигәнемне сизми дә калдым.

Монда ул гадәти кануннардан читләшсә дә, тормышта төп таләпләрдән тайпылмаган. Хатыны Хәлимә белән өч бала үстергәннәр. Уллары Дилюс аларга онык та бүләк иткән инде, ә Ләйсән Ижау көллиятендә укытучылыкка укый. Кечеләре Гөлия яннарында– Кырынды урта мәктәбенең 5 нче сыйныф укучысы. Әйе, гаилә ягыннан да тамыры нык Мөнәвирнең.

● "Йолдыз" акционерлык җәмгыятенең баш инженеры Мөнәвир Гыйльметдинов.

Иманга кайту юлында

● Җәүдәт мәчете.

Аллаһу әкбәр... Аллаһу әкбәр...

Һәр җомга көнне әнә шулай авылыбызның ике мәчет манарасыннан моңлы азан тавышы яңгырый. Өлкән яшьтәге кешеләр кыйблага карап намазга ошый. Изге Рамазан аенда мәчетләребездә ахшам, тәрравих намазлары укылды. Гыйбадәтләребезне, изге гамәлләребезне Алла кабул кылсын!

Бәятуллаларыбызга карыйбыз да, куанычыбыз эчкә сыймый. Аларны төзү җиңел булмады. Хәтерем ялгышмаса, 1985 еллар ахырында коммунистик идеология какшады, динне тыю, кысрыклау тукталып калды. Республика газитләре күп кенә авылларда мәчетләр төзелә башлады, дип хәбәр итте. Әлбәттә инде, бездә дә мәчет төзү теләге туды. Әмма андый зур төзелешне ничек башкарып чыгарга? Акча, төзү материалларын каян табарга? Киңәшә торгач, Алабуга җиңел автомобильләр заводы генераль директоры Карачуринга мөрәҗәгать итеп карарга булдык. Бу иптәш, күңелләребезне күтәрерлек вәгъдәләр бирсә дә, конкрет берни дә эшләмәде.

Шулай да безгә бәхет елмайды. 1990 елның язында "Алга" колхозында эшләгән авылдашыбыз Җәүдәт Кәримов рәис булып кайтты. Шул ук көнне гомуми җыелышта мәчет төзүгә ныклап алыначагын әйтте. Җәүдәт сүзендә торды. 1990 елның җәендә, мәчет булачак нигездә, Коръән укып, эшне башлап җибәрдек.

Ниһаять, 1992 елның октябрендә,җомга көнне мәчетебезне ачу бәхетенә ирештек. Ул бик матур,үзе кирпечтән, түбәләре көмеш кебек ак калайдан. Авыл уртасындагы иң күренекле урында өч манарасы белән балкып утыра. Авыл картлары, бу төзелештәге тырышлыгын искә алып, аңа "Җәүдәт мәчете" дигән исем бирделәр.

Аннары икенче мәхәлләбездә дә мәчет төзелде. Аны төзүдә шул ук Җәүдәт Кәримов, Әгерҗе районы "Агрохимсервис" акционерлык җәмгыяте генераль директоры Ринат Закиров, аның туганнары Рәсим һәм Рөстәм Закировлар зур булышлык күрсәттеләр. Аларның беренчесе "Ялкын" күмәк хуҗалыгын җитәкли, икенчесе районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы булып эшли.

Җәүдәт Кәримов, мәчеткә кагылышлы нинди генә йомыш белән керсәк тә, ярдәм итәргә тырыша. Еш кына үзе дә безнең янга килеп, хәлебезне белеп чыга. Иншалла, алдагы көннәребездә дә безгә ярдәмен кызганмас, дин юлында мәрхәмәтле җитәкче булып калыр, дип ышанабыз.

Вәссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһу вә бәрәкәтүһ!

Габдулла ГАЛИЕВ,
"Җәүдәт мәчете"нең имам-хатыйб вазифаларын башкаручысы.

Сәхифәне Харис ЗАКИРОВ әзерләде.
М.ШАКИРҖАНОВ фотолары.

Йолдызнамә (16-22 февраль)

КУЧКАР (21.03-20.04). Бу сезнең өчен чын мәгънәсендә иҗат, хезмәт атнасы. Тырышлык, хезмәттәшләрегез белән дустанә мөнәсәбәт сезгә үсеш китерер, дәрәҗәгез тагын да күтәрелер. 17 февраль көнне матди зыян күрүдән саклангыз, чит-ят кешеләргә ышанмагыз. 21е көнне сәламәтлегегез турында кайгыртучанлык таләп ителер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). Элек урнаштырган эшлекле мөнәсәбәтләрегез сезгә икеләтә уңыш китерер. Партнерларны дөрес сайлый белү сезнең төп сыйфатлардан булса, финанс мәсьәләсендә дә ялгышмау таләп ителә. 21е көнне максатчан сәфәргә чыгарсыз һәм үзегез теләгән нәтиҗәләргә ирешерсез.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05-21.06). Атна сездән гаҗәп зур сабырлык таләп итә. Язмыш борылышлары сынаудан сынауга илтә, күңелсез вакыйгалар китерә. Матди хәлегезгә дә зыян килү куркынычы зурдан. 19, 22се көннәрендә финанс мәсьәләсендә, йорт байлыклары белән эш иткәндә уяулык күрсәтегез, чит-ятлардан да, туган-тумачаларыгыздан да сакланыгыз.

КЫСЛА (22.06-22.07). Сөбханалла! Кысла иң бәхетле мизгелләрен кичерә. Атнаның иң бәхетле кешесе ул. Тормыш юлы яктыга, биеккә, матур киләчәккә әйди. Аның эшләре уң бара, табыш керә, гаиләдә иминлек. 20се көнне яңа проектларга керешмәгез, игътибарыгызны гаиләгезгә, туганнарыгызга, иң якын, кадерле кешеләрегезгә юнәлтегез.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). 19, 20, 22се сезнең өчен уңайлы көннәр. Очрашулар, элемтәләр, хезмәттәшлек көтә. 17се көнне юлда, транспортта йөргәндә, эш урынында бәхетсезлектән саклану кирәк. Атна сезнең алга сынаулар куя, бәхәсле минутлар да бар, кешеләрнең шәфкатьсезлеге сездә рәнҗү тудыра. Сез бу начарлыктан өстен булырга тырышыгыз, ихтыяр көчегезне туплап, авырлыкларны җиңү күпкә хәерле.

КЫЗ (24.08-23.09). Сез илаһи көчләр карамагында. Эшлекле мөнәсәбәтләрегез уңышлы булыр. Ләкин 18е көнне акча югалту куркынычы бар. 19ы көнне ызгыш-талаштан сакланыгыз. 20се көнне сәламәтлек турында кайгырту таләп ителә. Көтелмәгән очрашулар, вакыйгалар булуы ихтимал. Атнаның соңгы көне сезнең сабырлыкка бүләк булыр. Ул сөенечле, бәхетле көн.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). Сез атна дәвамында илаһи серле көчләр карамагында. Рухи ихтыяҗыгызга колак салыгыз, җан таләбе белән яшәргә омтылыгыз. Изге гамәлләргә юнәлтелгән ихтыяҗыгыз сөенеч, үсеш китерер, гомумән, эшләрегез, тормышыгыз уң булыр. Күңелле вакыйгалар шаһите булырсыз, очрашулар ләззәт бирер.

ЧАЯН (24.10-22.11). Сезне юллар көтә, 20се көнне табыш керә. Ләкин сез шактый гына ямьсез сөйләшүләрнең сәбәпчесе. Кешеләрне, хезмәттәшләрегезне, гаилә кешеләрен сәбәпсезгә рәнҗетмәгез, аларның рухын төшермәгез. Үзегезгә җан тынычлыгы табу өчен тирә-юньдәгеләргә шәфкатьлелек кылыгыз, мәрхәмәтле булыгыз.

УКЧЫ (23.11-21.12). Сез атнаның иң бай кешесе. 16, 22се көнне зур керем көтелә. Тормышыгызда күңелсез вакыйгалар, бәхәсләр күзәтелсә дә, сез эшегездә үсеш кичерәсез, уңышларга ирешәсез. Гаиләгездә аңлашучанлык, ярату, хөрмәт өстенлек итә.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). 16, 19, 21е сезнең өчен уңайлы көннәр. 17се көнне бәхәсле вакыйгалардан читтә калырга тырышыгыз. 18е көнне акчагызны саклагыз, матди байлыкларыгызны игътибарда тотыгыз. 20се көнне илаһи серле көчләр сезнең карамакта. 22се көнне табыш көтелә.

СУКОЯР (21.01-19.02). 18, 21, 22се сезнең өчен уңышлы көннәр. Атнагызның бәхәстән башлануы ихтимал. Үзегезне чикли белегез, сабырлык күрсәтегез. 17се көнне зур эшләргә, яңа проектларга керешмәгез. 20се көнне матди югалтулардан сакланыгыз.

БАЛЫК (20.02-20.03). Сез атнаны иң мөһим мәсьәләләрне хәл итүдән башлап китегез, уңышлы булыр. 17, 19, 20, 21е шулай ук сезнең өчен уңайлы көннәр. Илаһи көчләр дә сезнең ярдәмчеләрегез.

Федор ШАЛЯПИНның туына 125 ел

"Җырлап яшәү мине таң калдыра"

13 февральдә бөек якташыбыз, үзенең кабатланмас таланты белән бар дөньяны таң калдырган Федор Шаляпинның тууына 125 ел тулды. Бу олуг бәйрәмне без дә зурлап билгеләп үтәбез.

1982 елның февраль аенда Казанда, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында опера сәнгатен бөтен дөньяга танытkан мәшһүр җырчыбыз Ф.Шаляпинга багышланган опера фестиваленә нигез салына. Бу фестивальне оештыручыларның берсе –



танылган җырчыбыз, опера театрының баш режиссеры Нияз Курамша улы Даутов була.

Мин бу фестивальне ачуга әзерлек вакытын, оештыручыларның, зур җаваплылык тоеп, янып-көеп йөрүләрен, фестивальне тәүге тапкыр ачып җибәрү мизгелләрен үз күзләрем белән күргән, үз йөрәгем белән кичергән кеше. Шунысы хак: фестивальне ачып җибәрү җөмһүриятебезнең мәдәни тормышында зур вакыйга булды.

Язучы М.Янковскийның "Шаляпин" исемле китабына Нияз ага Даутов миңа болай дип язып биргән иде: "Кадерле Айрат! Безнең өчен үтә дә дулкынландыргыч булган бу көннәрдә Сезнең дусларча мөгамәләгез, ярдәмегез өчен бик зур рәхмәт. Н.Даутов".

Бу гүзәл опера фестивале, шул көннәрдән алып, шәһәребездә ел саен уздырылып килә. Баштарак ул Бөтенсоюз фестивале дип аталса, соңгы елларда Халыкара фестиваль дәрәҗәсен алды. Менә быел февраль аенда, бөек якташыбызның тууына 125 ел тулган көннәрдә, Ф.Шаляпин исемендәге Халыкара фестиваль 17 нче мәртәбә үткәрелә.

Әйе, Шаляпин фестиваленә быел 17 ел тула һәм, быел да опера сөючеләр аны гүзәл мизгелләр бүләк итүче олы сәнгать бәйрәме итеп көтеп ала. Хәзер инде ышанып әйтергә була: даншөһрәте ерак-еракларга таралган халыкара Шаляпин фестиваленең киләчәге бар, ул матур. Ул елдан-ел ныгый, көч ала, тамырларын тирәнгә җәя. Опера фестивале белән бергә аның үз тамашачысы да үсә, камиллэшә бара. Һәр фестивальдә залларның халык белән шыгрым булуы нәкъ менә шул турыда сөйли ләбаса.

Фестивальләр барышында оештырыла торган Шаляпин укуларында опера сөючеләр теләп катнаша, опера сәнгате, классик җырчыларның башкару осталыгы турында үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтә алалар.

Чыннан да, Шаляпин фестивале безнең барыбызга да опера музыкасын тирәнтен аңлау, аны ярату өчен әйтеп бетергесез зур этәргеч бирә торган зур вакыйга. Безгә ул нәкъ менә шушы ягы белән кадерле һәм якын.

Мин үзем, шәхсән, бөек якташыбыз Ф.Шаляпин иҗаты белән 60 нчы елларда аеруча кызыксына башладым, Шаляпин үзе язган һәм аның турында чыккан китапларны һәм дә аның тавышы язылган тасмаларны җыярга керештем. Аның турында тулырак мәгълүматны ул вакытта М.Горький музеенда алырга мөмкин иде.

1954 елны мин, Октябрьнең 40 еллыгына багышланган нәфис сүз осталарының Бөтенрусия конкурсында катнашып, лауреат булу бәхетенә ирешкән идем.

Конкурс Мәскәүнең Яблочкина исемендәге актерлар йортында үткәрелде һәм шунда миңа Ф.Шаляпинның кызы Ирина Федоровна Шаляпина белән танышырга насыйп булды. Ул һәр көнне конкурста катнашучыларны тыңларга килә, "Нәфис сүз жанрын бик яратам, ә бирегә бөтен Русиядән башкаручылар җыелган, барысын да ишетәсем килә", дия торган иде. "Әтием дә яхшы укучыларны бик ярата иде, үзе дә кайбер әсәрләрдән монологларны бик оста укый иде", – дигән сүзләре бигрәк тә хәтеремә уелып калган.

Лауреатлар хөрмәтенә үткәрелгән мәҗлестә дә урыным аның белән янәшә туры килде. Бик озак тәмләп сөйләшеп утырдык. "Әтиемнең якташы белән очрашуыма шатмын", – дип башлаган иде ул сүзен.

Ирина Федоровна миңа Федор Ивановичның Казанны, татарларны бигрәк тә яратуы, үзе дә, Казанда булган саен М.Горький музеена кермичә китмәве, казанлыларның әтисенең якты истәлеген кадерләп саклавы турында тәфсилләп сөйләде. Шул кичәдә ул миңа С.Вургун китабына үз кулы белән түбәндәге сүзләрне дә язып бирде: "Яшь дустым Айратка – әтиемнең якташына бәхет һәм иҗади уңышлар телим. Ирина Шаляпина. 4/XII – 57 ел. Мәскәү".

Шуннан соң да, Мәскәүгә барган саен, Актерлар йортында Ирина Федоровна белән тагын берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Күрешкәндә ул, һәрчак мөлаем елмаеп: "Әтиемнең якташы белән кабат очрашуыма бик шатмын", – дия торган иде. Федор Ивановичның Казанны бик яратуы, чит илдә яшәгәндә дә үзенең хатларында Казанны еш искә алуы турында җанланып сөйли иде ул. Мин үз чиратымда: "Казан халкы Шаляпин исеме белән бәйле изге урыннарны кадерләп саклый, аның белән чынчынлап горурлана", – дип рәхмәт әйтә торган идем.

Ф.Шаляпинның үзе язган һәм аның турында чыккан китапларны укыгач, бөек җырчы гомере буена Казанны яратып, сагынып яшәвен, кайда гына торса да, җаны һәрвакыт Казанга омтылуын күрәсең. Чит илдән кызларына язган хатларында ул еш кына: "Кайтып Казанны күрәсе иде, Суконный бистәсен тагын бер әйләнәсе иде..." – ди. Ә бер хатында: "Дөньяның нинди генә гүзәл шәһәрләрен, елга-күлләрен күрмәдем, әмма аларның берсе дә минем өчен Кабан күлен алыштыра алмады", – дип яза.

Даһи җырчы буларак бар дөньяны таң калдырган Ф.Шаляпин операны да беренче мәртәбә нәкъ менә Казанда тыңлаган һәм бу турыда уй-хисләрен кәгазь битләренә төшергән: "...Опера мине таң калдырды... Анда, сәхнәдә, бер дә сөйләшмиләр, фәкать җырлап кына аңлашалар. Җырлап яшәү мине таң калдыра".

Быел без даһи җырчыбызның тууына 125 ел тулуны шатлык вә горурлык хисләре белән билгеләп үтәбез. Казан урамнарын февраль башыннан ук Шаляпин фестивале ачылуын игълан иткән афишалар бизи. Театр фойесында фестивальгә килүчеләрне Шаляпин заманындагы Казан шәһәренә багышланган күргәзмә каршылый һәм без бөек якташыбыз өчен тагын бер кат сөенеп: "Шаляпин янә Казанда!" – дибез.

Айрат АРСЛАН,
Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе.

بسم الله الرحمن الرحيم

ايمان الفباسى

Иман әлифбасы
IMAN ӘLIFBASЬ

Иртәгә, 14 февральдә, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында республикабыз мөселманнарының корылтае ачыла. Корылтайда соңгы ике елда Татарстандагы мөселман җәмгыятьләре башкарган эшләргә йомгак ясалыр, киләчәккә төп юнәлешләр билгеләнер, Татарстан мөфтие, Диния нәзарәте һәм аның казые сайланыр. Мөфти итеп 6 кандидат күрсәтелгән. Шулардан берсе делегатларның ышанычын казаныр, иншалла! Корылтай моңарчы Татарстанда яшәп килгән ике Диния нәзарәтен дә берләштерер дип өметләник.

Татарстан Президенты Минтимер ШӘЙМИЕВ:

– Руханилар бүген яңарыш юлларын эзли, һәм Татарстандагы хәл моннан 4-5 ел элек Русиядә булган сәяси хәлгә охшаш. Аларның үзгәртеп коруы башланды сыман. Бу процесслар, минем уйлавымча, җәмгыятьтә котылгысыз. Лидерлар барлыкка килә, үзләренең мөфтиятләрен, үз тарафдарларын булдырырга тырышалар. Ләкин бу проблема, бүгенге белән чагыштырганда, моннан ике ел элек кискенрәк торды. Хәзер дин лидерлары берләшергә кирәклеген, алга таба болай дәвам итә алмавын аңлый башладылар. Шушы көннәрдә мин ике төп мөфти белән очраштым. Без мөселманнарның Бөтентатарстан корылтаен чакырабыз. Берләшүгә ирешелер дип уйлыйм.

Кыйблабыздан тайпылмыйк

Балтач районында 4-5 ел инде күркәм традиция яшәп килә. Һәр айның беренче атнасында барлык мәхәлләләрнең имамнары катнашында аларның ихтыяҗларына бәйле мәсьәләләр тикшерелә. Бу киңәшмәләрдә район җитәкчеләре дә катнаша.

– Бүген, Аллаһы насыйп итсә, безнең очрашуыбыз өз генә үзгәрәк булыр, – дип башлады сүзен Балтач районы мөхтәсибе **Җәлил** хаҗи **ФАЗЛЫЕВ.** – Безнең алда Аллаһы тәгалә каршысында да, илебез каршысында да, милләтебез каршысында да зур эш тора – мөселманнарның корылтае була. Ислам канунннары буенча, һәрбер дин әһеле сайлап куелырга тиеш. Монда утыручыларның берсе дә бу гамәлне үтмәгән. Дөрес, мәчет ачканда кул күтәртеп сайланган кешеләр бар, алары да ике-өч кандидатура куелып, яшерен тавыш белән сайланган түгел. Әмма тормыш алга таба бара. Безнең барлык мәхәллә имамнарыннан алып мөфтигә хәтле – барысы да сайланып куелган булырга тиеш. Элек тә шулай булган ул. Моңарчы без ике тапкыр мөфти сайладык, бер кандидатурага каршы килмибез, дип ризалык бирдек. Ә хәзер алты кандидатура. Дини җитәкчене сайлаганда нинди шартлар куела соң? Иң беренчесе – гыйлемле булу, тәкъвалык шарт. Икенчесе – тәҗрибәлелек, олы яшьтә булу. Яшьләре тигез булса, чибәре, мәхәббәтлеләрәге. Ул яктан да берберсенә тиңдәш икән, тавышы – кайрәаты матур булганы, матур тавыш белән Коръән укыганы. Безнең имамнарга да шул таләпләр куела. Мөфти – шулай ук имам. Менә без шушы сыйфатларына карап фикерләргә тиешбез.

– Минем имамнар белән очрашуымның бер сәбәбе республикада узачак мөселманнар корылтае уңаеннан, – диде район хакимияте башлыгы **Марат ӘХМӘТОВ**. – Без күптән түгел генә шушы мәсьәлә буенча Президентта очрашуда булган идек. Президентыбыз мөселманнарның дини хәрәкәтендәге таркаулыкка, үзара башбаштаклык дип әйтик инде, бик борчыла. Шушы хәлгә Русия дәүләте җитәкчеләре алдында да, бүтән милләт халыклары алдында да бик читенсенәм, диде ул безнең алда чыгыш ясаганда. Һәм безгә дә, үз чиратында, районыгызда дин әһелләре белән очрашыгыз, сөйләшегез әле, аларның фикер-киңәшләрен тыңлагыз, диде. Менә шушы булачак корылтай республикабыз мөселманнарын берләштерүне хәл итәргә тиеш. Дини хәрәкәттә үзара сугышып-тарткалашып яшәү Аллаһ тәгалә алдында нинди дәрәҗәдә гөнаһ икәнен үзегез күз алдына китерәсездер. Димәк, үзара шушындый кискен ызгыш-талаш мөнәсәбәтенә кергән дин әһелләре үзләренең ниндидер мәнфәгатьләрен Аллаһы тәгаләдән дә өстенрәк куя торган кешеләрдер, дип саныйм. Аларны, гомумән, андый вазифаны башкарырга һәм Аллаһы исеменнән сөйләп, мөселманнар белән идарә итәргә лаеклы түгел дип уйлыйм. Очрашуда Президент та менә мондый фикерләр әйтте. Республикабызның, татар халкының йөзен, тормышын, бөтен яшәү рәвешен, бөтен дөнья халкы, бигрәк тә башка милләтләр каршында да лаеклы итеп тәкъдим итә алырдай шәхес булсын иде Татарстан мөфтие. Һәм, әлбәттә, аны дини хәрәкәтне берләштерә алырдай шәхес итеп күз алдына китерәбез. Үзегез шаһит: халыкны дингә, мәчеткә тарту эше бик авырлык белән бара. Һәрберегез булдыра алганча, тешегез-тырнагыгыз белән, бөтен барлыгыгыз белән шушы эшкә бирелгәнсез. Билгеле, бу өлкәдә эшләү җиңел түгел.

Мин үзем әле генә район үзәгендәге мәчеттә узган гает намазында катнашкан идем. Бер уйлаганда, күңелемнән куандым: яшьләр бик күп иде. Күңелдә ул өмет уята. Икенче яктан караганда, 7 мең кеше яши торган Балтачта мәчеттә генә түгел, ә аның ишек алдында да энә төртер урын булмаска тиеш иде кебек. Әмма мин җаным-тәнем белән рәхмәтле үзенең кыйбласын шушы мәчет юлында, Аллаһы юлында сайлаган кешеләргә. Бигрәк тә яшь буынга. Менә шушы вакытта, әйткәнемчә, динчеләрне берләштерәсе, шушы халыкны туплыйсы урында, бигрәк тә Казан шәһәрендә дип әйтим инде, таркату белән шөгыльләнүчеләр бар. Бу мәсьәлә республикабыз җитәкчелеген бик нык борчый.

Тарихның кайсы гына чорын алып карасак та, таркау булган дәүләт яши алмаган. Власть, дәрәҗә, урын бүлешә торган дәүләт һәрвакыт җимерелгән. Бездә сөйләнә торган мәзәкне искә төшерик. Имеш, теге дөньяда тәмуг казанында яһүдләр, һич булмаса син минем җилкәмә басып чыгып азат бул, дип әйтеп, бер-берсен тәмугтан коткарырга булыша, ди. Чөнки алар – тату халык. Ә бер татар, мин көчлерәк, мин чыгыйм әле, дип үрмәли башласа, икенчесе мин монда янганда, ничек син чыгарга тиеш әле, дип, тегесен аягыннан тартып үзе янына төшерә, ди. Безнең мөселман динендәге шушы таркаулык моңа бер мисал. Шуңа да Президент бу корылтай төрлетөрле ызгышка чик куяр, Татарстан мөселманнарын – дин тотучыларны берләштерер, дип өмет баглый. Шушы очрашуда кандидатлар мәсьәләсендә уртак фикергә киленде. Бу мәсьәләгә беркем, шул исәптән, республика җитәкчеләре дә битараф кала алмыйлар. Хәтта дәүләт корылтайны уздыру белән бәйле чыгымнарны үз өстенә алырга тиеш булды. Әмма моны дин эшенә тыкшыну дип уйларга ярамый. Чөнки бу чараны уздырырга дин оешмаларының мөмкинлеге җитми. Әмма сезгә, авылдашларыгыз алдында үзегезне гаепле итеп тотмас өчен, һичсүзсез, намусыгыз кушканча тавыш бирергә кирәк булачак. Чөнки берәү дә, тегене яз, моны сыз, дип мәҗбүр итмәячәк.

Без – район җитәкчеләре, дин юлында бергәләп хезмәт итәргә, җитәкләшеп эшләргә тиеш, дип саныйбыз. Күбрәк халыкны шушы юлга тарту – безнең дә турыдан-туры тәрбия эшебез, дип уйлыйбыз.

Дөрес, Конституциядә, дин дәүләттән аерылган, дип әйтәләр. Шушы дәүләт үз кулы белән динне, мәчетләрне бетергән икән, шушы дәүләт үз кулы белән, үз ярдәме белән бу хәрәкәтне, аның матди базасын да булдырырга, торгызырга тиештер, дип тә уйлыйм.

* * *

Киңәшмәдә мәктәпләрдә дин тарихын укытканда дин сабакларын бирү, укытучыларга һәм биш намаз укыла торган мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә дин сабакларын алып баручы мөгаллимнәргә түләү, балалар бакчаларында мөселман дине буенча башлангыч мәгълүматлар бирү мәсьәләләре тикшерелде һәм район җитәкчеләре аларны уңай хәл итәргә ышандырдылар.

Шәех ЗӘБИРОВ.

Хәерне кемгә бирергә?

Бүгенге көндә мәчеттә, муллалар арасында барган бөтен талаш, сугышлар да шул хәер акчасы өчен чыгадыр. Бик гадел эшләгән мулланы да, аңа ялган бәла ягып, аның халык алдында дәрәҗәсен төшерәләр. Гадәттә, үзе мулла булып, хәер акчасын урлап яшәргә теләгән намуссыз кеше гадел муллага яла яга. Бу хәлләр дин башлыкларына, мәчеткә, дингә карата халыкта нәфрәт уята.

Мәчет өчен хәер акчасы җыюны бетерергә кирәк. Әгәр ул бетерелмәсә, мәчеттә, дин эшендә беркайчан да тәртип булмаячак. Хәер-сәдаканы мәчетләр каршындагы хәйрия оешмаларына (башта аларны оештырып) тапшыру гадел булыр.

Муллаларга халыкны тәрбияләү өчен шарт тудырырга – хезмәт хакы түләргә, ә урлашу өчен мөмкинлек бирмәскә кирәк.

Әкълимә ИСХАКОВА.

Минзәлә шәһәре.

Сез рәсемдә Чаллыдан мөгаллимә Гөлнур Хәйруллинаны кызы Исламия белән күрәсез. Гөлнур ханым әле гыйнвар аенда гына "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлады. 12 яшьлек кызы да Коръәнне гарәпчә укый, бик күп догаларны белә, намаз укый.

Фотохәбәрчебез **Мидхәт ШАКИРҖАНОВ** аларны мәдрәсәдә төшереп алган.

Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы

ҖӘЛИЛ хәзрәт мөселманнар алдында һәр атнаның җомгасында, көн ихтыяҗларыннан чыгып, яңа вәгазь укый. Ә менә укучыларыбызга тәкъдим ителә торган вәгазьдән өзек бүген дин оешмалары җитәкчеләре арасында барган хәлләргә кагыла.

Без, дингә, халыкка хезмәт итәбез, дибез икән, байлык кайгысы, мал кайгысы арткарак чигенә. Беренче урында динне тарату торырга тиеш. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә ("Нәхел" сүрәсе, 125 нче аять) әйтте: "Бәндәләрне Аллаһы юлына Коръән дәлилләре белән, тәэсирле сүз белән, яхшы вәгазьләр белән һәм күркәм юллар белән өндәгез, динегез өчен көрәшегез", диде. Аллаһы Раббыбызның өйрәтүләрендә "Бер-берегезне мыскыл итегез, бер-берегезгә теләсә нинди сүзләр әйтегез, бер-берегезнең тырнак астыннан кер эзләгез", дигән сүзләр юк.

Хикмәт белән, белем белән, үзеңнең барлыгың, бирелгәнлегең, үзеңне тота алуың белән динегезне шушылай итеп алып барыгыз, диде. Бүген, Аллаһу сакласын, урамнарда гына түгел, иман китергән кешеләр хәтта мәчет эчләрендә дә бер-берсенә кычкырып, тупас сүзләр әйтүдән тайчанып тора алмыйлар. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әйтте: "Әгәр берәү сиңа начар сүз әйтә, начарлык эшли икән, син аңа, әлбәттә, яхшылык белән җавап кайтар. Тагын сиңа начарлык эшли икән, тагын син аңа яхшылык белән җавап кайтар. Килер бер көн, ул үзенең ялгышын аңлар һәм синең дустың булыр", – диде. ("Фүссиләт" сүрәсенең 34 нче аяте). Безнең бүген нәфесебезне җиңүебез, ачуыбызны эчкә алуыбыз, бер-беребез белән үпкәләшмәвебез, дус торуыбыз ул – безнең һиҗрәтебез, җиһадыбыз. Без үзебезнең нәфесебезне тыеп торабыз икән, димәк, Аллаһы юлында торабыз. Һиҗрәт ул – Аллаһы юлына чыгу. Без үзебезнең күркәм холыкларыбызны расларга теләп, начар гадәтләребездән арынабыз, тиктормас телебезне тыябыз, нәфесебез белән, мин-минлегебез белән көрәшәбез икән, бу менә җиһад була. Менә бу һиҗрәтебез була.

Безне Аллаһу тәгалә сыный. Әмма без әле белмибез: кайсысы безнең соңгы сыналуыбыз булыр? Аллаһының тагын күпме сынайсы бар икән? Белмибез. Безгә берәр авырлык килә икән, берәрсенең безне үпкәләтәсе килә икән, без монда үзебезне мөселманнарча тотарга тиеш, аны Аллаһының сынавы дип кабул итәргә кирәк.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһиссәлам әйтте: "Зур гөнаһлар кечкенә гөнаһлар эченә яшерелгән. Зур саваплар кечкенә саваплар эченә яшерелгән", – диде. Әгәр безнең алдыбызда торучы бер кешене, бу бернәрсә дә эшли алмый, моңа нәрсә әйтсәк тә була, дип, аңа теләсә нәрсә әйтсәк, теләсә ничек аны мыскыл итсәк, ялгышабыз. Ул, бәлки, Аллаһы тәгаләнең иң сөекле бәндәседер?! Бәлки, без шушы сүзебез белән Аллаһы тәгалә каршысында төзәтеп булмаслык зур хата эшлибездер. Без бит Аллаһы тәгаләгә кемнең якынрак икәнен, кемнең эшләгән саваплары күбрәк икәнен дә белмибез.

Аллаһы Раббыбыз күңелләребезгә, калебләребезгә нур салып, Аның сүзләрен ишетергә, Коръән аятьләрен аңларга мәгърифәт иңдерсә иде. Шуңа ирешеп, Аллаһы тәгалә кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә язсын. Алдыбызда торган сынауларны чын мөселманнарча дәрәҗә белән, матур иттереп үткәрергә кирәк. Шуны насыйп итсә иде Аллаһы Раббыбыз барчабызга да.

Игътибар яңа рубрика:

Мәшһүрләр дә адәм баласы

Менә сиңа Алтынчәч...

– Элек мин операны яратып бетерми идем, – ди Татарстанның халык артисты Венера Ганиева. – Ә миңа опера җырчысы булырга язган икән...

Тик әле аңа кадәр атаклы "Саз" ансамблендә, шул ансамбльнең җитәкчесе, танылган баянчыбыз Рәфкат Гомәровтан нотага, җыр осталыгына өйрәнә ул. Аннары музыка училищесында 4 ел буе белем ала. Музыка училищесына ул "Ай, былбылым"ны җырлап керсә, консерваториягә керү имтиханнарында инде Нәҗип Җиһановның "Алтынчәч" операсыннан Алтынчәч ариясен башкарып күрсәтә. Венера үзе:

– Консерваториягә мине кабул итмәделәр, – ди. – Алтынчәч ариясен башкарганда бик дулкынландым, бер-ике урында фальш җибәрдем бугай. Көннәрдән бер көнне документларымны алырга килгән идем, коридорда Нәҗип ага Җиһанов туктатты. Шул көннән берьюлы әзерлек группасына да, 1 нче курс студентлары лекциясенә дә йөри башладым. 4 ел эчендә консерваторияне тәмамладым.

Ә байтак еллардан соң В.Ганиева М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында берничә операда, шул исәптән Н.Җиһановның "Алтынчәч" операсында Алтынчәч партиясен башкарган өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Ак каеннар белән аңлашу

– Татарстанда минем турыда яхшы беләләрдер, – ди Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Айдар ГАЛИМОВ. – Башта автотранспорт техникумында белем алдым, армиядә хезмәт иттем. Башкорт дәүләт университетының юридик факультетын тәмамладым. Хәзер исә Казан педагогика университетының музыка факультетында, өченче курста укыйм. Әнием – татар теле укытучысы, әтием – шофер.

Ә гаиләм турында кайбер яшь кызларга болай дип җырлыйм: "... Ак каеннар, ак каеннар, ник шауламыйсыз, ике кызым, хатыным бар, ник аңламыйсыз..."

РЕДАКЦИЯДӘН. Популяр җырчы белән әңгәмәне киләсе саннарның берсендә укый аласыз.

Сынык куллы Кармен

Мәскәүнең Зур театр примадоннасы, танылган җырчы Елена Образцованы Санкт-Петербургта Мариинка театрында чыгыш ясаганда "ашыгыч ярдәм" машинасы хастаханәгә алып китә. Җырчының партнеры, ипсез кыланып, аның кулын сындыра. Бу хәл "Кармен" операсы барганда килеп чыга. Хосе ролен башкаручы тенор Юрий Луцюк, режиссура һәм либретто таләп иткәнчә җырлап, каны кызып, Карменны этеп җибәрә. Образцова авыртудан кычкырып куя. Тамашачы артистларны шашып алкышлый. Ләкин артист сәхнәдән китми, авыртуга түзеп, кулын шәл белән каплап, үз партиясен ахыргача җырлый. Шуннан соң гына табибларга буйсына. Аны сәхнә (Кармен) костюмында операция залына китерәләр. Кул сынган, катлаулы операция була. Табиблар җырчының сабырлыгына хәйран калалар. Әмма аңа Литвада буласы гастрольләреннән баш тартырга туры килә.

("Известия").



Кемнең машинасы шәбрәк?

Артист халкының машинасы бар инде ул. Берәү генә дә түгелдер әле. Хәер, ничәү һәм нindиләр икәнен үзләреннән белешик әле.

Татар эстрадасының иң популяр җырчысы **Салават Фәтхетдиновның** ничә машинасы барлыгын төгәл генә әйтеп булмый. Чөнки "корыч айгыр" җене кагылган җырчыбызның бүген-иртәгә тагын бер машинасы барлыкка килүе дә бик ихтимал. Казанга "Дуслар булса, кайгырма" дип аталган концертын куярга асфальт төсендәге "Geep" белән килгән иде. Шуны да әйтергә кирәк, Салават автокроссларда да бик актив катнашып килә.

Җәүит белән Зөлфия Шакировларныкы "99"лы. Кайгырмагыз, бөтен шөребе дә үз урынында. Аңлагансыздыр инде, "җүләр" дигән машина түгел, әлбәттә. "Нинди төстә соң?" – дип соравыбызга Җәүит: "Үзем төсле", – дип җавап бирде. Күз алдына китергәнсездер, шәт.

Газинур Фарукшинның ак "Жигули"ен белмәгән кеше юктыр инде. Руль артында җырлап йөри-йөри онытылып китеп, гел ГАИга эләгеп торганын да беләсездер. Күптән түгел генә шул машинасын саткан да инде Газинур. Яңаны алырга уйласа, милиция кырыеннан выжылдатып узып китә торганын гына алсын иде инде.

Равил Шәрәфинең машинасы "велосипед" дип атала. Безнеңчә, сәпит була инде.

Зәйнәп белән Зөфәрнеке – "Рено". Белмәсәгез, белегез: BMWдан да шәбрәк машина ул.

Алмаз Хәмзин җәяү йөри. Артыннан этеп йөри торган машинасын саткан. "Сез аласын белгән булсам, бушка биргән булыр идем", – ди.

Хәния Фәрхи-Бикташирова үзенең бөтен гастрольләренә "Газель"дә генә җилдерә.

Гөлдания белән Рөстәм Хәйруллиннар һәм аларның иҗат төркеме "Волга" һәм "УАЗ"икта йөриләр. "Элек бер "Ока"га ничек сыеп беткәнбез икән?" – дип гаҗәпләнәләр.

Асаф Вәлиевнеке дә – "99"лы. Әмма үзе төсле түгел. Юеш асфальт төсендә.

P.S. Соңгы мәгълүматларга караганда, татар җырчылары һәм артистлары арасында самолет алучылар ишетелми әлегә.

("Бердәмлек").

Кияү дә качмаган, кәләш тә тыныч

"Алла Пугачеваның кызы Кристина Орбакайтеның башын-күзен әйләндергән теге "текә" чичән качкан икән..."

"Кристина бала көтә, диләр бит..."

"Мин ишеткән идем: Кристина "Раштуа очрашулары"нда егылган икән дә, хәзер баласын таба алырмы, юкмы..."

(Кухняда сөйләшүләрдән).

Бу сүзләр дөресме, әллә гайбәт кенәме – шуны ачыклар өчен без Мәскәүдәге "Инфант" концерны директоры Руслан Байсаровка мөрәҗәгать иттек. Ә чичән егете Руслан – Кристинаның булачак кияве бит инде.

Руслан Байсаров болай диде:

– Гайбәт бу. Кем уйлап чыгарадыр, шайтан белсен. Качарга уйлаганым да юк, менә фирмам белән җитәкчелек итәм, ул – халыкара сәүдә үзәгендә урнашкан. Кристина белән очрашып торабыз. Кичә дә күрештек әле. Кәефе әйбәт, сәламәтлеге дә. Ходай кушса, бәбиебез туар, дип өметләнәбез.

("КП").

Бәйге алды ырымнары

Спортчылар – сәер халык, алар төрле ырымнарга ышаналар, ләкин бу турыда сөйләргә яратмыйлар. Шулай да кайчак ышанычлы кешегә серләрен ачалар. Сезгә таныш спорт осталарының "сер"ләрен чишик әле.

Ольга Князева, *фехтование буенча олимпия уеннары чемпионы:*

– Мин ярыш буласы көнне бөтенләй ашамыйм. Ач спортчы усал була. Ә фехтование ярышлары үткән мәйданда усаллык бик кирәкле сыйфат.

Ярыш алдыннан мин көндәшемне күрмәскә тиеш. Әгәр күрсәм, шундук уемнан аның белән үтәсе "көрәшне" бәйнә-бәйнә күз алдыма китерә башлыйм. Ә бу ярамый – болай ярышка кадәр үк "янарга" мөмкин. Тагы шунысын да күңелемә салып куйганмын: әгәр ярышларга юылмаган кием белән чыксам – отырам. Хәзер һәр ярышка кер дә тимәгән киемнәрдә чыгам.

Иң бәхетле "ырым" – тренерыбыз Владимир Житловны күргәндә. Мөһим ярышларга ул буйлы күлмәк киеп килә. 1976 елда командабыз Олимпия уеннарында җиңеп чыккач, бишебез дә Владимир Васильевич янына йөгерешеп килдек тә, безне күзәтеп торган меңнәрчә тамашачы алдында Житловның шул буйлы күлмәген ерткалап истәлеккә алдык.

Евгений Мишин, *"Синтез" ватерпол командасы баш тренеры:*

– Мин үзем ул кадәр үк ырымнарга, нindидер билгеләргә ышанмыйм. Шулай да матч алдыннан кырынмый идем. Күпләр шулай итә. Мин дә берничә көн кырынмыйча йөрдем – беренче җиңелүгә кадәр. Хәзер беркайчан да алай йөрмим. Тренер бик пөхтә булырга тиеш. Ә менә матчта җиңелүгә очрагач, киемне бөтенләй алыштырам. Хәтта трусик һәм башмакларны да.

Сергей Абрамов, *"Ак барс" хоккей командасы капкачысы:*

– Уен буласы көнне беркем белән дә сөйләшмим, беркемне дә күрмим. Кайчак дусларым үпкәли: янәсе, әллә нишләдең әле, исәнләшмисең дә... Тимераякларымны һәм щитокларымны һәрвакыт уң аягымнан кия башлыйм. Матч алдыннан була торган "разминка"га беренче булып гадәттә Леша Чупин чыга. Мин – аның артыннан. Һәм тагы бер мәҗбүри процедура бар: уен алдыннан, көндез, мин төп-төгәл ярты сәгать черем итеп алырга тиеш.

Рафаэль Газимов, *"КАИ-ТАЦИТ" гандбол командасы баш тренеры:*

– Мин ырымга бөтенләй ышанмыйм. Хәтта киресенчә: кара песи юлымны кисеп үткәнгә сөенәм, кәефем күтәрелә. Шундук каршы команда белән, хәтта теге дөнья көчләре белән бил алышасы килә башлый. Безнең команда ак кием бәхетсезлек китерә, дип саный иде. Ә менә күптән түгел, Русия чемпионатының чираттагы уены вакытында, Снежинскийның "Сунгуль" командасы белән ике арада булган бик мөһим матчка команданы ак киемнән чыгарга мәҗбүр иттем. Беләсезме, җиңеп кайттык бит!

"(Конец недели").

Гауга

"Шагыйрьләр авылда туа, шәһәрдә үлә", дигән әдип чыннан да хаклы. Мин әлеге фикерне авыл туфрагында бөреләнеп шәһәргә килгән бөтен иҗат кешеләренә карата да әйтелгән дип саныйм.

Авылдан чыккан талантлар язмышы белән шәһәрдә тәрбияләнгәннәрнеке нык аерыла. Авылларыбызга, анда эшләүчеләргә бары савым сыеры дип кенә карау, мәдәният йортларының фәкыйрьлеге, китапханәләрнең ярлылыгы, мәктәпләрдә уку-укытуның ташка үлчимлеге аркасында күп кенә талантларыбыз үз юлларын табарга дип шәһәргә килә. Чөнки ул дуңгыз, сарык фермалары юлындагы сазлыкка батып калудан, сәрхушкә әйләнеп, ике багана арасында адашып йөрүдән курка. Шәһәрнең якты утлы мәдәният йортлары үзенә сыйдырыр, җылытыр дип өметләнә. Чөнки аның үз талантын, сәләтен башкаларга да күрсәтәсе, үсәсе, күтереләсе килә. Талантымны, һичшиксез, шәһәр түрәләре дә күрер, төмле сүзләре, ачык йөзләре белән каршы алыр, алырга тиеш, дип хыялдану табигый бер нәрсәдер. Ә инде чит өлкәдә туган, ата-бабасының төп йорты дип санаган Татарстанына, аның да пайтәхете булган Казанга тартылу аеруча көчле.

Свердлау өлкәсендә туып-үскән җырчы Әлфирә Тимершина да үзен Татарстан кызы дип саный. Чөнки әтисе – Кайбыч ягыннан, әнисе – Минзәлә төбәгеннән. Кыз тәвәккәлләп 1983 елда Чаллыга юл тота. Шәфкать туташы буларак хастаханәләрнең берсенә эшкә урнаша. Әтиәнисенең борынгы татар халык җырларын үзәк өзгеч итеп башкаруларын, шулчакларда күзләреннән кайнар яшьләре тамуын күреп үскән, чит җирләрдә дә туган телен онытмаган Әлфирә кичләрен Ренат Гобәйдуллин җитәкләгән "Сердәш" ансамбленә йөри. Җырлый, бии. Иҗатташлары арасында гына түгел, тамашачылар арасында да абруй казана. Күпләр аңа укырга, профессиональ белемен күтәрергә киңәш бирә. Үз көченә нык ышанган Әлфирә, билгеле инде, Казанның үзенә юл тота. Төп эшеннән аерылмыйча, Казан музыка училищесына укырга керә, аның вокал бүлеген уңышлы гына тәмамлау бәхетенә дә ирешә. Радио-телевидение тапшыруларында катнаша, төрле фестиваль-конкурсларда чыгышлар ясый. Үз тавышы, үз моңы булган җырчыны күреп алалар һәм Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә чакыралар.

Ә мондый бәхет бик азларга гына тәти. Тагын да канатланып иҗат эшенә чума Әлфирә. 1991 елда үткәрелгән "Җырлы Татарстан" бәйгесендә катнашып, лауреат исемен ала. 1993 елда уздырылган Халыкара "Җыр – 93" конкурсында дипломант була.

Сүз уңаенда чит-ят җирләрдә туып-үскән, шытым биргән талантларыбызны шәһәр тормышы үзенең мең дә бер каршылыклы яклары белән сынавын, бөгүен, таптавын да искәртеп узу кирәктер. Бүген әдәбият-сәнгатьтә үз урыннарын алган авыл малайлары, кызлары боларның барысын да үз җилкәсендә татыган, чәч чаларткан. Шәһәрләрдә туып-үскән талантлардан аермалы буларак, аларны иртәләрен, кичләрен кайнар ашлар, күпертелгән мендәрләр көтеп тормый шул.

Кыршылган чемоданнары белән өстерәп тулай торакларга, йә булмаса, чит-ятларның салкын идәннәрендә барлы-юклы акчаларын түләп, озын төннәр үткәрергә мәҗбүр инде алар. Сәхнәдә үз урынын яулар өчен Казанга килгән Әлфирә дә моннан күп тапкырлар авыз иткән җырчы. Төрле оешмаларның тулай торакларындагы кысан бүлмәләрендә җан асрарга да, төрле холыклы кешеләрнең фатирларында почмак алып яшәргә дә өлгергән ул.

Боларга карап кына тормыш дигәнең тукталып калмый, әлбәттә, гел хәрәкәттә ул, үз агымы белән тәгәри бирә. Кияүгә чыккач, аңа Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе карамагына тапшырылган фатирдан 12 квадрат метрлы бер бүлмә бирәләр. Ике бүлмәгә исә аның белән бергә эшләгән җырчы Халидә Хәсәнова үз гаиләсе – ире, улы белән төпләнә. Өч бүлмәле фатир-тулай торакта алар 1989 елдан бирле тереклек итәләр. Ике гаиләнең анда ничек яшәүләре хакында бу очракта сөйләп вакыт үткәрү кирәкмәс. Шау-шу, гаугаларның көн саен чыгып торуын бәян итү дә, Халидә Хәсәнованың инвалид-авыру хәленә әверелүе дә икенче мәсьәлә, икенче тема. "Бер Казанга ике тәкә башы сыймый" дигән мәкальнең бик тә хак, төгәл әйтелгәнлеген искәртеп узу барысын да күз алдына китерер дип уйлыйм...

Моннан берничә айлар элек Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә 30 ел эшләп пенсиягә чыккан Халидә Хәсәнова, ниһаять, үзенең элеккеге күршесе Әлфирә Тимершинаның тырышлыгы, шәһәр хакимияте җитәкчеләренең булышлыгы ярдәмендә ике бүлмәле фатир алды.

Мондый бәхеткә тиенүенә ул Вахитов районы хакимияте каршында эшләп килүче пенсия фондына рәхмәтле.

Моңа кадәр ике баласы, ире белән югарыда күрсәтелгән торакта яшәгән Әлфирә Тимершина бүгенге көндә үзен шушы фатирда хуҗа булып калдыруларын, иркенләп яшәргә, иҗат итәргә рөхсәт бирүләрен сорый. Мөмкин булмаган очракта башка урыннан фатир бирүләрен дәгъвалый. Тик бу дәгъвасы аның Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчеләре белән тарткалашуга, гаугага сәбәпче булган. Моның шулай икәнлеген җырчының редакциягә язган хаты да, Казан шәһәр хакимиятенә, Татарстан Министрлар Кабинетына һәм Президентыбыз исеменә язылган хат-шикаятьләре дә раслый.

Әлфирә ул хат-шикаятьләре янына байтак кына оешмалардан алынган рәсми җаваплары да теркәгән. Арада ике гаиләгә бүлеп бирелгән торакта алардан башка, гәрчә анда яшәмәсә дә, Татар җыр һәм бию ансамблендә эшләүче Наилә Әкрәм кызы Вәлиеваның да пропискада торуын күрсәткәне дә бар. (Ә бүгенгә кадәр Әлфирә үзенең ирен прописькага кертә алмый җәфалана). Торакка акча түләү мәсьәләсендә аңлашылмаган нәрсәләр барлыгын раслаган хатны да теркәгән Әлфирә. Баксаң, моңа кадәр ике гаилә яшәгән торакта кемнең күпме мәйдан биләве исәпкә алынмаган икән. Мәсәлән, 1996 елның 1 гыйнварыннан 1997 елның 1 апреленә түләү аермасы 2 миллион сумга якынлашкан. Кечкенә баласы белән өйдә утырган, беркайдан матди ярдәм күрмәгән ана өчен шактый зур акча бу!

Яңа Савин районы хакимияте башлыгы В.Бударин кул куйган хаттан күренгәнчә, моңа кадәр тулай торак булып файдаланылган фатир 1997 елның 1 февраленда "кунакханә" статусына күчерелгән. Тик җитәкчелек бу үзгәрешне бирүдә яшәүчеләргә хәбәр итәргә генә "онытканнар"... Дистә елга якын шушы "кунакханә"дә яшәгән, төзелгәннән бирле ремонт чырае күрмәгән, беренче каттагы фатирга шушы елның 28 гыйнварында ике яшь кызны – Ирина Бабич белән Елена Саксонованы прописькага кертеп тә куйганнар. Хәзер исә алары: "Без шушында яшәргә тиеш", – дип көн саен Әлфирә янына килеп ишек тибәләр... Шаушулы, гаугалы, серле фатирны үз гаиләсенә калдыруларын, йә булмаса башканы бирүләрен сорап бу көннәрдә Әлфирә Тимершина калын ишекләрне шакый. Үзенә әйтелгән тозлы-борычлы сүзләрне килеп миңа – бу язманың авторына сөйли. Үзен, гаиләсен яклап калу өчен судка кадәр үк барып җитәчәген әйтә...

... Бу көннәрдә данлыклы Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнә. Моны истә калырлык итеп үздыру өчен күптөрле чаралар билгеләнгән. Ансамбль урнашкан бинада ремонт эшләре бара, концерт-тамаша программасы әзерләнә.

Мондый вакыйгалар алдыннан хөкүмәтебезнең традициягә кергән матур бер гадәте бар. Мохтаҗларга фатирлар, лаеклыларга мактаулы исемнәр бирә ул. Дистәләгән кеше фатирга чират торган бу коллектив өчен дә бәрәр җае табылыр дип өметләнік. Моңа мөмкинлек юк түгел. Чөнки соңгы елларда Президентыбыз фәрманы белән Казанда торак йортлар төзү күзгә күренеп артты. Моңарчы иске йортларда, тулай торакларда, "кунакханә"ләрдә җан асраган меңнәрчә гаиләләр бөтен уңайлыклары булган яңа фатирларга күчтеләр.

Дистә елдан артык җыр сәнгатен пропагандалауга үзенең көч-сәләтен биргән Әлфирә Тимершина, аның гаиләсе – ире, җиде яшьлек улы Альберт белән өченче яшен тутырып килүче Лилия дә озакламый шундый бәхеткә ирешсеннәр иде. Судлашып, тавышгауга чыгарып яшәүләр Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчеләренең дә, җырчы Әлфирә Тимершинаның да абруен арттырмас, мөгаен.

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,
махсус хәбәрчебез.

Дөнья шаулый

Лев Толстой гөмбә иснәгәч, балачагын искә төшергән

Тормышыбыздагы бик күп вакыйгалар ислар белән хәтергә сеңә. Яңа чабылган печән исе безне яшьлеккә алып кайта, дару исе авыруларны искә төшерә, үткәннәргә кайтыр өчен борынга хуш исле берничә молекула эләгүе дә җитә.

"Әле генә урманнан кайттым гөмбәгә барган идем. Бик күп гөмбә җыйдым, – дип яза 1851 елның 22 августында Л.Толстой дустына язган хатында.

– Миңа кемдер исләрнең, күп еллар үткәч тә, хәтердә үткәндәге вакыйгаларны яңартуга сәләтле булуын сөйләгән иде. Минемчә, урмандагы исләр моңа аеруча сәләтле... Менә хәзер дә кулымдагы гөмбәдән килгән ис, шәен якты сыдай, җиде яшькәчә булган балалык чорымны бөтен нечкәлекләренә кадәр хәтеремдә яңадан яңартты..."

Б.Прусның "В поисках утраченного времени" дигән китабы персонажына да пешкан-туган апасы пешергән печенье исе ерак балачактагы күренешләрне яңартырга ярдәм иткән.

Шешәдәге хуш ис җенси дәртне көчәйтә

Бу турыда борынгылар да белгән. Индус руханилары билбауларында сирәк очрый торган хуш исле үлән суы салынган флакон йөрткәннәр. Берәр куанычлы хәл булганда алар, шул флаконны борыннарына якын китергәннәр, хуш исләр шатлык хисләре белән аралашкан. Еллар үткәч тә, кайгы килгәндә шул флаконны билбаудан алып иснәгәннәр, һәм теге бәхетле чактагы хуш исләр, бөтен рәхәтлеге белән, болар күңелен биләп алган.

Япон гейшалары да исләрдән торган "куен дәфтәреннән" яхшы файдаланганнар. Әгәр гейшага берәр ир заты ошаса, аның белән кавышканчы ул тәненә, киеменә ясмин, лаванда, роза исләреннән торган духи сөрки, ә бу исләр ир күңелендә дәрт уятучан. Аерылганда ул партнерына буш духи шешәсе бүләк итә һәм аның төсе итеп саклавын сорый. Һәм, чынлап та, шешәне иснәгән саен, әлеге онытылмас хатирәләр аның күңелендә кабат яңара, һәм, гадәттә, әлеге гейшага ир кабат әйләнеп кайта.

Куркакның исе дә башка

Исләр хайваннар дөньясында гына түгел, кешеләр арасында да таныклык булып хезмәт итә. Җитәкче кеше "феромон доминантности" (баш булу) исе чыгара, шуңа аның исе дә көчлерәк. Каратэ, айкидо, бокста партнерның исен танырга япон һәм кытай сугышчыларын яшьли өйрәтәләр. Куркак кешенең исе батыр, үз-үзенә ышанучан кеше исеннән аерылып тора. Чөнки курыккан чакта курку исе тәннән бөркелеп чыга икән.

Әфган сугышы вакытында мөҗәһитләрне тау арасыннан, янгын һәм көйгән кеше тәне исе бөркеп, куып чыгаралар икән. Бу ис коточкыч борчылу, курку хисе тудыра. Көйгән резин исенең дә тәэсире шундый.

Литвада татар-караим тәңкәләре

Татарлар һәм караимнәрнең Борынгы Бөек Литва кенәзлегенә килеп урнашуларына 600 ел тулды. Шул уңайдан Литва хөкүмәте саф көмеш 3000 юбилей акчалары койдырды. Аның берсенең бәясе (номиналы) – Литва акчасы белән 50 литка тиң (12,5 доллар). Тәңкәнең бер ягына 1410 елда, кулына корал тотып, Грюнвальд сугышында нимес тәре йөртүчеләре белән сугышкан татар яугире, икенче ягында – бөек кенәз замогы ишегендә сакта торучы караим сурәте төшерелгән. Көмеш тәңкәнең әйләнәсендә "Караимнәр һәм татарлар Литвада 600 ел" дигән язу бар. Көмеш тәңкәдә Литва Республикасы тугрысына да урын табылган.

("Татар-Информ").

Җир өсте кысаная бара

Бер елдан Җир шарында яшәүчеләр саны 6 миллиардка җитәчәк. Демографлар хәбәр итүенчә, бу вакыйга 1999 елның 13 мартында булачак, ди. Хәзер планетабызда 5,7 миллиард кеше яши. Кешелекнең бөтен тарихы буена бертуктаусыз сугышлар, бәла-казалар, төрледән-төрле эпидемияләр булып торуга карамастан, кеше саны арттаннан-арта бара. Әле 4 мең ел элек кенә Җирдә нибары 50 миллион кеше яшәгән, аннан соңгы 3 мең ел эчендә бу сан 5,5кә арткан, соңгы 10 гасыр эчендә исә – 20 мәртәбә! Озакламый кечкенә Җир шарына сыймый башлавыбыз да ихтимал.

7 минутта 90 йомырка...

Кыргызстанның Каракол шәһәрендә яшәүче эшсез йөрүче С.Ашырбаев базарда, бәхәсләшеп, 7 минут эчендә 90 пешкән йомырка ашаган. Бәхәстә ул җиңсә, 10 доллар аныкы буласы икән. Бәхетсезлегенә күрә, йомыркаларның берничәсе чәберчек булып, Сталбәкне укшыткан. Табиблар, аның ашказанын юдырткач, йомырка белән сак эш итәргә киңәш биргәннәр. Һәм 10 доллар да... очкан.

Президент кадәр портрет

Чуашстанның яңадан сайланган президенты Николай Федоровка инаугурация вакытында бик кыйммәтле бүләк – Борис Ельцинның үзе кадәр итеп ясалган портретын бүләк иткәннәр. Республикада бу төрле имеш-мимешләр тудырган. Әмма күпчелекнең фикере бер: мондый хәлнең хәтта Брежнев вакытында да булганы юк иде, диләр.

Музейга – курчак

"Казан" милли мәдәният үзәгендә үткән бер күргәзмәдә 45 сантиметр "буйлы", татар милли киемендәге (күлмәге, камзолы алтын һәм сәйлән белән чигелгән, толымнарына тәңкә чулпылар тагылган) курчак куелган иде. Аны күргәзмә өчен Татарстан Министрлар Кабинеты махсус сатып алган булган. Рәсми булмаган чыганаклар әйтүенчә, курчак 5 миллионга төшкән, әмма Асия Глебова экспозициясеннән алынган бу курчакның бәясе күпкә югары булырга тиеш.

Күргәзмәгә килүчеләрне курчакның югары зәвык белән оста итеп эшләнүе хәйран калдырган. Танылган останың шундый ук бер эше Мәскәүдәге Революция музеенда да куелырга тиеш. Анда шулай ук Татарстан әләме, тугрысы, нәкыш осталарының иң яхшы эшләре дә урын алачак.

("АиФ").

Телефон кара кайгыга әйләнде

Парижда күчмә телефоннарга "сугыш" игълан ителде. Өлкәннәр мавыгып киткән бу уенчык тәмам бәлагә әйләнде. Парижлылар театрларда, рестораннарда, башка җәмәгать урыннарында, кесәдән "мыеклы" телефон тартып чыгарып, өзлексез лыгырдаудан тәмам туйдылар.

("Франс" радиосы).

Революция бишегендә балалар кими

Санкт-Петербургта үлем-җитем балалар туу белән чагыштырганда ике мәртәбә артып китте. 1997 ел нәтиҗәләрен караганнан соң шәһәр статистика комитеты шундый мәгълүмат бирде: 1998 елның 1 гыйнварына шәһәрдә 4 миллион 750 мең кеше яши. Хәзер шәһәрдә 1 мең кешегә яңа туган 7 бала туры килә.

Бәрәңгедән... тәлинкә

Хоккайдо утравында (Япония) урнашкан Кусиро шәһәрендә бәрәңге крахмалыннан ясалган тәлинкәләр җитештерелә башлады. Бу тәлинкәләрне әле генә Нагано шәһәрендә башланган Олимпиада уеннарында катнашучы спортчылар кулланачак. Тәлинкәләр бәрәңге крахмалын җылытып, компресслау юлы белән ясала, алар бер тапкыр кулланыр өчен генә ярый. Соңыннан аларны ашлама итеп дөге басуларына кертәчәкләр. Олимпиада уеннары быел "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында кайгыртыйк!" дигән шигарь белән дә үтәчәк. Мәгълүматлар буенча, Олимпия уеннары вакытында Наганода 100 мең бәрәңге тәлинкәсе кулланылышка чыгарыла.

("СР").

Кыйммәткә төшкән янау

Ставрополь шәһәрендә билгесез берәү шәһәр милиция бүлегенә тимер юл вокзалы менә-менә шартламачак, дип телефоннан шалтырата. 5 сәгать буе, китәсе һәм киләсе поездларны туктатып, шартлаткыч эзләсәләр дә, таба алмыйлар. 5 сәгать тоткарланып торганнан соң, тимер юлда поездлар хәрәкәте башлана.

("Эхо Москвы").

Белемле карак

Күптән түгел Казанның Авиатөзүче районындагы милиция бүлеге коридорлары төрледән-төрле аудио-видео аппаратлар, музыкаль җайланмалар, транзисторлар белән шыплап тулган иде. Милиция боларны үз кирәгенә сатып алган дип уйламагыз тагы. Мондагы оперлар ел ярым буе фатир басып йөрүче бер каракны тоттылар. 25 яшьлек Сергей Французов дигән бу кеше 30 фатирны басуда гаепләнә (бу әле чама белән генә). Милиция Французовка "Стандартный" җинаятьчел төркеме әгъзасы һәм наркоман буларак игътибар итте. Ул моннан ике ел элек утлы корал йөртүе өчен кулга алынган иде. Ирекка чыгуга ук, егет фатир басу белән шөгыльләнә башлаган, чөнки опиумга акча кирәк. Бүген карак урлаган күп нәрсәләр хуҗаларына кире кайтарылды.

Менә сиңа уенчык!

Ташкентта яшәүче 12 яшьлек Саша З. иске Яңа ел кичендә үз гаиләсен унитазсыз калдырды. Ул бәйрәмгә шартлаткыч петарда сатып алган да, берсен, сынап карамакчы булып, ванна бүлмәсендә шартлаткан. Шартлау унитазны челпәрәмә китергән. Хәзер Саша һәм әти-әнисе бәдрәфкә күршеләренә йөриләр.

Ленин үлде, әмма Леундеж яши

Уфада Леундеж исемле яшүсмер инстанцияләр буйлап исемен үзгәртүләрен сорап йөри. Баксаң, аның исеме кыскартылган сүзләрдән тора икән: "Ленин Умер, Но Дело Его Живет". Иптәшләре "Леня" дип йөрсәләр дә, бу исем белән егет үзен бик уңайсыз сизә икән. Совет заманы үтте бит!

Сөенечләр һәм көенечләр

Республика җиңел промышленность предприятиеләре быелгы суыкларда безгә катып үләргә ирек бирмәделәр: миллионнан артык пар киез итек, 525 мең киек тиресеннән бүрекләр, 37 мең яка, 30 мең тун, 424 мең пар күн аяк киемнәре җитештерделәр. Ләкин ел буена Серго исемендәге завод нибары 1,5 мең суыткыч чыгарды, Чистай сәгать заводы да сәгать чыгаруны шактый киметте.

("ВК").

Анатолий ПОНОМАРЕНКО рәсеме (Нововоронеж).

Татар энциклопедиясе битләреннән

ӘБҮЛХАНОВ Рифат Назыйм улы (1956 елда туган), балет артисты, ТР халык артисты (1990), Татар опера һәм балет театры солисты (1975). Ф.Яруллинның "Шүрәле", П.Чайковскийның "Аккош күле", С.Прокофьевның "Ромео һәм Джульетта" балетларында Былтыр, Зигфрид, Меркуциа партияләрен башкара.

ӘГЪЛӘМОВ (Әгъләметдинов) Мөдәррис Зөфәр улы (1946 елда туган), шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1992). Иҗатына дәртле публицистика, кодрәтле лирика, заман сулышын тою хас. "Кыңгырау" (1970), "Учак урыннары" (1973), "Исәнме, йөрәк" (1978), "Киләчәккә кайту" (1987), "Иман тәрәзә шакый" (1996) җыентыклары укучыларда мәхәббәт казанды.

ӘДҺӘМОВ Алмас Мәхмүт улы (1923 елда туган), генерал-майор (1978). 1973-87 елларда СССР Оборона министрлыгы баш инспекциясенең өлкән инспекторы.

ӘДҺӘМОВА Сәрвәр Сабир кызы (1901-1978) язучы һәм тәрҗемәче. К.Нәҗми хатыны. Балалар өчен хикәя җыентыклары: "Дуслар" (1948), "Тубалбаш" (1958), пьесалар, мемуарлар, М.Горький, А.Пушкин, Л.Толстой әсәрләрен тәрҗемә итә. 1930 нчы елларда репрессияләнә һәм аклана.

ӘЙДИ (Әйделдинов) Тәүфикъ Рамазан улы (1941 елда туган), язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1991). "Божра" повесте (1978), "Елан угы" романы (1991), "Безгә ни булды?" җыентыгы (1991), юлъязмалар, очерклар авторы.

ӘЛМӘШЕВ Исхак Мөхәммәтҗан улы (1892-1937), актер һәм режиссер, Татарстан Хезмәт Батыры (1925). 1912 елдан "Нур" труппасында. Ырынбур мәгариф бүлегендә сәнгать мөдире (1919-1928). 1930 нчы елларда укыту эшендә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

ӘЛМИЕВ Усман Гафият улы (1915 елда туган), җырчы, Татарстанның халык артисты (1957). Татар дәүләт опера һәм балет театры җырчысы (1938-1958), аннары Татар дәүләт филармониясендә (1958-1968) эшли. Җ.Фәйзинең "Башмагым", У.Гаҗибәковның "Аршын мал алан", Н.Җиһановның "Алтынчәч" әсәрләрендә Галимҗан, Әскәр, Урмай һәм Җик партияләрен башкара.

ӘЛМӨХӘММӘДОВ Газиз Салих улы (1895-1938), композитор, музыка белгече, җырчы, БАССРның халык җырчысы (1929). 1922-1931 елларда Казанда яши. Беренче татар оперлары – "Сания" (В.Виноградов, С.Габәши белән берлектә) һәм "Эшче"не иҗат итә.

ӘМИНОВ Әхтәм Әмин улы (1918-1942), шагыйрь. "Алар сафта" дигән шигырьләр җыентыгында басыла (1961). Калуга шәһәре янындагы сугышта һәлак була.

ӘМИНОВ Фәйзерахман Габдрахман улы (1904-1984), нәкышче һәм график. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1978), РСФСРның атказанган рәссамы (1984). Хезмәтләре: "Сак-Сок" (1972), "Салкын чишмә", "Г.Тукай Кырлайда", "Шүрәлеләр урманы" (1970 еллар), зур күләмле нәкыш әсәрләре, Г.Тукайның "Шүрәле" әсәренә иллюстрацияләр (Мәскәү, 1964, 1974, Казан, 1975, акварель), Ленинградта яшәүче татар зыялыларының портретлары. 1933 елдан Ленинградта яшәгән.

Дүшәмбе
16 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан" информацион программасы.
17.55 Балалар өчен: "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Кырлар докторы". Ә.Мостафин.
19.45 Яңалыклар.
20.00 Барыбыз өчен дә хоккей.
20.45 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "СТАЛКЕР". 1 нче серия (21.45 – Яңалыклар).
22.20 "Лира йолдызлыгы астында".

"ЭФИР"

6.00, 10.30, 11.25, 14.15, 21.45, 2.45 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 5.25 "Республика". Информацион-аналитик программа.
7.20 "Уян һәм җырла".
9.00 "ЛУНА НАД ЛАКОТОЙ".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45, 14.45 Даруханә.
12.00, 15.00 "ТСН-6".
12.10 "БОЛЬШИЕ ДЕРЕВЬЯ".
13.55 "Тамаша залы".
15.10 "ВАРИАНТ "ОМЕГА". 1 нче серия.
16.35 Мультфильм.
17.00, 19.30, 22.00, 3.20 "Шәһәр". Информацион программа.
17.15 И.Демидовның "Музыка күзәтүе".
18.20 "ВАВИЛОН-5".
19.10 Мультфильм.
20.05 "ХОЛОД АРКТИКИ".
22.35 Юл патруле.
22.55 "ТОНГО".
0.40 Нагаподан "Атна спорты".
1.10 "ОСП студиясе".
1.55 Бенни Хилл шоуы.
2.15 Атна һәлакәтләре.
3.00 Мультфильмнар.
3.50 Нәфис фильм.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Хәерле иртә!
9.15 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
10.00 XYIII кышкы Олимпия уеннары. Чаңгычылар.
11.45 Өй китапханәсе.
12.00, 15.00, 18.00, 1.25 Яңалыклар.
12.15 "Бергә".
13.05 "СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ".
14.20 Көлкеле манзара.
15.20 Мультсериал: "Розовая пантера".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ РОБИН ГУДА".
17.10 XYIII кышкы Олимпия уеннары. Чаңгычылар.
18.20 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак" Олимпия уеннарында.
19.30 XYIII кышкы Олимпия уеннары. Русия – Чехия җыелма командалары (тәнәфестә – "Тыныч йокы, нәниләр").
21.00 "Вакыт".
21.40 "ПОЛТЕРГЕЙСТ".
22.50 "Көмеш шар".
23.35 "МАКАРОВ".

"РУСИЯ"

7.00 Мультфильм.
7.10 Православие календаре.
7.15 Уян.
7.30, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
8.00, 1.00 Кизү бүлеге.
8.15, 1.20 Почта аша әйберләр.
8.20 "Стронг" тәкъдим итә.
8.25 Хәтер өчен.
8.30 Кышкы Олимпия уеннарында. Фигуралы шуу.
10.05 "САНТА-БАРБАРА".
11.35 "Аншлаг һәм Ко".
12.30 "Ап-ачык – акылга сыймаслык".
13.00 Кышкы Олимпия уеннарында тимераякта шуу.
14.35 "ХИЩНИКИ".
16.00 Графоман.
16.10 Акчалар.
16.30 "МАЛЕНЬКИЙ БРОДЯГА"
17.30 Кроссворд.
18.05 Кышкы Олимпия уеннарында. Хоккей. Канада – АКШ.
20.30 "Нечкәлекләр".
20.45 Олимпия курьеры.
21.25 "САНТА-БАРБАРА".
22.25 Довгань-шоу. "Серле лабиринт".
23.00, 23.55 Кышкы Олимпия уеннарында. Тимераяк. 1500 метр.

"КУЛЬТУРА"

8.00, 0.20 Музыкаль экспромт.
8.15, 14.00, 0.00 Мәдәният яңалыклары.
8.35 Модада кешеләр.
8.50 Спектакль: "Возвращение из прошлого". Ф.Шаляпинның 125 еллыгына.
10.00, 12.00, 16.00, 18.00 Яңалыклар.
10.05 Петербургтан музыка. "Дөнья биючесе – Игорь Зеленский".
10.45 Документаль фильм: "Катакомбы ранних христиан".
11.00 Сынчы В.Цигаль.
11.45 Китап хәзинәсе.
12.05 "Көнчыгыш факультеты". Шамиль.
12.35 Телеспектакль: "Винтовки Тересы Каррар".
13.45 "Дөнья шәһәрләре мәдәнияте".
14.20 В.Астафьев. "Затеси".
15.10 "Православиеле Русия". П.Чесноков әсәрләре.
15.45 Китаплар вакыты.
16.05 "ЧЕЛЛЕНДЖЕРС".
16.30 "Вакыт буенча сәяхәт".
17.10 Терпсихора гашыйклары.
17.25 "Лукоморье".
17.45 Кибермәдәният.
22.25 "ОТЦЫ И ДЕТИ".
23.40 Төнге кунак.

"НТВ"

6.00, 10.00 Бүген иртән.
9.05 "ЧУЖОЙ НАРОД". 5 нче серия.
10.10 Кичә "Йомгаклар"да.
11.10 Документаль сериал: "Синдикат убийц".
11.40 В.Шендерович белән "Җәмгысе".
12.00, 14.00, 16.00 Бүген көндез.
12.20 "Иске телевизор". "Богач, бедняк...".
14.20 "О ЧЕМ ЗНАЛА МЕЗИ".
16.20 "Сезам урамы".
16.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
17.40 Документаль сериал: "Шпионы".
18.10 "Файда өчен".
18.20 Криминал.
18.35 Футбол клубы.
19.00, 22.00 Бүген кич.
19.40 "Көн каһарманы".
20.00 "ЛЕГЕНДА О ДИНОЗАВРЕ".
22.50 "ЧУЖОЙ НАРОД".
23.40 "Олимпия сәгате. Безнекеләр – Наганода".
0.45 Көн яңалыклары.
1.10 "Бүген төн уртасында".



Сишәмбе
17 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан". Информацион программа.
17.40 Мультфильм.
17.50 Республика телевидениеләре программасы. "Эшлекле Татарстан".
18.10 Баскетбол. Русия чемпионаты. "УНИКС-Локомотив" (Казан) – "Спартак" (Санкт-Петербург) (Тәнәфестә – "Җиһан").
19.45 Яңалыклар.
20.00 "Карт-бланш". Е.Березиков.
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
21.00 "СТАЛКЕР". 2 нче серия. (21.45 – Яңалыклар).

"ЭФИР"

6.00, 11.30, 21.45, 2.50 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 17.00, 19.30, 22.00, 3.30 "Шәһәр". Информацион программа.
7.20 "Уян һәм җырла".
9.00 "ХОЛОД АРКТИКИ".
